МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№1 / гыйнвар 2014

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

«Энҗе» панносы. 2011 ел.
63х48. Күн, ефәк җеп.
Н.Кумысникова эше

12 +

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ тарафыннан гамәлгә куелды. 2012 елның май аеннан чыга.

Баш мөхәррир —
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары — җаваплы сәркатип —
Рамил ХАННАНОВ
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов
Әнвәр Хуҗиәхмәтов

Бүлек мөхәррирләре:
Илдус ЗАҺИДУЛЛИН
Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН
Алия МӨБАРӘКШИНА
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы —
Диләрә НӘҮРҮЗОВА
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор —
Дания ФӘЙЗУЛЛИНА
(843) 222-09-83 (17-90)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

Заказ №А-8
Тираж — 1500 данә.
Формат 70 х 108 1/16
Басарга кул куелды: 13.01.2014
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Бәясе ирекле

МИРАС
ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№1(25) / гыйнвар 2014

Эчтәлек

ТАРИХ

4 **Идел буе Болгар дәүләтендә мөселман мәхкәмәләре һәм казыйлары.** *Алмаз Мөхәммәдиев*

12 **XVII-XVIII гасырларда Көньяк Урал төбәгендә яшәгән татарлар тарихыннан.** *Гаяз Сәмигулов*

24 **Йосыф Акчура һәм аның «Яңа төрек дәүләте уңчылары» әсәре.** *Мәсгуд Гайнетдин*

27 **Яңа төрек дәүләте уңчылары.** *Йосыф Акчура*

36 **Гыйлем, мәгърифәт нурын чәчүче...** *Ленар Гобәйдуллин*

39 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның гыйнвар ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

47 **Республикабыз мәнфәгатьләрен кайгыртып.** *Азат Зыятдинов белән Илдус Заһидуллин әңгәмәсе*

54 **Нардуган һәм сәүмәт.** *Рифкать Әхмәтҗанов*

ӘДӘБИЯТ

58 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*

71 **Елый-елый, сугыша-сугыша җирдә...** *Разил Вәлиев*

72 **Чишмә башы.** *Лена Гайнанова*

84 **Әкиятче бабай.** (Зариф Мөэминовның тууына 120 ел) *Факил Сафин*

96 **Хәтер ярыннан торып...** *Марсель Галиев*

101 **Шигырьләр.** *Эльс Гаделев*

СӘНГАТЬ

106 **Гасырлардан килгән матурлык.** *Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова*

112 **Ул — Яруллиннар йолдызлыгыннан.** (Фәрит Яруллинның тууына 100 ел). *Рәшат Низами*

120 **Яңа китаплар.** *Разил Вәлиев*

Безнең журналга
54132 ИНДЕКСЫ
буенча Татарстанның һәм
70275 ИНДЕКСЫ
буенча Россия төбәкләренең
һәр элемтә бүлегендә язылырга
мөмкин.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.
Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.
Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Тышлыкның 1 нче битендә — «Сәнгать агачы» панносы. 2006 ел.
Күн, мамык җеп.
Н.Кумысникова эше.

Бу санда авторларның архивларыннан да фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

«Истинное наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)



Тарих

Хәрабәләр, ташлар арасында
Башын иеп тора кылганнар…
Бабайларның сүзен сөйләр өчен,
Тик кылганнар гына калганнар.

Разил Вәлиев

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ МӨСЕЛМАН МӘХКӘМӘЛӘРЕ ҺӘМ КАЗЫЙЛАРЫ

АЛМАЗ МӨХӘММӘДИЕВ,
тарих фәннәре кандидаты, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре

X ГАСЫР БАШЫНДА БОЛГАРЛАР ТАРАФЫННАН ДӘҮЛӘТ ДӘРӘҖӘСЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮ ЯҢА ДӘҮЛӘТЧЕЛЕКНЕҢ, ДИНИ ҺӘМ ХОКУКЫЙ СИСТЕМАНЫҢ, ГОМУМӘН АЛГАНДА ДӨНЬЯГА ЯҢАЧА КАРАШНЫҢ ФОРМАЛАШУЫН АҢЛАТА.

Болгарларның законнар чыгару һәм мәхкәмәсе нигезенә ислам дине барлыкка килгәндә булган, соңрак Өммәвиләр һәм Габбасыйлар дәверендә киң үсеш алган һәм өстәлгән хокукый система салынган. Әмма бу болгар хокукый системасы аларның төгәл күчерелмәсе икәнлеген һәм бернинди үзгәрешләрсез калганлыгын аңлатмый. Төп аермаларның берсе буларак шуны атарга мөмкин: болгар хакиме шәфигыйләр (Багдад) мәзһәбенең түгел, ә хәнәфиләрнең (Урта Азия) йолалар системасын кабул итә. Идел буе болгарлары тарафыннан шул заманда ук гамәлдә булган хәнәфиләр мәзһәбенең тулысынча өстенлеккә ирешү сәбәбе бары тик дини карашлар һәм географик фактор белән генә билгеләнми, ә бу сәяси тенденцияләр Урта Азия белән бәйле әүвәлдән килгән сәүдә һәм мәдәни багланышларны саклау теләге белән бәйле.

Хәнәфиләр мәзһәбенә ияручеләр карашылыкларда һәм мәхкәмә эшләрендә төп игътибарны кануннарның сүзләренә түгел, ә җирле шартларны искә алып, аларның мәгънәсенә юнәлтә. Шулай итеп, Әбу-Хәнифә тәгълиматы һәм аңа иярүчеләр төгәл вазгыятькә бәйле рәвештә, хокукый мәсьәләләрне хәл иткәндә, чагыштырмача ирекле гамәл кылырга мөмкинлек биргәннәр. Ибне Фадланның Болгар падишаһының фикъһе карарларын гамәлгә кертү кагыйдәләрендә хәбәрдарлыгын (мөҗтәһидләрнең мәҗбүри килешүләре нигезендә), шулай ук җәй көннәрендә кичке һәм төнге намазны берләштерү тәҗрибәсен (моны шуңа туры килгән фәтва таләп иткән) искәртүе белгечләргә болгарларның мөселман хокукый традицияләре белән яхшы таныш булулаларын гына түгел, ә җирле шартларны һәм үзенчәлекләрне искә алып, төгәл фәтвалар чыгарырга омтылышлары турында да сөйли [1].

X гасыр азагына кадәр барлык ис-

лам дөньясында казыйларның Коръән, сөннәт, Мөхәммәд (с.г.в.) сәхабәләренең аерым һәм күмәк карарлары (иҗмагъ) белән чикләнмәгән мәсьәләләрне тикшергәндә шактый иректе эш иткәннәрен һәм «бер мәсьәләне хәл иткәндә, бер мәзһәбнең карарларын, ә икенчеләрен тикшергәндә, башка хокукый мәктәп тарафдарлары тәкъдим иткән нормаларга мөрәҗәгать итүләрен» истә тотып, Р.М.Мөхәммәтшин X гасыр башына Идел буе Болгарстанында дәүләтчелек һәм дини-хокукый система формалашу процессы ислам динен гаммәви һәм рәсми кабул итү белән генә төгәлләнмәгән дигән нәтиҗәгә килә. Хәнәфиләр мәзһәбе башкаларның фикеренә һәм исламга кадәрге чорда халыкларда формалашкан җирле йола буенча килгән хокуктан файдалануга чагыштырмача түзем булуы белән, мөгаен, әлеге процессның төгәлләнүен тизләтүгә булышлык итмәгән. Бу очракта, галим, болгарларның исламлашуын чынбарлык буларак истә тотып, Г.Э. фон Грюнебаумның «һәркемгә мәгълүм мәгънәдә канунны көнкүреш юридик практикадагы гамәли корал буларак түгел, ә барыннан да бигрәк һәммә мөселманнарны да бәйли торган мөселман идентификациясе һәм көче дип карарга кирәк», дигән фикере белән килешмәскә мөмкин түгел, ди [2].

Болгарларның хәнәфиләр мәктәбен үзләштерүләре аларның нәкъ менә исламның шушы юнәлештәге хокук нормаларын кабул иткәнлекләрен дә аңлата. Идел буе Болгарстанында казыйларның һәм фәкыйһләрнең Коръән һәм сөннәттән кала нинди мөселман хокукы чыгакларыннан файдалану ихтималы турында без танылган татар дин галиме Г.Утыз-Имәни (1754-1834) таянган мәшһүр чыганаклар нигезендә фикер йөртә алабыз. Шунысы мәгълүм: бу галим Идел буе Болгар дәүләте чорыннан килгән чыганаклар белән генә файдалануны дәвам итеп калмый, ә җирле мөселман-хокукый фикере традицияләренә дә чын күңелдән ияргән була. Әлеге чыганакларны өч төркемгә бүләргә мөмкин. Беренче төркем — VII-VIII гасырларга караган чыганаклар, аларга аеруча мәшһүр китап — «әл-Мәбсүт»не кертәләр, китапның авторы — әбү Хәнифә шәкертләреннән булган Әбү Йосыф Ягъкуб ибне Ибраһим әл-Казый әл-Хәнәфи (798 елда вафат). Икенче төркем — X-XII гасырларга карый, алар арасында Урта Азия фәкыйһе Әбү әл-Ләйс Насыйр ибне Мөхәммәд ибне Ибраһим әс-Сәмәрканди әл-Хәнәфинең (968 елда вафат) «Ән-Нәвазид фи әл-Фуругъ», Мөхәммәд ибне Әхмәд ибне Әби-Сәхел әс-Сархаси әл-Хәнәфинең (1046 елда вафат) «Әл-Мөхит», Урта Азия дин галиме Борһанетдин ибне Әбүбәкер әл-Маргинани әл-Хәнәфинең (1196 елда вафат) «әл-Һидая» исемле китаплары бар. Өченче төркемгә шулай ук хәнәфиләр мәзһәбенә нисбәтле, XIII-XV гасырларга караган күпсанлы гыйльми әсәрләр керә. Гомумән алганда, Г.Утыз-Имәнинең Әбү-Хәнифә, яки аның шәкертләре Әбү Йосыф һәм Мөхәммәд фәтваларына өстенлек биргәнлеге, әмма беркайчан да аларның фәтвалары кысаларыннан чыкмаганлыгы мәгълүм. Шуның белән ул татар-мөселман җәмгыятендәге традицион нигезләрнең сакланып калуына ярдәм иткән [3].

Югарыда күрсәтелгәннәр безгә Идел буе Болгарстанында хокук белгечләре һәм казыйлары шушы беренче ике төркем мөселман хокукы чыганаклары белән таныш булганнар, аны гамәлдә уңышлы кулланганнар дип уйларга мөмкинлек бирә. Моны аларның барлыкка килү вакыты, ислам динендәге хәнәфиләр мәзһәбенең турыдан-туры чыганагы булулары белән дә, шулай ук бу чыганакларның вакытлар узу белән традицион мөселман иҗтимагыйхокукый фикеренә әверелүе һәм Идел буе татарлары арасында йөзләрчә еллардан соң да кулланылуы белән аңлатырга мөмкин.

Идел буе болгарлары арасында ис-

лам хокукый фикере тернәкләнүенә, үсешенә йогынты ясаган һәм бәхәсле дини-хокукый, шул исәптән мәхкәмә мәсьәләләрен дә чишәргә сәләтле мәшһүр мөселман хокукы белгечләре булганмы? Һичшиксез, булган. Тикшерүчеләр аларның кайберләрен исемнәре белән атаган. Чыганакларның шикле булуына да карамастан, без бу авторлар турында мәгълүматларны китерәбез. И.Березин болай дип яза: «Голямалардан сәхабәләрнең укучысы Габделлатыйф ибне Габдулла һәм бөек мөҗтәһидләрдән «Хөкемдарларга терәк һәм юридик мәсьәләләр буенча киңәш бирүчеләргә файда» исемле әсәр авторы Нух ибне Мөрим мәгълүм, аның кабере хәзерге вакытта Болгарда. Болгардан мәшһүр имам Хагерзадә Хәрәземдә җирләнгән; һәм тагын бер танылган болгар казначысы Гайсә ибне Әхмәт ибне Мөхәммәд ибне Әбүбәкер Болгарда җирләнгән. Болгар зиратына башка мөҗтәһидләр дә җирләнгән[1]. Сәяхәт вакытында Кашгар җиреннән килеп вафат булган Бохара, Хәрәзем руханилары һәм фәкыйһләре бихисап, алар арасында Габдрахман Җами[2] да бар... Болгарга килгән мөгаллим Хисаметдин ибне Ибраһим «Хюсамовның раславы һәм «Тимер таш» кануннарының нәтиҗәләре турында» исемле кануннар китабы язган» [4].

М.Худяков Шәрәфеддин бине Хисаметдинга сылтама ясап, шулай ук урта гасырда Урта Идел буйларында яшәп, дини-хокукый тормышка йогынты ясаган суфи әйдаманнарның исемнәрен телгә ала. Аеруча, Әхмәд Ясәвинең мөриде Ибраш углы Бәйрәш; Бәйрәшнең мөриде Тукмөхәммәд углы Ишмөхәммәд; Зөлмөхәммәд углы Идрис һ.б. исемнәрне яд кыла [5].

Без бүген чыганаклар нигезендә Идел буе Болгар дәүләте тарихында үзләренең эзләрен калдырган кайбер болгар хөкемдар-казыйларының төгәл исемнәрен атый алабыз. Мәсәлән, «Тәварихе Болгария»не язган болгар казые Ягъкуб ибне Ногман әл-Болгари (XIII гасыр). Кызганыч ки, хәзерге вакытка кадәр әлеге китапның бер генә нөсхәсе дә табылганы юк. Ш.Мәрҗани (1818-1889), бөтен Европага бу турыда мәгълүмат бирелүгә карамастан, аны эзләү уңай нәтиҗәләр бирмәүгә сыкрана. (Шунысын да әйтергә кирәк: бу вакытта ибне Фадланның Идел буена сәяхәте турындагы язмалары да табылмаган була). Икенче галим — Әбел-Гали ибне Идрис әл-Казый әл-Болгари (XII гасыр, 1106 елда исән була) — башка титуллары белән бергә «бидгатькә каршы көрәшче», «фәкыйһ» [6] исемнәрен дә йөрткән. «Болгарда казый булган» Хәмид әл-Болгариның шәкерте Ибне Дауда әс-Саксини язмаларына караганда, «бу казый Әхмәд Ясәви тарикатендә булган»[7]. Шулай ук шәех, имам, казый Гыймаледдин Әбүбәкер Мөхәммәди ибне әл-Хәсән ибне Мансур ән-Нәсәфи исеме дә билгеле [8]. Бәйһакиның «Трихе Бәйһак» әсәрендә 1041/1042 (һиҗри буенча — 433) елларда «...болгарларның кешесе — бу халыктан зур кешеләрнең берсе — илле кешедән торган яраннары белән хаҗ кылырга барганда», Багдадта булганнар дигән мәгълүмат бар. Шунысы мәгълүм: болгар аксөякләрен «хөкемдар» ләкабле Ягъла ибне Исхак әл-Хәрәзми дигән кеше озата килә, ул хәлиф диванында (дәүләт канцеляриясендә) сөйләшүләр алып бара [9].

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине рәсми рәвештә кабул ителүенә дә карамастан, җәмгыятьнең бер өлеше мәҗүсилек карашларын һәм

---

[1] И.Березин: «...похоронены и другие мюджтегиды принципов и выводов из принципов», — дип яза. Мөҗтәһидләр — исламның беренче чорларында яшәгән канун чыгаручы белгечләр. «Принцип» сүзе астында дин канунын аңларга кирәктер, ягъни «мюджтегиды принципов» — дин кануннарын белгән, өйрәнгән, шул кануннар нигезендә пәйгамбәр заманыннан соң үзгәреп бара торган тормышка яраклашып яңа кануннар чыгарган («выводы из принципов») галимнәр. — Тәрҗ.иск.

[2] Бу — мистификация. Фарсы-таҗик суфый шагыйре Габдрахман Җами (1414-1492) Һерат каласында (хәзерге Әфганстанның төньяк-көнбатышы) вафат була. — Тәрҗ.ис.

гадәтләрен дәвам итә. Бу буйсынган фин-угор кабиләләренә генә түгел, ә болгарларның үзләренең кайбер төркемнәренә дә карый. Болгарлар арасында мәҗүсиләргә бәйле мәхкәмә дәгъваларының һ.б. бәхәсле мәсьәләләрнең ничек хәл ителгәнлеге турында бездә дәлилләр юк диярлек. Мөгаен, җәмәгать мәхкәмәләре өчен хокук чыганакларыннан берсе булып йола буенча килгән хокук нормалары калу дәвам иткәндер. XI гасырда Болгарда булып кайткан Әл-Гарнати мәгълүматлары буенча, мукшыларның [10] ата-бабалары сихерчеләргә корган мәхкәмәсе традицион диннәр тарафдарлары булган халыклар арасында гадел хөкем, ислам дине кабул ителгәннән алып йөз ел узганнан соң да, йола буенча килгән хокук нигезендә дәвам иткән дип уйларга мөмкинлек бирә.

Югарыда әйтелгәннәргә бәйле рәвештә, берничә сорау туа. Йола буенча килгән хокук нигезендәге мәхкәмәләрнең карарлары ислам дәүләте кысаларында нинди куәткә ия? Шәригать хокукы һәм хөкеме белән Болгар дәүләтенең мәҗүси халкы арасында үзара бәйләнешләр һәм тәэсир итешүләр булганмы? Әгәр дә булган икән, мәҗүсиләр җәмгыятендә хөкем-бәхәс мәсьәләләрен хәл иткәндә шәригать мәхкәмәләренең роле нидән гыйбарәт? Җавапны урта гасырлардагы башка төрки дәүләтләрдәге мәхкәмәләр һәм хөкемдарларның эшчәнлеге белән чагыштырып карап табарга мөмкин. Мәсәлән, Госманлы дәүләтендә казыйлар шәригать эшләрен генә түгел, ә йола буенча килгән хокук эшләрен дә тикшерергә вәкаләтле. Анда беркайчан да бары тик йола буенча килгән хокук эшләрен генә тикшерә торган махсус хөкем йортлары булмаган. Багдадтагы «Мәрҗания» мәдрәсәсе диварларына язылган язу («диван шәригать һәм гореф хокукы буенча булган бәхәсләрне тикшерә») Илханилар заманында ике төрле хокук эшләре дә бер хөкемдар тарафыннан тикшерелгәнлеген дәлилли. Сәлҗукыйлар дәүләтендә дә казыйдан башка үзгә мәхкәмәләр юк. Мөселман булмаганнарның кайбер эшләрен карау вәкаләте вакыты белән шул җәмгыятьләрнең мәхкәмәләренә тапшырылган. Кайбер мөселман илләрендәге мазалим диваннары («гаделлек диваннары») гореф мәхкәмәсен тәшкил итмәгәннәр, ә гадәти мәхкәмәләрдән оешу җәһәте белән генә аерылып торганнар, шулай ук шәригать кысаларында гамәл кылып, аерым вәкаләтләргә һәм вазифаларга ия булганнар. Гомумән алганда, мондый традиция әүвәлге ислам дәүләтләре традицияләренә тәңгәл килгән [11].

Хәзәр дәүләтенең дә мәхкәмә системасы үзенчә уникаль булган. Аның йогынтысына Идел буе Болгар дәүләте дә кергән. Җыеп әйткәндә, Хәзәр дәүләте һәм болгарлар арасындагы сюзеренитет-вассалитет системасы, аның Идел буе Болгарстаны белән иҗтимагыйхокукый мөнәсәбәтләрен яктырткан-да, Хәзәр дәүләтендәге җәмәгать хокукына караган чыганакларны җәлеп итәргә мөмкинлек бирә. Әл-Мәгъсуди мәгълүматларына караганда, Хәзәр каганлыгында «җиде хөкемдар: икесе мөселманнар өчен; икесе хәзәрләр өчен, алар Тәүрат буенча хөкем иткәннәр; икесе андагы христианнар, алар Инҗил кануны буенча хөкем иткәннәр; ә берсе славяннар, руслар һ.б. мәҗүсиләр өчен, болары мәҗүсилек кануннары буенча, ягъни акыл кануны нигезендә хөкем иткән. Хөкемдарлар төшенә алмаган зур дәгъваләр булган очракта, алар мөселман хөкемдарлары янына җыелган, дәгъва турында сөйләгән һәм ислам кануны нигезендәге карарга буйсынган» [12].

Чыганаклардагы мәгълүматларны һәм татарлар арасында ислам хокукы таралуын өйрәнү Г.Гобәйдуллинга хәзәр хакимияте «әгъзалары, яһүд дине вәкилләре булуга карамастан, ислам хокукын өстен күрә һәм кассацион мәхкәмә[3] ике казыйдан торган мәхкәмә булган, алар мәхкәмә эшләрен

шәригать буенча алып барган» [13], дип язарга нигез биргән.

Әмма бу нисбәттән берникадәр алданрак әйтелгән һәм, безнең карашка, дөресрәк фикер бар. А.Я.Гаркави, чыганак текстына үзенең аңлатмаларын кертеп, әл-Мәгъсудинең мөселман казыйларына өстенлек бирүе хакыйкатькә якынрак торган авторның ислам кануннарының башкалардан өстенлеге турында гомуми инануы булмаса, ихтимал ки, аның тарафыннан гомуми кагыйдәгә кертелгән аерым бер очрак кына, дип әйтә. Ибне Фадлан катлаулы булган дәгъваларның мөселман казыйларына түгел, ә Хәзәр каганына тәкъдим ителүнең шаһиты була [14].

П.Голубовский фикеренчә, Хәзәр каганлыгында башка хөкемдарлар мөселман хөкемдарларына дәүләт хөкемдарлары булганлыктан мөрәҗәгать иткән [15]. Шушы вакытта Хәзәр дәүләтенең таркалу алдында торганлыгын искә алсак, тиздән каганның мөселманнардан ярдәм сорарга мәҗбүр булачагын һәм үзенең дә ислам динен кабул итәчәген искә алганда, бу фикерне инкярь итү, безнең фикеребезчә, чынбарлыкка туры килми.

Әлбәттә, Хәзәр дәүләтендә хәтта мөселман хөкемдарларының абруйлары да аларга үзләренә тиңдәшле башка мәхкәмәләргә мөнәсәбәтле югары инстанция булу хокукы бирә алмаган. Бигрәк тә яһүдләр, христианнар һәм мәҗүсиләр мәхкәмәләре эшләрне төрлечә, үзләренең кануннары һәм төшенчәләре буенча караган, һәрберсенең мәхкәмәдә чыгыш ясау, мәхкәмә процессын алып бару үзенчәлекләре булган. Һичшиксез, Әл-Мәгъсуди мөселман хокукы кануннарының дөреслеге ягыннан да, гаделлек буенча да бүтәннәрдән өстен булуына тирән инанган. Башка хөкемдарларның да, авыр чишелешле мәсьәлә буенча карашларын ачыклау, әлеге мәсьәләләргә ислам кануннар җыелмасы күзлегеннән кызыксыну яки эшнең асылына бәйле шәхси фикерләрен белер өчен, үзләреннән укымышлырак казыйларга мөрәҗәгать итүләре мөмкин. Хәзәр каганлыгында төрле тәртиптә мәхкәмә эшләрен алып бара торган җиде хөкемдар булганлыгы турында Ибне Хаукаль, Ибне Фадлан, әл-Мөкаддәси һәм әл-Бәкри кебек галимнәр дә искә ала.

Моннан тыш Ибне Фадлан Хәзәр каганының Идел елгасындагы утрауда зур шәһәре булганлыгы, аның икегә бүленгәнлеге, бер өлешендә мөселманнар, ә икенчесендә каган һәм аның якыннары яшәгәнлеге турында әйтә. «Мөселманнар өстеннән хаз (казый) дип аталган, патшага якын булган яшүсмер ир углан идарә иткән. Хәзәрләр илендә яшәгән мөселманнар һәм алар янына сәүдә эшләре белән вакытлыча килгәннәр өстеннән мәхкәмә хакимияте аңа бирелгән. Аннан кала берәү дә хөкем итү эшләрен алып бармаган. Бу шәһәрдә мөселманнарның намаз укый торган һәм җомга көннәрендә җыйнала торган җамигъ мәчете бар» [16].

Мәхкәмәләр булу шул чорда мәхкәмә карарларын башкаручы һәм хокук саклаучы органнарның да эшчәнлеге турында уйларга нигез бирә. С.Плетнёва фикеренчә, Хәзәр дәүләтендә полиция функциясен ларшилар дип аталган мөселманнардан торган каган гвардиясе башкарган [17].

Тарихи әдәбиятта X гасыр башында болгар патшасы кулында хәрби хакимияттән тыш, югары мәхкәмә һәм гади халык өстеннән хакимият тә тупланганлыгы искәртелә. Төрки традицияләр буенча, дәүләт яки халык башлыгы иң изгеләрдән саналган. Җәмгыятьне исламлаштыру болгар хакименең бу роленә сизелерлек дәрәҗәдә йогынты ясамаган. Ибне Фадлан хәбәрләренә караганда, Алмыш илтәбәр кулында югары дини һәм мәхкәмә хакимияте тупланган [18].

[3] Кассацион мәхкәмә — мәхкәмә хөкемен яңадан карый һәм аны юкка чыгара ала торган югары инстанция.

Ибне Фадланның Алмыш турындагы мәгълүматыннан кала, югары хакимият кысаларында югары мәхкәмә хакимияте дә булганлыгын, соңгы мәхкәмә инстанциясе хокукына ия, акыллы һәм гыйлемле болгар хакиме образын без «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә дә күрәбез. Әсәрдә аның турында: *«Бай-ярлыга дөрес, гадел хөкем кыла, / Берәүгә дә җәбер-җәфа кылмый имди»,* — дип языла. Йосыфның җәза бирү һәм ярлыкау турындагы вәкаләте башта үзенең юлдан язган агаларына җәза бирүендә күренсә, аннары нәфрәтенең мәрхәмәткә алышынуы әсәрнең аерым бүлегендә чагылыш таба [19].

Идел буе Болгар дәүләте тарихы турындагы чыганакларда, аеруча рус елъязмалары һәм аның нигезендә барлыкка килгән хезмәтләрдә, без халыкара мәхкәмә кебек күренешнең яралгыларын табабыз. Күп кенә хәрби бәрелешләргә, конфликтларга да карамастан, Идел буе Болгар дәүләте һәм рус кенәзлекләренең багланышлары, нигездә, тыныч яшәү, үзара ярдәмләшү, табышлы сәүдә мөнәсәбәтләре рәвешендә булган. Болгарлар һәм рус кенәзлекләре арасында тынычлык килешүләре килеп чыккан бәхәсле мәсьәләләрне ике якның да гадәтләре һәм традицияләре нигезендә хәл итүне күз алдында тоткан. Бу җәһәттән монгол яулары алдыннан, 1229 елда, Владимир кенәзлеге һәм Идел буе Болгар дәүләте арасында булган тынычлык турындагы соңгы килешүләрнең берсе аеруча игътибарны җәлеп итә. В.Н.Татищев ничек итеп рус чикләре янәшәсендәге Коренев утравында рус һәм болгар илчеләре җыйналуларын, сөйләшү-килешүләрен тәфсилләп сурәтли. Тарихчы язуынча, алар «сәүдәгәрләргә һәр ике тарафка да чикләүсез чыгарга һәм салымнарны һәр шәһәрнең уставы нигезендә, кыерсытылмыйча түләргә; һәр якның балыкчыларына дәүләт чикләренә кадәр барырга; мәхәббәт һәм тынычлык булдырырга, барлык әсирләрне дә азат итәргә; әгәр дә бәхәсләр була калса, ике як хөкемдарларына да дәүләт чикләренә килеп хөкем итәргә», дип карар кылалар [20].

Тексттан ике дәүләтнең дә икътисади һәм сәяси мөнәсәбәтләрен үзара килешеп җайга салулары аңлашыла. Тикшеренүчеләр, рус елъязмаларына нигезләнеп, үзара табышлы сәүдә турында гына түгел, ә Идел буе Болгар дәүләтендә күп сандагы рус колонияләре һәм рус территорияләрендәге болгарлар булуы турында да яза. Аеруча Владимир-Суздаль кенәзлеге шәһәрләрендә болгарлар шактый булган, алар хәтта ссудалар белән дә тәэмин ителгән [21].

Әмма хезмәттәшлек һәм бәхәсле хәл барлыкка килү факты ике як өчен дә мәҗбүри карар чыгарырга билгеләнгән уртак мәхкәмә булганлыгын аңлатмый. Кенәз Юрий Всеволодович кешеләре һәм болгарлардан вәкилләр нәрсә нигезендә 1229 елда мәхкәмә оештырырга җыйналган соң? Бу сорауга да җавап рус елъязмаларында бар. Хәрби конфликттан соң, 1220 елда, бөек кенәз Юрий болгар илчеләре белән тынычлык турында килешә, «элекке килешү буенча идарә итеп, әтисе Всеволод һәм бабасы Георгий Володимерич заманындагыча, илчеләрне кенәз ротасына һәм җирләренә аларның кануны буенча алып бардылар» [22]. Һәр ике тараф та үзләренең гадәтләре, иманнары буенча ант итә. Бу факт турында, рус чыганакларына нигезләнеп, Н.М.Карамзин «безнең илчеләр аларның җирләренә барды, андагы барлык халык та ислам дине кануны буенча ант итеп тынычлыкны яклаган», — дип ассызыклый [23].

Тынычлык өчен килешүләр нигезендә куелган шартлар һәм бурычларның башкарылуы үзара ант итешү белән гарантияләнгән. Анттан читләшү яки аны бозу җинаять саналган һәм уртак мәхкәмәдә каралып, кырыс хөкемгә тартылган. Мөгаен, бу һәм элегрәк

төзелгән тынычлык килешүләрнең шартлары, шулай ук ут күршеләрнең дус-тату яшәүләренең гомуми принциплары рус кенәзлеге һәм Идел буе Болгарстаны чигендә әлеге дәүләтләрдә яшәүчеләр өстеннән халыкара мәхкәмә оештыруга сәбәп булгандыр.

Ике мәдәниятнең багланышларын, ике иҗтимагый-хокукый системаның килешүен без әл-Гарнатый язмаларында да күрәбез. Гарәп сәяхәтчесе славяннарда мөлкәткә китергән зыян өчен җинаять җаваплылыгы булуы турында хәбәр итә. Әгәр дә алардан кем дә булса башка берәүнең кол хатын-кызына яки аның улына, яки аның аяклы малына зыян китерсә, нинди дә булса рәвештә канун бозса, тәртип бозучыдан билгеле суммада штраф алганнар. Әгәр дә тәртип бозучының акчасы булмаса, җинаять өчен түләү буларак, аның хатынын, ул һәм кызларын сатканнар. Гаиләсе һәм балалары булмаган очракта, гаепләнүченең үзен сатканнар. Ул кеше, зыян күрүче белән исәп-хисапны өзгәнче яки кем дә булса аның өчен түләгәнче, кол булып калган. Әгәр түли алмаса, бурычлы кеше хуҗасы вафат булганчыга кадәр аңа хезмәт иткән. Мондый төр хезмәт өчен бернинди дә түләү каралмаган. Славяннарның әлеге кырыс кануннары чит ил һәм чит дин кешеләре белән багланышларында да кулланылган. «Ә аларның илләре ышанычлы, — ди әл-Гарнатый, — мөселманнар алардан кем белән булса да эш алып барса, һәм славян банкротлыкка чыкса, ул үзенең балаларын, өен сата — әлеге сәүдәгәргә бурычын кайтара» [24]. Славяннарга иң якын, күрше булып яшәүче халык болгарлар булганлыгын исәпкә алганда, сүз бу ике ут күрше арасындагы эшлекле һәм сәүдә мөнәсәбәтләре турында барган, дип ялгышмыйча әйтергә була.

Мәхкәмәләр халык өчен ачык булганлыктан, хөкем бертөрле калып буенча гына чыгарылмаган, аңа җәмәгатьчелек фикере дә йогынты ясаган. Идел буе Болгарстанында җәмәгатьчелекнең мәхкәмәләргә һәм хөкемдарларга ничек караганлыгы турында без XII гасырның мәшһүр суфи шагыйре шәех Әхмәд Ясәви хикмәтләреннән һәм аның рухи дәвамчысы Сөләйман Бакыргани әсәрләреннән укып белә алабыз. Ә.Ясәви тәгълиматының мәшһүр булуын искә алып, галимнәрнең, Идел буе Болгар дәүләтенең Урта Азия белән сәүдә-икътисади һәм мәдәни багланышлары җанланганда, «Хикмәтләр» авторы исән булган вакытта ук, бу әсәрнең болгар җәмгыяте мәдәни катламының казанышы дип уйларга нигезләре дә бар. Күп галимнәрнең фикеренчә, Ясәви һәм Бакыргани әсәрләренең иң киң таралган урыны — Идел-Урал төбәге [25]. Хикмәтләрнең кулъязма вариантлары әлеге төбәктә бүгенге көндә дә табыла. Әдәбият һәм тел галимнәре төрки-татар әдәбиятына Ә.Ясәвинең йогынтысы Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәреннән башлап XVII-XVIII гасыр әдипләре Мәүлә Колый һәм Утыз-Имәни әсәрләренә кадәр чагылыш таба дигән бердәм фикердә тора. Шул сәбәпле, галимнәрнең XII гасырда болгар зыялылар катламы суфи-дәрвишләр тәгълиматы белән таныш булган, дип әйтергә хаклары бар [26].

Суфи-дәрвишләрне хак галимнәр һәм камил шәхесләр буларак данлап, Ә.Ясәви хакимнәргә, шәригать һәм әхлак сафлыгы сагында торучыларга, шул исәптән хөкемдарларга да нәфрәтен яшерми. Бер хикмәтендә, мөселманнар арасында әхлакый кыйммәтләр югала бару турында бәян итеп, автор бу гамәлләрдә барлык җәмгыятьне — түбән катлау вәкилләреннән алып гаделсезлек кылучы һәм закон бозучы түрәләргә кадәр гаепли. Шул ук вакытта Ә.Ясәви, камил рухи остазлар һәм хөкем чыгаручылар булганда, җәмгыятьнең бозыклыгы бары тик вакытлы күренеш икәнлеген анык аңларга мөмкинлек бирә [27].

Югарыда әйтелгәннәрне гомумиләш-

тереп, без түбәндәге нәтиҗәләрне ясыйбыз. Идел буе болгарлары тарафыннан ислам динен кабул итү иҗтимагыйхокукый мөнәсәбәтләрнең һәм мәхкәмә системасының үзгәрешенә алшартлар тудыра. Болгар җәмгыятендә казыйлар барлыкка килә, аларның халык арасында төп бурычы гадел хөкем кылу була. Ислам хокукый системасы Идел буе болгарларына, мәхкәмәбәхәс мәсьәләләрен хәл иткәндә, яңа принциплар алып килә һәм дәүләттәге мәхкәмә-хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала. Чираттагы мөһим вакыйга дип Рус дәүләте һәм Идел буе Болгарстаны арасында халыкара мәхкәмәнең яралгылары барлыкка килүен әйтергә мөмкин. Шул ук вакытта Идел буе Болгарстаны өммәте арасында бәхәсләрне төркиләрнең йола буенча килгән хокуклары нигезендә дә хәл итү мөмкинлеге кала. Югары мәхкәмә хакимияте булып хан үзе исәпләнә.

Искәрмәләр

1. История мусульманской мысли в Волго-Уральском регионе. — Казань: РИУ, 2010. — С.63.
2. Мухаметшин Р.М. Ислам в татарской общественной мысли начала XX века. — Казань: Иман, 2000. — С.19-20.
3. Адыгамов Р.К. Габдрахим Утыз-Имяни. — Казань: Издательство «Фэн» Академии наук Республики Татарстан, 2005. — С.96-97.
4. Березин И. Булгар на Волге // Учёные записки КГУ. Книга III. — Казань: Типография Казанского университета, 1852. — С.153-155.
5. Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. — М.: ИНСАН, 1991. — С.198.
6. Марджани Ш. Извлечение вестей о состоянии Казани и Булгара. Часть I. — Казань: Изд-во «Фэн» АН РТ, 2005. — С.101-102.
7. Измайлов И. Распространение и функционирование ислама в Волжской Болгарии // Ислам и мусульманская культура в Среднем Поволжье: история и современность. Очерки. — Казань: Изд-во «Фэн», 2006. — С.45.
8. Марджани Ш. Извлечение вестей… — С.101-103.
9. Измайлов И.Л. Великий волжский путь и распространение ислама в Поволжье // Великий волжский путь: история формирования и культурное наследие. Материалы III этапа Международной научно-практической конференции «Великий волжский путь». Часть II. — Казань: ИИ АН РТ, 2004. — С.36.
10. Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную Европу и Центральную Европу (1131-1151). — М.: Главная редакция восточной литературы, 1971. — С.37.
11. История Османского государства, общества и цивилизации: в 2 т. / под ред. Э.Ихсаноглу; Исслед. центр исламской истории, искусства и культуры; пер. В.Б.Феоновой под ред. М.С.Мейера. — Т.I. — М.: Восточная литература, 2006. — С.338-339.
12. Гаркави А.Я. Сказания мусульманских писателей о славянах и Хазарском царстве. — С.-Петербург: Типография академии наук, 1874. — С.129-130.
13. Губайдуллин Г. История распространения арабского права среди приволжских татар / Мухамадеев А.Р. Шариатская комиссия при Народном комиссариате юстиции ТАССР. — Казань: Изд-во ДУМ РТ, 2009. — С.86.
14. Гаркави А.Я. Сказания мусульманских писателей… — С.152.
15. Голубовский П. Болгары и хазары / «Киевская старина». — Т.XXII. — Киев, 1888. — С.64.
16. Ковалевский А.П. Книга Ахмеда ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921-922 гг. — Харьков: Изд-во ХГУ, 1956. — С.147.
17. Плетнёва С.А. Хазары. — М.: Изд-во «Наука», 1976. — С.58.
18. История татар… Т.II… — С.144.
19. Кул Гали. Сказание о Юсуфе. — Казань: Татар.кн.изд., 1985. — С.137.
20. Татищев В.Н. История Российская. — Т.III. — М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1964. — С.225.
21. Фахрутдинов Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. — М.: «Наука», 1984. — С.91.
22. Русские летописи. Воскресенская летопись. Подготовлена Цепковым А.И. по изданию: ПСРЛ. — Т.VII. — СПб., 1856. — Рязань: «РИНФО». — С.176.
23. Карамзин Н.М. История государства Российского. Книга I. — Ростов н/Д: Изд-во «Феникс», 1994. — С.448.
24. Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную Европу… — С.36-37.
25. Татар әдәбияты тарихы. — Т.I. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1984. — С.126.
26. Амирханов Р.М. Тюрко-татарская философская мысль средневековья (XIII-XVI вв.). — Казань: Изд-во «Мастер-Лайн», 2001. — С.45-46.
27. Амирханов Р.М. Тюрко-татарская философская мысль… — С.49-50.

Русчадан ***Ленар Гобәйдуллин***
тәрҗемәсе

XVII-XVIII ГАСЫРЛАРДА КӨНЬЯК УРАЛ ТӨБӘГЕНДӘ ЯШӘГӘН ТАТАРЛАР ТАРИХЫННАН*

ГАЯЗ СӘМИГУЛОВ,
тарих фәннәре кандидаты,
Көньяк Урал дәүләт университеты доценты (Чиләбе шәһәре)

1710 елда Эчкен авылында 47 хуҗалык хисапланган (158 ир-ат һәм 131 хатын-кыз), аларда отставкадагы һәм хезмәттәге 24 драгун, 3 казак улы, 11 оброк түләүче татар һәм күченеп килгән татарлар яшәгән. Авыл кешеләре арасында ике Сәйдәшев бар: отставкадагы драгун Колаш һәм казак улы Түләк [30]. Түләк – XVII гасыр азагы документларында чагылыш тапкан Сәйдәшевләрнең туганнарыннан берсе [31]. 1748 елда җир биләмәләре хакында рәсми расланган күчермәне Сәйдәшевләрнең нәсел дәвамчылары исеменнән «Аптигарим Апсалямов» (Сейдяшев?) алган. Ул бу документны үзе өчен дип кенә түгел, ә бөтен туганнары өчен сораган. Кызганычка каршы, туганнарының исемлеге сакланмаган. «Аптигарим» үзе Тубыл йомышлы татарларының писаре булып хезмәт иткән [32]. Шунысын да әйтеп китү зарур: Мехон кирмәнендә 1710 елда татар хуҗалыклары теркәлмәгән, ягъни П.С.Палласның мәгълүматы раслана: эчкен татарларының төп өлеше йомышлы татарлардан (Мехон кирмәне драгуннары) торган, алар XVII гасыр азагы – XVIII йөз башында кирмәннән Эчкен елгасы буена күченгән, халыкның бер өлеше XVII гасырның соңгы өч дистә елында Идел буеннан килеп утырган.

Сәйдәшевләрнең килеп чыгышы ачык түгел. Күрәсең, морзалар нәселеннәндер. Ни өчен дигәндә, алар – даими рәвештә, кимендә XVII гасыр азагына кадәр, үз фамилияләрен үзгәртмичә саклаган азсанлы татар нәселләренең берсе. Ләкин фамилия саклану аларга җир бирелү белән генә дә бәйле булырга мөмкин. Чөнки җир авыл җәмгыятенә түгел, ә бертуган Сәйдәшевләргә бирелгәнлектән, бу фамилия, мирасчыларны, варисларны ачыклау максатыннан, мәҗбүри сакланган булырга мөмкин.

Иң башта Мехон кирмәненнән чыккан татарлар Эчкен авылына килеп утыра, аннан якынча 1750 елларда Исет провинциясенең канцеляриясе аларга Әлмән күле районында, Каратабын һәм Баратабын исемле башкорт волостьлары җирләрендә биләмә

*Ахыры. Башы журналның 2013 елның 12 нче санында

бүлеп биргән. 1760 еллар азагында Исет провинциясенең канцеляриясе табынлылар, үзләренең вотчина җирләрен башта эчкенлеләргә, аннары катайлыларга бирү сәбәпле, бераз үпкә тоталар, дип яза [33]. Катайлылар җирне 1766 елда эчкен татарлары белән янәшә алалар [34]. П.С.Паллас 1771 елда Әлмәнкүл аша уза һәм: «Могильная авылы яки татарча — Әлмәнкүл. ... Бу авылда 20гә якын татар хуҗалыгы бар. Әлеге татарлар Эчкен казаклары нәселеннән. Картлар сөйләвенә караганда, моннан йөз ел элек, Бөек Пётрның яшь чагында, Казан провинциясеннән килеп, Эчкен суы Исет елгасына кушылган җиргә урнашканнар, хәзер саннары артты һәм 200 гаиләгә җитте. Алар Төче һәм Мияс елгалары буенда көн итә. Мещеряклар кебек үк, кирәк очракта хәрби хезмәт башкаралар, шуның бәрабәренә барлык салымнардан һәм рекрутлыктан азат ителгәннәр. Исеттән алып килгән карабодай игәләр», — дип яза [35]. 1773-1774 елларда Е.Пугачёв җитәкчелегендәге баш күтәрү вакытында авыл җимерелгән дип фаразларга була. 1770 елларның азагында — 1789 еллар башында ул кабат тергезелә. 1783 елга нисбәтле бер документта болай диелгән: «Могильная авылына Эчкен йортыннан (ягъни Исет буеннан — *авт.*) күченеп килгән Исмәгыйль Уразмәтевтә 30 хуҗалык» [36]. Эчкен татарларының башка төркемнәре һәм авыллары билгеле түгел. Әгәр дә аларның Әлмәнкүлдән (Могильная авылы) башка торак пунктлары булса, бу документларда — әйтик, чик буе хезмәтенә кешеләрне җибәрү исемлегендә яки шул хакта рәсми хат алышу кәгазьләрендә теркәлгән булыр иде. Әгәр башка авыллар булса, биредә яшәүчеләр турында, аларның Эчкен йортыннан күчүләрен искә алып, «эчкен татарлары», дип язарлар иде... Күрәсең, күченү процессы бик актив барган. 1786 елга нисбәтле бер документта Чиләбе өязендә эчкен татарларының өч авылы теркәлгән: «Могильная, Резяпова һәм Цаликульская» [37].

1795-1796 елларда уздырылган 5 нче ревизиядән (җан исәбен алу) соң төзелгән картада 4 авыл билгеләнгән: Учкулево (Өчкүл) яки Шабай, Тузово, Могильная (Әлмәнкүл), Вешняково яки Сорочья [38]. 5 нче ревизия буенча, аларда гомуми халык саны 415 ир-ат дип күрсәтелгән (шул исәптән Тузово, Могильная (Әлмәнкүл) авылларында — 235, Вешняковода — 62 һәм Өчкүлдә (Учкулево) — 118 ир-егет [39].

Паллас Эчкен татарларын тасвирлаганда, аларны йомышлы мещеряклар белән катыштыра диярлек — соңгылары ул елларда Төче елгасы буенда яшәгәннәр. Күрәсең, монда ике төркемгә керүчеләрнең дә статуслары буенча «йомышлы кешеләр» булуы тәэсир иткәндер. Бәлки, чынбарлык катлаулырак булып, әлеге төркем татарлар үзләре генә түгел, ә башка төркем вәкилләре өстәлү хисабына формалашкандыр. Аларның беришләре мишәр булган, моңа сөйләмдәге «ц»лаштыру, ягъни «ч» авазын «ц»га алыштыру ишарә ясый («Эчке» урынына — «Ицке», Өчкүл урынына — Өцкүл яки Цаликүл) [40].

1761 елда П.И.Рычков болай дип яза: «Шушы ук провинциядә (Исет провинциясендә — *авт.*) 166 йомышлы мещеряк, 31 сарт, 32 аюк калмыгы — һәммәсе 229 хуҗалык бар. Җан исәбен алу мәгълүматлары буенча, 419 эчкен татары, 196 бәгәрәк татары бар — һәммәсе 615 җан. Шулардан эчкен һәм бәгәрәк татарлары ярты ясакта булган, хәзер исә, барлык башкортлар кебек үк, ясактан чыгарылганнар» [41]. Әлеге мәгълүматлар П.И.Рычковның Фәннәр академиясеннән юллаган анкета сорауларына Исет провинциясе канцеляриясендә 1761 елда язылган җаваплардан алынды [42], шул сәбәпле мәгълүматны дөрес дип санарга нигез бар. Эчкен татарларының күпчелеге бу вакытта Исет елгасы буенда яшәгән. П.И.Рычковның эчкен һәм бәгәрәк та-

тарлары турында алар «барлык башкортлар кебек үк» дигән фразасы игътибарга лаек. Биредә, әлбәттә, этник группа түгел, сословие күздә тотыла. Ягъни әле Башкорт-Мещеряк гаскәре оешканчыга кадәр, рус булмаган халык вәкилләре охшаш хокукларга ия булган, охшаш бурычлар үтәгән йомышлы кешеләр дип кабул ителгән. Әлбәттә, искәрмәләр дә булган.

Күченеп килгән эчкен татарлары яңа волость төзегәннәр. Руслар аны Могильный дип (Әлмәнкүл авылы һәм күленең рус варианты — Могильный атамасы нигезендә) йөрткәннәр. Төркемнең бер өлеше Эчкен елгасы буенда кала. Андагы вакыйгалар вотчина җирләрен югалтуга китерә.

Димәк, XVIII гасырның соңгы утыз елында Сәйдәшевләр Эчкен авылыннан ерак түгел урында Сибиркино авылына нигез салалар. Соңрак Сәйдәшевләр белән Эчкен авылы кешеләре арасында низаг чыгып, эчкенлеләр Сәйдәшевләргә җир биләмәләреннән, печәнлекләрдән, урманнан һ.б. файдалануны тыялар. Сәйдәшевләр Пермь өяз мәхкәмәсенә шикаять бирә, мәхкәмә алар ягына баса. Эчкен авылы кешеләре исә, мәхкәмә карарына апелляция язып, хакимияткә юллыйлар, ахыр чиктә Пермь губернасының Гражданнар мәхкәмәсе палатасы «бу җирләр фәкать яшәү өчен бирелгән, ә хезмәт өчен түгел, димәк, алар дәүләт җирләре», дигән карар чыгара [43]. Эчке эшләр министрлыгына мөрәҗәгать итү файда бирми — мәхкәмә карары үз көчендә калдырыла. Шулай итеп, Эчкен авылы тирә-ягындагы җирләр дәүләтнекенә әйләнә. Документлардан озакламый бу җирләр башкортларга бирелгән дигән тәэсир кала. 1841 елда инде «элеккеге хәрби припущенниклар булган Эчкен авылы казаклары» турында һәм «Эчкен һәм Сибиркино авыллары башкорт вотчинникларының» җирләре турында сүз бара [44]. Чынбарлыкта нәрсә булганын әле ныклап өйрәнәсе бар. Кызганычка каршы, хәзергә әлеге мәсьәлә буенча кулда тарихи чыганаклар юк, шуңа күрә гомуми фаразлар китерергә генә мөмкин.

Биредә яшәүчеләрнең тагын бер төркемен Синар һәм Бәгәрәк елгаларының аскы агымында урнашкан татар авыллары тәшкил иткән. Әлеге торак пунктлары турында чыганакларда шактый тулы мәгълүмат сакланган. Бу мәгълүмат Салзаут (Сальют) волосте башкортлары, Катай кирмәне һәм Бәгәрәк бистәләре арасындагы җир мәсьәләсе буенча низаг эшендә тупланган. Эш Казан һәм Себер заводлары Баш идарәсе тарафыннан Исет провинциясе канцеляриясе катнашында 1740 елларда карала. Материалларда төрле авыл кешеләреннән сораштырулар да теркәлгән, аларда торак пунктларының кайчан нигезләнүе, кешеләрнең кайчан һәм кайдан күченүләре турында хәбәрләр бар.

Документларга таянып, хәзерге Чиләбе өлкәсендәге иң борынгы авыл дип Усман авылын санарга кирәк. 1745 елгы сораштырулардан бирегә беренче күченүчеләрнең кимендә 60 ел элек, ягъни якынча 1685 елда килеп төпләнүләре ачыклана. Шуларың берсе — 108 яшьлек Исәкәй Кадерголов җан исәбен алган вакытта әле исән була [45]. XVIII гасыр документларында бик еш «Асманово» яки «Османово» [46] дигән авылдан бу төбәктә «Усть-Багарякские юрты» дип аталачак авыллар төркеме оеша. Бу торак пунктларында яшәүчеләрне «бәгәрәк татарлары» дип атап йөртә башлыйлар. Авыл исеме, күрәсең, 1745 елгы исемлектә теркәлгән бер авыл кешесенең атасы, җан исәбен алу үткәрелгәнче, 16 ел элек үлеп киткән Зәет Госманов («Заит Асманов») [47] исеменнән килеп чыккан. Усман авылында һәммәсе 24 хуҗалык башлыгын сораштыралар. Якындагы өч авылның исеме билгеле: Түбән Синар (Нижнесинарская) яки Бәгәрәк, Яңа авыл (Давыдково (Даутово)) һәм Ключевская (Ключики).

Түбән Синар авылы — Синар елгасы буенда, аңа коя торган Бәгәрәк елгасын-

нан аз гына өстәрәк. 1745 елда биредә 31 ясаклы татар хуҗалыгы теркәлгән [48]. Яңа авыл (Даутово яки Давыдково) Түбән Синардан елга буенча түбәнрәк урында булып, биредә шул елда 24 ясаклы татар хуҗалыгы һәм 15 йомышлы мишәр хуҗалыгы исәпләнгән [49]. Елга агымы буенча тагын да түбәндәрәк 14 хуҗалыктан торган Ключевская (Ключики) авылы булган [50]. Документлар күрсәткәнчә, әлеге өч авыл кушылып, бүген бер Бәгәрәк тамагы (Усть-Багаряк) торак пунктын тәшкил иткән. «Усть-Багарякские юрты» атамасы 1736 елда ук Бәгәрәк һәм Синар елгаларының түбән агымында урнашкан шушы өч авылга карата кулланылган [51], кайбер очракта аларны гомумиләштереп, Усть-Багаряцк авылы дип йөрткәннәр [52].

Авыл кешеләре кайдан һәм кайчан күченеп килүләре турында җентекләп сөйләмәсәләр дә, булган материаллар кайбер кызыклы детальләрне ачыкларга мөмкинлек бирә. 70 яшьлек Антык Кепаков (Кибәков) исемле Түбән Синар авылы кешесе Усман авылында тууын, Түбән Синарга сораштыруга кадәр 30 ел элек күченеп килүен хәбәр итә [53]. Бу мәгълүмат дөрес икән, Усман авылы инде 1675 елда оешкан һәм башка исем белән аталып йөртелгән булып чыга. Алда без телгә алган Исәкәй Кадерголов: «60 ел элек рөхсәтсез-нисез генә хәзер Асманов авылы урнашкан җирдән күчендем», — дип сөйли. Шунысы кызык: күченүче бер ул гына булмаган. Бирегә «туганнар белән һ.б. татарлар белән килешеп килдем» [54], дип искәртә ул. Кибәковның 1745 елга кадәр 70 ел элек Асманов авылында туганлыгын әйткән идек инде. Димәк, Усманның (Асман) Чиләбе өлкәсендә иң борынгы татар авылы булуы документлар белән раслана. 1744 елда рус һәм башкорт җирләрен межалаганда, Исет провинциясенең канцеляриясе тарафыннан Усман (Асман) авылы җирләрен читләтеп үтү турында әйтелә, чөнки «биредәге борынгы торак пункты анда рус авыллары оешканчы ук яшәгән» [55].

Болардан тыш, сораштыру документларында инде бу вакытка яшәүдән туктаган торак пунктлары турында да мәгълүмат теркәлгән. Өч кеше үзләренең Түбән Синарга Усман авылыннан — Бәгәрәк елгасының аскы агымында урнашкан Кормаштан килүләрен, бу авылның инде (сораштыру уздырган вакытта, 1745 елда) юкка чыкканлыгын хәбәр итә. Кормаш авылында туып, Түбән Синарга күченүчеләрнең иң өлкәненә 72 яшь була [56]. Бәгәрәк елгасы тамагында XVII гасыр азагы — XVIII йөз башында Бабиково (Бәбек) һәм Айметево (Аймәт) авыллары урнашкан, алар да сораштыру вакытында инде яшәүдән туктаган була [57]. Болардан тыш, Катай кирмәне карамагында XVII гасыр уртасында ясаклы татарларның Кадергол исемле авыллары булып, анда яшәүчеләр «башкортларның баш күтәрүләре» вакытында, күрәсең, 1662-1669 елларда, Эчкен йортларына күченгән. Әлеге нәтиҗәне Исәкәй Кадерголов хикәяте белән танышкач ясадым. Эчкен йортында утыз елдан артык яшәп, ул Усман авылына 60 ел элек килеп төпләнгән [58]. Исәкәй Кадерголовның Эчкен йортында 30 ел яшәве турында сөйләвен, аның өлкән яшьтә икәнлеген исәпкә алсаң, чынлыкта бу арттырып сөйләүгә охшаган. Язманың башында Эчкен татарлары, Катай кирмәне һәм аерым яки берничә авыл булып көн күргән татар крестьяннары искә алынган иде. Кадерголның шул Катай кирмәненә урнашкан татар авылы булу ихтималы юк түгел. Камен бистәсендә XVIII гасыр башында Сәнгел исемле авыл булганлыгы мәгълүм [59].

Синар һәм Бәгәрәк елгалары буендагы санап үтелгән дүрт авылда яшәүчеләрнең күпчелеге элегрәк Көньяк Уралда — «Уфа провинциясендә» көн күргән. Аларның биредә төгәл кайчан яшәгәнлекләрен ачыклау мөмкин түгел, чөнки XVIII гасыр башы авыл

исемнәренә карап кына, аерым очракларны исәпкә алмаганда, моны эшләп булмый. Шундый «аерым очрак»ка Эчкен һәм Терсәк (Терсют (Терсяк)) йорты керә. Соңгысыннан Яңа авылга 6 кеше, шул исәптән ясаклы татарларның сотнигы Морзагол Исәнбаев күченгән. Аның сүзләренә караганда, ул туган төбәгенә русларның «вольница»сыннан соң күченеп киткән [60]. «Вольница» — рус крестьяннарының отрядлары — гадәттә, башкорт восстаниеләре вакытында, регуляр гаскәрләрнең баш күтәрүчеләр белән көрәштә көчләре җитмәгәндә оештырылган. Шуңа күрә татарларның Терсәк йортыннан яңа авылга күченүләре 1705-1709 еллардагы баш күтәрү вакытында яки тагын да иртәрәк булырга тиеш.

Бәгәрәк тамагы йортында яшәүчеләр «биш гривеньле ясак» түләгәннәр, 1754 елда әлеге бурычтан азат ителгәннәр һәм үзләре яшәгән җирләр бирелгән [61]. Нәкъ шушы 1754 елда Бәгәрәк тамагы йорты йомышлы татарлары төркеме оеша, дип әйтергә нигез бар. Бу төркем составына элекке ясаклы татарлар, Синарның һәм Бәгәрәкнең түбән агымында урнашкан авылларда яшәгән мишәрләр керә. Бәгәрәк тамагы йорты татарлары һәм сан ягыннан бик күп тапкыр артык булган ясаклы татарлар арасында (XIX гасыр — XX йөз башында) мишәр үзаңы формалаша. Шунысы кызык: үзләрен мишәр дип Усман (Асман), Яңа авыл, Түбән авыл кешеләре дә атый. Н.Ю.Зограф алар турында болай дип яза: «Мещерякларның үзләренең хикәяләве буенча, алар ике — җирле һәм күченеп килгән кабиләләр кушылу нәтиҗәсендә оешкан» [62]. Д.М.Исхаков та бу авыл кешеләренең 1920 елларда үзләрен мишәр дип санаулары турында яза [63]. Әлегә мишәр үзаңы ни өчен җиңеп чыкканлыгын әйтүе кыен.

Кечкенә кенә өстәмә. Бәгәрәк тамагы йорты ясаклы татарлары арасында бер өлеш православие динендәге яки православие динен тотучыларның нәсел дәвамчылары — руслар да булган. Мисалга берничә исем атап үтәм: Усман авылында Савелий Мокшин һәм Усейн Тимофеев [64], Иванай авылыннан Түбән Синарга күченеп килгән Аднабай Иванов [65], ә ясаклы татарларның старшиналары Иктабан Степанов исемле булган [66]. Бу сирәк очрый торган хәл түгел: рус фамилияләрен — аталары исемнәрен йөртүчеләр башка авыл кешеләре, шул исәптән эчкен татарлары арасында да булган. Мәсәлән, берсе — Иван Иванаев, икенчесе — Упазай Иванов исемле [67]. Кайберләренең чыгышлары белән татар булмаганы ачык (Савелий Мокшин), башкаларының кем булулары билгеле түгел. Бәлки, алар чукынган халык вәкилләре булып, җирле татарлар төркемен оештыруда катнашкандыр. Православие исемнәре «оберег» кебек бирелгән булуны да инкарь итәргә ярамый. Мәсәлән, руслар балаларын Ненаш, Найден, Ибрагим дип атаган. Ягъни чит-ят исем кешене сакларга тиеш булган. Арада исламга кабат әйләнеп кайткан татарлар да булырга мөмкин. Хәзергә ниндидер нәтиҗәләр ясарга әле иртәрәк.

«Йомышлы мещеряклар» дип аталучылар да сан ягыннан күп түгел. Көньяк Уралга төрле төбәкләрдән килеп урнашкан бу кешеләр төрле авылларда яшәгән.

Алар 1730-1740 елларда Мөслим Аширов (аны кайбер документларда «полковник» дип атаганнар) җитәкләгән командага берләшкән. И.Кириллов җитәкчелегендәге Оренбург экспедициясе эшчәнлегенә каршы кабынган башкорт восстаниесе кызган 1736 елда, ул чордагы Уфа провинциясенең төньяк-көнчыгышында яшәгән йомышлы мещеряклар һәм ясаклы татарлар, Енисейская пехота полкы майоры Шкадерга куркыныч туган очракта, гаиләләре белән рус бистәләренә күчәргә рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәләр [68]. Гаризадан тыш, архив эшендә «реэстрлар», ягъни авыл кешеләренең исемлекләре дә сакланган [69]. Әлеге

исемлекләрне тулы түгел дип фаразларга мөмкин, төзелү тәртибенә караганда, алар шактый буталчык язылган: башта бер авыл кешеләренең исемнәре бирелә, тагын берничә авыл кешеләре исемлегеннән соң, кабат теге авыл буенча беренче язганда төшеп калган кешеләр теркәлә. Гомумән алганда, авыл исемнәре һәм ир-атлар саны язылган мәгълүматлар файдаланырга ярарлык. Аларны гомумиләштергән таблица да төзелә. Авылларның бер өлеше (Алчаево, Новая, Улугуш) катнаш торак пунктлары була. Өч авыл чиста татар исемнәрен йөртә. (Бу авылларда ясаклы татарлардан тыш башкаларның яшәве документларда искә алынмый.)

11 мещеряк авылы, шуларның дүртесендә — берәр, берсендә — ике, калганнарында алтыдан алып унбергә кадәр хуҗалык була. Болардан тыш, Урал артының әлеге төбәгендә мещеряклар һәм ясаклы татарлар яшәгән башка торак пунктлары да урнаша. Әйтик, инде телгә алынган Бәгәрәк тамагы йорты. Бу авылда 1736 елны йомышлы мещерякларның 22 хуҗалыгы теркәлгән, биредә яшәүчеләрнең составы катнаш булырга да мөмкин [70]. Башка документта өч Бәгәрәк тамагы йорты, ягъни ясаклы татарлар яшәгән өч авыл телгә алына. Исемлектә 40 ир-ат теркәлгән. Ул тулы түгел, фәкать өлкән ир-атлар гына язылган, башкорт восстаниесен бастыру өчен оештырылган рус «вольница»сы, булмаган указга нигезләнеп, әлеге кешеләрнең коралларын һәм ат дирбияләрен талап алган [71]. Болардан тыш, Тичә бистәсе җирләрендә — Терекүл күле янында — Ибрай исемле мещеряк яшәгән бер хуҗалыктан торган авыл булган [72]. Шулай итеп, әлеге «реэстр»да язылган авыллар һәм аларда яшәүчеләрнең исемлеге тулы түгел. Без бүген исемлеккә ничә торак пунктының керми калганын якынча да әйтә алмыйбыз. Шулай да 1736 елда кайбер башкорт булмаган авылларны санап үтәргә мөмкин. «Реэстр»дагы мәгълүматларга таянып, түбәндәге таблицаны төзедек.

Таблица №1

УФА ПРОВИНЦИЯСЕНЕҢ ТӨНЬЯК-КӨНЧЫГЫШЫНДА
1736 елда урнашкан йомышлы мещеряк һәм ясаклы татар авыллары*

Ясаклы татар авыллары	Йомышлы мещеряк авыллары	Татарлар, ир-атлар	Мещеряклар, ир-атлар	Һәммәсе, ир-атлар
Алчаево	Алчаево	20 (11 гаилә)	24 (13 гаилә)	44
	Арыково		1	1
	Атикчи		15 (8 гаилә)	15
	Епарово (Япарово)		1	1
	Еумбаево		13 (6 гаилә)	13
	Карабулак (Караболак)		30 (11 гаилә)	30
Кутукаево		4 (1 гаилә)		4
Кызылташево		41 (22 гаилә)		41
	Мишли		1	1
Новая	Новая	28 (12 гаилә)	20 (11 гаилә)	48
	Нураево		18 (10 гаилә)	18
	Пермяково		1	1
	Токшаково		2 (2 гаилә)	2
	Тюбук		21 (9 гаилә)	21
Улугуш	Улугуш	22 (12 гаилә)	26 (10 гаилә)	48
	Уразаево		20 (8 гаилә)	20
Шешма		25 (11 гаилә)		25

*Свердловск өлкәсенең дәүләт архивы. 24 нче ф. 1 нче тасв. 626 а эш. — Б.128.

Мещерякларны һәм ясаклы татарларны, шулай ук башка башкорт булмаган авыл кешеләрен рус бистәләренә күченергә нәрсә мәҗбүр иткәндер, әйтүе кыен. Бу вакыйга, күрәсең, 1736 елның яз-җәй айларында булган. Башкорт булмаган авыл кешеләренең туган йортларын калдырып китү сәбәбе: аларның элекке хуҗалыклары таланган — моны кайбер документлар раслый. 1736 елның августында В.Н.Татищев Себер губерна идарәсенә промемория юллый, анда ул башкортлар буйсындылар, «мещеряклар элекке йортларына кайттылар һәм тынычлыкта калдырылдылар», дип яза [73]. Шул ук елның август башында В.Н.Татищев А.И.Тәвкилевкә түбәндәгеләрне юллый: «Месчеряки и ясашные, как вам известно, что оставя домы свои, жили в русских деревнях, лето все противо воров служили и во отлучение их домы от воров позжены, кони скот и пожитки пограблены, жалованье же им дано от меня толко по полтора рубли, и более без указа дать не смею, того ради они все отпусчены в домы, чтоб могли есче что либо посеять и сен приготовить, а в поход их без крайней нужды не требовать» [74]. Тәвкилев бу вакытта Көньяк Уралда, Югары Җаек (бүген Верхнеуральск шәһәре) пристаненә бару юлында, кирмәннәр төзүче җыелма отряд белән җитәкчелек иткән. 1736 елда Чибәркүл, Миасс һәм Чиләбе кирмәннәре корыла.

Күрәсең, 1736 елның августында Татищев Тәвкилевкә генерал-поручик А.И.Румянцевның яңа төзелгән кирмәннәр янында «чирмешләрне, мещерякларны һ.б.» урнаштырырга дигән рекомендациясен тапшырган. Моңа Тәвкилев болай дип җавап биргән: «на оное покорно доношу при мне означенных иноверцов ныне никого нет, да и за нынешним их разорением сей осени никак им строением управиться не уповаю» [75]. Полковникның шиге урынлы, чөнки ул хатны 20 августта ала, һәм мещеряклар, һәм мариларның чынлыкта яңа урынга килеп урнашырга мөмкинлеге юк, бу таланган кешеләрне беркем дә азык-төлек белән тәэмин итәргә җыенмый, аларны кирмәннәр янына китерүдән артык мәгънә дә булмый.

Шулай итеп, 1736 елны мещеряклар элеккеге йортларына, хуҗалыкларына, төгәлрәк әйтсәк, аларның харәбәләренә кире кайталар. Башкорт восстаниесе дәвам итә, мишәрләрнең проблемалары моның белән генә чикләнми. Император галиҗәнапларының 1736 ел, 11 февраль указының 1 нче пунктында болай дип язылган була: «Служилым Мещерякам, от Башкирцев быть отдельно, и за их верность и службу… земли угодьи те, коими они по найму у Башкир владели, а те Башкирцы были в воровстве, в бунте: те дать им вечно безоброчно, указныя дачи, первому Старшине — 200, Ясаулам, писарю, Сотникам — по 100, рядовым — по 50 четвертей, и за претерпенной убыток от воров Башкирцев, обещать награждение» [76]. Ләкин, В.Э.Ден бик хаклы билгеләп үткәнчә, хөкүмәтнең бу мәсьәләгә карашы үзгәреш кичерә [77]. 1838 елның 17 мартында В.Н.Татищевка, Оренбург экспедициясенең җитәкчесенә, юлланган боерыкта болай дип хәбәр ителә: «Мещерякларны башка урыннарга һәм аерым авылларга күчерүне ашыктырмаска…» [78].

Йомышлы мишәрләрнең алдагы тарихын күзәтүдә Чиләбе өлкәсе берләштерелгән архивының Чиләбе өязе түбән расправасы фондында саклана торган берничә документ ярдәм итә. Беренче документ 1785 елда булган эштә күчермә рәвешендә сакланган, ул — 1742 елның 20 маенда язылган Исет провинциясе канцеляриясенең провинциядә йомышлы мещерякларга җир бүлеп бирү турындагы указы. Бу указда мәсьәлә бик җентекләп яктыртылган. Аның кыскача эчтәлегенә тукталыйк. Документта яшерен советник дәрәҗәсенә ия булган В.Н.Татищевның полковник һәм Исет провинциясе воеводасы И.Н.Татищевка 1738 елда

бирелгән наказының (11 нче пункт) эчтәлеге дә бирелгән [79]. Югарыда без императорның 1838 ел, 17 март көнне чыккан указыннан өзек китергән идек. Анда ачык итеп, хәзергә мещерякларга элекке җир биләмәләре белән канәгать булып торырга кушылган. В.Н.Татищев исә «Урал артында мещеряклар һәм ясаклы кешеләр аз булуын» искәртә, «аларның башкортлар арасында көн күрүен, аерым авылларда яшәмәүләрен сылтау итеп, Тубыл ягында төзелгән кирмәннәр артына, уңайлы урыннарга авыллап-авыллап урнаштырырга» боера [80]. Күрәбез, В.Н.Татищев, болай язып, бераз хәйләли. Мещеряклар һәм ясаклы татарлар күп очракта башкорт авылларыннан читтә яшәгән. Ләкин элекке җирләрдә калу аларның 1736 елгы указ аркасында күрелгән зыянны каплау һәм хәрби хезмәт өчен вәгъдә ителгән җир биләмәләрен алу мөмкинлеген юкка чыгара. Шуңа күрә В.Н.Татищев, император Анна Иоанновнаның күрсәтмәсен читләтеп үтү өчен, шундый хәйлә юлына баса. Восстание 1740 елда гына бастырыла, бу шартларда мишәрләрне Тубыл ягына күчерү кулай юл түгел. Соңрак та, Уй һәм Себер линиясе кирмәннәре төзелеп беткәч, Тубыл ягы, чик буе зонасы булу сәбәпле, иң хәвефле урын исәпләнә. В.Н.Татищев 1739 елда император галиҗәнаплары кабинетына мөрәҗәгать итә: мещерякларга, татар һәм чувашларга җир бүлеп бирү мәсьәләсен куя. Татищевтан соң Оренбург комиссиясе җитәкчесе итеп билгеләнгән генерал-лейтенант кенәз Урусовка башкаладан мондый эчтәлектәге күрсәтмә килеп төшә: «от 20-го августа того ж году между протчим в 10-м пункте написано о взятых у башкирцов землях и об отдаче мещерякам за их верности и чтоб оными землями им мещерякам впредь владеть вечно без платежа ясака и о поселении мещеряков татар и чюваш особыми деревнями быть по представлению оного тайного советника Татищева: и того ради по ея императорскаго величества указу генералом лейтенантом князем Урусовым определено, чтоб по прошению мещеряков старшины Муслюма с товарищи о поселении их внутрь от крепостей по лежащей к Оренбургу дороге, по речке Тече вверх по обе стороны, с таким от крепости расстоянии, чтоб не захватить подлежащих крепостям земель и угодий» [81].

Шулай итеп, 1742 елда старшина (полковник) Мөслим Әширов җитәкчелегендәге йомышлы мещерякларга Тичә елгасы буенча җирләр бүлеп бирелә, шулай ук зур бер биләмә елгадан төньякта — Чабак (Чибәркүл), Уелгы, Аликуль күлләренә кадәр булган урында бирелә. Көнбатыштан һәм төньяктан аларның җирләре — Бала-Катай волосте башкортлары биләмәләре белән, көньяктан — Чиләбе һәм Миасс кирмәннәре җирләре белән, көнчыгыштан Тичә бистәсе (Рус Тичәсе) белән чиктәш чыга [82]. Җәмгысе 100 йомышлы мишәр хуҗалыгы күченергә тиеш була [83]. Бу урыннарда Мөслим, Корман, Коншак, Борис [84] һәм Субин (Тишки күле янында) дип аталган авылларга нигез салына [85]. Яңа оешкан торак пунктларына кешеләр 1 нче таблицада күрсәтелгән төрле авыллардан күченеп утыра. Соңрак, күрәсең, 1740 елның азагында, мещерякларга Чүмләк елгасының сул як ярындагы җирләр бирелә (бүгенге Курган өлкәсенең Сафакүл районы территориясе). Мещеряклар 1767 елның язында Уложение комиссиясенә юллаган наказларында болай дип белдерәләр: «…безгә Тичә һәм Чүлмәк (Чүмләк — *авт.*) елгалары буендагы җирләр белән канәгатьләнергә кушылды, шулар буенча ызан сызылды» [86]. Сотник Мөслим Әширов кешеләренә Тичә елгасы буенда бирелгән җирләр Мещеряк волосте яки Югары-Тичә волосте дип атала башлый, соңгы атама ешрак кулланыла.

Чүмләк елгасының уң як ярындагы җирләр мишәрләр биләмәсенә керсә дә, Исет провинциясе юкка чыгарылганга, ягъни 1781 елга кадәр, күченүчеләр,

нигездә, Тичә елгасы, Коншак һәм Тишки күлләре янындагы җирләрне үзләштерү, эшкәртү белән шөгыльләнә. Тичә елгасыннан төньякта урнашкан җирләр Пермь наместничествосы карамагына күчкәч, 1781 елда хәл үзгәрә, Чиләбе Уфа наместнигында кала. Оренбург губернасы да 1782 елда элекке хәлендә яшәүдән туктый — биредә наместниклык формасындагы идарә системасы кертелә (Уфа наместниклыгы). Әле элегрәк, 1782 елга кадәр, яңа оештырылган Чиләбе өязе башта Пермь, аннары Уфа наместниклыгына тапшырыла. Исет провинциясе җирләрендә XVII гасыр — XVIII йөз башыннан бирле яшәгән йомышлы мишәрләрнең күп өлеше төньяк төбәкләрдә көн күрә: компактлы төркем Тичә елгасы буенда һәм Коншак, Тишки, Уелгы күлләре янында, Синара, Бәгәрәк, Караболак елгалары буенда урнашкан авылларда яши. Күрәсең, хәзерге Сафакүл районы җирләрендә инде бу вакытта (1780 еллар) мишәр авыллары булган. Һәрхәлдә, әлеге фараз файдасына кайбер дәлилләр бар.

1782 һәм 1783 елларда Мөслим, Коншак һәм Курман авылларында яшәгән мишәрләргә ике «билет» — Далмат округыннан (бу авыллар наместниклыклар оештырганда, шул административ берәмлеккә кертелгән була) Чиләбе өязенә күченергә документ тапшырыла. Бер билет — 70 хуҗалыкка, икенчесе 30 хуҗалыкка бирелә, җәмгысе 100 хуҗалыкны күчерү планлаштырыла. Алар «яңа бүлеп бирелгән җирләрдә урнашырга тиеш була» [87]. 1742 елгы указдан соң бирелгән җирләр «яңа бирелгән җирләр» дип хисапланган. 1784 елда 100 хуҗалыкның 56сы — мещеряк авылы, 6сы «биредәге Чиләбе округындагы Мансур, Карасево, Әҗитәр һәм Тишки (Субин — *авт.*) күле янындагы Чибин исемле мещеряк авылларыннан күченә» [88]. Ягъни санап үтелгән авыллар инде моңа кадәр үк яшәгән булып, өязләр арасында чик сызганда, Чиләбе өязе ягында калган. Төгәлрәк әйтсәк, Әҗитәр һәм Мансур авыллары аңа кадәр дә булган, ә менә Карасу (Карасево) күле янындагы авыл 1783 елгы документларда яңа оешкан торак пункты буларак билгеләнгән [89]. Башка мишәр авыллары (Какчерлино, Сафакүл, Сюлюклино), күрәсең, соңрак барлыкка килгән. Аларга нәкъ менә теге элекке Мөслим, Коншак һәм Курманово авылларында калган 44 мишәр гаиләсе һәм бу вакытка инде Верхнеуральскига якынрак урнашкан, ләкин кире ияләнгән төбәккә кайтырга ниятләгән башка гаиләләр дә күченгән. Исет провинциясендәге йомышлы мещерякларның бер өлеше, Оренбург ведомствосыннан чыгарга теләмичә, 1780 елда ук, Уклы-Карагай һәм Уйга күчерүне сорап, гариза биргән була. Шул ук елда рөхсәт кәгазе алып, старшина Габди (Абди) Биктимеров һәм ахун Абдулла Мөслим углы Даушев (1667-1668 елларда эшләгән Уложение комиссиясе депутаты) җитәкчелегендә 40 хуҗалык Урал елгасының югары агымына барып нигез кора [90]. Дөрес, әүвәл, гаиләләрен элекке урында калдырып, ир-атлар күченә. Ләкин тиздән Чиләбе өязенең Пермь наместниклыгыннан Уфа наместниклыгына тапшырылуы билгеле була (ягъни шул ук Оренбург губернасына) һәм күченүчеләрнең бер өлеше, Чиләбе өязендәге элекке җирләрдә яшәргә рөхсәт сорап, яңа гариза бирә [91].

Нәтиҗәдә, яңа урында, Верхоуральски дистанциясендә 19 гаилә кала, араларында илледән артык ир-ат була, алар белән «ахун һәм депутат Абдул морза» Мөслим углы Даушев җитәкчелек итә. Бу төркем күченүчеләр, күрәсең, бүген Башкортстанның Өчиле районында урнашкан Ахун исемле зур авылга нигез салган. Старшина Габди Биктимеров җитәкчелегендә 21 гаилә кире Чиләбе өязенә кайтырга уйлый. Аларның бер өлеше Мещеряк волостенда, Чүмләк елгасы буенда оешып килгән авылга китеп төпләнә.

Болардан тыш та күченүче төркем-

нәр була. 1786 елда Чиләбе түбән земствосы судына Уфа наместниклыгы идарәсеннән боерык килә, анда Сембер наместниклыгыннан Уфа наместниклыгына күченгән 12 йомышлы татар турында әйтелә. Указда аларның соңгы ревизия буенча җан башыннан салым түләү-түләмәүләрен ачыкларга кушыла. Кызганычка каршы, бу документта фәкать бер кешенең (күрәсең, күченүчеләрнең инициаторы) — Алтынбай Әбсәлимовның исеме генә язылган. Аларның кайда урнашуларын — эчкен татарлары яки йомышлы мещеряк авылынамы — без белмибез. Идел буеннан бу якларга күпләп күченү XIX гасырга туры килсә дә, мондый төркемнәр берәү генә булмаган. Мещерякларны да, башкортларны да «тулыландырып» торган тагын бер төркем — даладан күченгән казахлар. Аларны, 10 елга салымнардан азат итеп (күрәсең, алар чик буен саклау хезмәтен дә 10 ел буе башкармаган), башкорт, мещеряк авылларына урнаштырганнар. Мәсәлән, 1811 елда Әҗитәр авылына — 4, Сафакүлгә 5 казах килеп урнаша [92].

Әмма барлык мишәрләр һәм йомышлы татарлар XVIII гасыр уртасында элекке авыллардан яңа волостька күченмәгән. Караболак авылы кешеләре шәхси җир биләмәләренә ия булган. Караболак исемле мишәр авылы кешесе Мостафа Аликиев 1781 елда ызаннарны тикшергәндә әйткәнчә, «от оной же речки Тургаку начнётца их Караболское владение, уступленное им от Мякотинской волости башкирцов, вечное владение из оброку, по указу из Исетцкой провинциальной канцелярии 1744-го году марта 20-го числа» [93]. Бүген бу — Чиләбе өлкәсендәге Татар Караболагы авылы.

Төбәк исемле мещеряк авылының язмышы исә икенче төрле була. 1744 елда биредә яшәгән кешеләр арасында Төбәктә туганнар булмый, беренче күченүчеләр бирегә 39 ел элек килә. 1744 елда, шул ук Исет провинциясе канцеляриясенең указы нигезендә, Караболак авылы кешеләре кебек үк, Төбәк авылы халкы да, оброктан азат ителеп, җирләренә хосусый милек хокукы ала. Моңа нигез булып без телгә алган, башкортлардан җир сатып алырга мөмкинлек биргән 1736 елгы указ тора. Әлеге авылда 80 хуҗалык булыр дип уйланыла [94]. 1 нче таблицада 1736 елны Төбәк авылында 9 хуҗалык күрсәтелгән, 1744 елда аларның саны 18гә җиткән. 1750 елда Мякотин волосте башкортлары һәм Төбәк авылы йомышлы мещеряклары белән килешү нигезендә, элек мишәрләргә бирелгән җирләрнең бер өлеше Арамил бистәсеннән яшәү өчен Төбәккә күченгән 15 хуҗалыкка бирелә. Моның бер сәбәбе булып мишәрләрнең һәр елны 80 хуҗалык исеменнән (чынлыкта аларның саны күпкә аз булса да) 16 сум оброк түләүләре тора [95]. Соңрак мишәрләр Төбәкне калдырып китә. Моның кайчан булганын төгәл әйтеп булмый — әлегә документлар табылмады. 1754 елда Салзаут (Сальют) волосте башкортларыннан сатып алынган җирләрне тасвирлаганда, ориентирның берсе итеп мещеряк авылы — Төбәк күрсәтелә [96]. Күрәсең, озак та үтми Төбәк авылы җирләре башкортларга сатылгандыр. Анда яшәүчеләр төрле җирләргә күченеп киткән. Ул вакытта ук инде йомышлы мишәрләрнең бер өлеше Югары Җаек (хәзерге Верхнеуральск) кирмәне янына, ягъни бүгенге Башкортстанның Өчиле районына күченә. Бәлки, Төбәк авылының башка мишәрләре дә соңрак шунда юнәлгәндер. Кыскасы, Төбәк алпавыт авылына әйләнә, аның яңа атамасы, биредә төзелгән чиркәү исеме белән, Богословское булып китә. П.С.Паллас 1772 елда биредә вакытта, әлеге торак пунктының элек татар авылы булганлыгы турында истәлекләр генә ишетә.

XVIII гасырда «татар» һәм «мещеряк» сүзләренең билгеле бер файдалы максатка ирешү өчен кулланылуына мисал китерәсем килә. 1786 елда Әлмәнкүл, Рәҗәп һәм Өчкүл

авылларында яшәгән эчкен татарлары Чиләбе өязе мәхкәмәсенә гариза белән мөрәҗәгать итә. Алар башкортлардан һәм мещеряклардан алына торган ям, почта хезмәте өчен үзләреннән акча җыймауны сорый. Тикшерү барышында моңа кадәр эчкен татарларының бу салымны түләмәүләре ачыклана. Әлеге салымны рәсмиләштергән 1757 елгы Сенат указында акчаны фәкать «башкорт һәм мещеряк халыкларыннан» гына җыярга, диелгән була [97]. Шул уңайдан Уфа наместниклыгы идарәсе гариза биргән йомышлы татарларның ям өчен салым кертелгәнгә кадәр кем булуын ачыкларга куша [98]. Эчкен татарлары теләкләренә ирешә. Әлеге вакыйганың дәвамы бар. Д.М.Исхаков 1824 елда эчкен татарларының, үзләрен «мещеряк» итеп теркәмәүләрен сорап, гариза бирүләре турында яза, һәм бу эшне тикшергән чиновник 1827 елда аларның дәлилләрен дөрес дип таба [99]. Мондый гариза бирүнең сәбәбе икътисади мәсьәлә белән аңлатыла: нәкъ шушы вакытта Чиләбе өязе Мещеряк (Карасев) волосте җирләре казна хисабына алына [100]. Мещеряклар белән бер үк нигездә җир алган һәм бу өяздә яшәгән эчкен татарлары, җирләрен югалтмау һәм мещеряклар хәленә төшмәс өчен, алардан үзгә булуларын расларга ашыга. Инде мондый тәҗрибә дә була. Нәтиҗәдә, Карасев волостеннән аермалы буларак, Эчкен (Могильский) волосте җирләре 1874 һәм 1894 елгы карталарда вотчина җирләре итеп күрсәтелгән [101]. Моның сәбәбе бик гади — эшне тикшерүче чиновниклар канун нигезендә гамәл кылырга тиеш булган. Бу очракта йомышлы мещерякларга караган салым йомышлы татарларга кагылмаган, чөнки документта нәкъ менә мещеряклар гына искә алынган (биредә ям салымын җыю һәм мещеряклар вотчинниклар түгел дигән карар күздә тотыла). Шуңа күрә исемдәге аерма тышкы билге генә түгел, үз артыннан шактый мөһим нәтиҗәләргә китерергә мөмкин булган.

Йомгак ясап, шуны билгеләп үтәсем килә: хәзергә XVIII гасыр уртасы Көньяк Урал төбәге буенча бик аз күләмдә төгәл мәгълүматыбыз бар. Борынгырак чорга кагылышлы хәлләр тагын да мөшкел. Шуңа күрә алда яңа чыганаклар эзләү һәм табу, борынгырак чорларны өйрәнә башлау бурычы тора. Яңа чыганаклар татарларның Көньяк Урал төбәгенә күченү тарихын һәм алар тормышын яктыртырга юл ачачак.

Искәрмәләр һәм әдәбият исемлеге

30. РДБАА (Россия Дәүләт борынгы актлар архивы). 214 нче ф. 5 нче тасв. Д.434 нче эш. Б.649.
31. Шунда ук. — Б.696.
32. ПКДА (Пермь краеның дәүләт архивы). 297 нче ф. 1 нче тасв. 1030 нчы эш. Б.3.
33. ЧӨБДА (Чиләбе өлкәсенең берләштерелгән дәүләт архивы). И-115 нче ф. 1 нче тасв. 42 нче эш. Б.8.
34. Шунда ук. — 114 нче эш. Б.3.
35. Паллас П.С. Путешествие по разным местам Российского государства. Т.II. Кн.II. — Спб.: При Императорской Академии наук, 1786. — С.30-31.
36. ЧӨБДА. И-44 нче ф. 1 нче тасв. 80 нче эш. Б.20.
37. Шунда ук. — 109 нчы эш. Б.401.
38. Шунда ук. — И-87 нче ф. 1 нче тасв. 1015 нче эш.
39. Шунда ук.
40. История Курганской области. Т.V. — С. 387-288.
41. П.И. Топография Оренбургской губернии. — Оренбург: Оренбургское отделение ИРГО, 1887. — С.370.
42. РФА СПб ТИФТА (Россия Фәннәр академиясе Санкт-Петербург тарих институтының фәнни-тикшеренү архивы). 3 нче ф. 10 а тасв. 165 нче эш. Б.155.
43. ПКДА. 297 нче ф. 1 нче тасв. 1030 нчы эш. Б.9.
44. Шунда ук. — 278 нче ф. Оп. 1 нче тасв. 472 нче эш. Б.4.
45. СӨДА (Свердловск өлкәсенең дәүләт архивы). 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.291; СӨДА. Р-481 нче ф. 1 нче тасв. 76 эш. Б.103.
46. Усман исеме XIX гасырга кадәр «Осман» яки «Асман» буларак та кулланылган.
47. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.293; СӨДА. Р-481 нче ф. 1 нче тасв. 76 эш. Б.105.
48. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.297; СӨДА. Р-481 нче ф. 1 нче тасв. 76 эш. Б.109.
49. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.301; СӨДА. Р-481 нче ф. 1 нче тасв. 76 эш. Б.109.

50. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.304; СӨДА. Р-481 нче ф. 1 нче тасв. 76 эш. Б.111.
51. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 626 а эш. Б.584-585.
52. Шунда ук. — Б.585.
53. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.291; СӨДА. Р-481 нче ф. 1 нче тасв. 76 эш. Б.107.
54. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.291; СӨДА. Р-481 нче ф. 1 нче тасв. 76 эш. Б.103.
55. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.441.
56. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.297; СӨДА. Р-481 нче ф. 1 нче тасв. 76 эш. Б.107.
57. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.297-299; СӨДА. Р-481 нче ф. 1 нче тасв. 76 эш. Б.107-108.
58. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.291; СӨДА. Р-481 нче ф. 1 нче тасв. 76 эш. Б.103-104.
59. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.296; СӨДА. Р-481 нче ф. 1 нче тасв. 76 эш. Б.106.
60. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.301; СӨДА. Р-481 нче ф. 1 нче тасв. 76 эш. Б.106.
61. Кулбахтин И.Н., Кулбахтин Н.М. Наказы народов Башкортостана в Уложенную комиссию 1767-1768 гг. — Уфа: Китап, 2005. — С.261-262.
62. Зограф Н.Ю. Антропологический очерк мещеряков Зауральской части, Пермской губернии. — М.,1879. — С.1,13.
63. Исхаков Д.М. Этнографические группы... — С.85.
64. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.293-294.
65. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.299.
66. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.302.
67. РДБАА. 214 нче ф. 5 нче тасв. 434 нче эш. Б.653.
68. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.126-127.
69. Шунда ук. — Б.128.
70. Шунда ук. — Б.585.
71. Шунда ук. — Б.594.
72. РДБАА. 199 нчы ф. 1 нче тасв. Д.481 нче эш. Б.153.
73. ШШДА (Шадринск шәһәрендәге Дәүләт архивы). 224 нче ф. 182 нче эш. Б.26.
74. РДБАА. 248 нче ф. 1 нче тасв. 34 нче китап. Б.187.
75. РДБАА. 248 нче ф. 1 нче тасв. 1532 нче эш. Б.563.
76. ПСЗ-I (Полное собрание законов). Т.IX. — Б.742.
77. Ден В.Э. Население России по пятой ревизии. Т.II. Ч.2. — М., 1902. — С.273.
78. ПСЗ. Т.Х. Б.444-445.
79. ЧӨБДА. И-115 нче ф. 1 нче тасв. 106 нчы эш. Б.15. Әлеге документта 1735 ел күрсәтелгән — бу күчерүченең ялгышы булырга тиеш. Чөнки наказ В.Н.Татищев Оренбург экспедициясе белән җитәкчелек иткән вакытта язылган, ә полковник И.Н.Татищев Исет провинциясенең воеводасы булган, ягъни 1737 елның көзеннән 1738 елның көзенә кадәр. 1735 ел дигән дата, күрәсең, Уфа түбән расправасының мещерякларга, чувашларга һ.б. ясаклы кешеләргә җир бүлеп бирү турындагы документларның күчермәләрен җибәрүне сораулары, В.Н.Татищевның Исет провинциясе воеводасы полковник Татищевка 1735 елда җибәргән боерыгы турына бәйле рәвештә әйтелә (Шунда ук. — Б.1-9). Чиләбе түбән расправасы хезмәткәрләре, күрәсең, теләсәләр дә, теләмәсәләр дә, датаны өстәге сораулга туры китерергә тырышып «бутыйлар». Шунысын да өстәргә кирәк: 1735 ел әле башкорт восстаниесенең башы гына, документта телгә алынган указлар һәм карарлар кабул итүгә китергән төп вакыйгалар соңрак була.
80. Шунда ук.
81. Шунда ук. — Б.15.
82. Шунда ук. — Б.17-20.
83. Шунда ук. — Б.15.
84. ПКДА. 297 нче ф. 2 нче тасв. 310 нчы эш. Б.23.
85. Самигулов Г.Х. Территория Сафакулевского района в XVII — начале XIX века // Этнокультурная история населения Сафакулевского района (с древнейших времен до начала XX века). Монография / под ред. Д.Н.Маслюженко. — Курган: Изд-во Курганского гос.ун-та, 2012. — С.54. — [Электронный ресурс] — http://if.kgsu.ru/index.php?option=com_content&task=blogcategory&id=7&Itemid=38
86. Кулбахтин И.Н., Кулбахтин Н.М. Наказы народов Башкортостана в Уложенную комиссию 1767-1768 гг. — Уфа: Китап, 2005. — С.258.
87. ЧӨБДА. И-44 нче ф. 1 нче тасв. 88 нче эш. Б.1.
88. ЧӨБДА. И-44 нче ф. 1 нче тасв. 88 нче эш. Б.2.
89. ЧӨБДА. И-44 нче ф. 1 нче тасв. 80 нче эш. Б.20.
90. ЧӨБДА. И-44 нче ф. 1 нче тасв. 9 нчы эш. Б.1.
91. Шунда ук.
92. БРҮДТА (БР Үзәк Дәүләт тарихи архивы). 129 нчы ф. 2 нче тасв. 138 нче эш. Б.50, 57.
93. И-172 (И — исторический — тарихи: провенциаль архивларда революциягә кадәрге фондларны еш кына шулай билгелиләр), 1 нче тасв. 81 нче эш. Б.28; Челябинская старина: Лингвистическое краеведение на Южном Урале, вып IX. — Челябинск, 2008. — С.71.
94. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1092 а эш. Б.329.
95. СӨДА. 24 нче ф. 1 нче тасв. 1322 нче эш. Б.111.
96. ЧӨБДА. И-172 нче ф. 1 нче тасв. 44 нче эш. Б.73.
97. ЧӨБДА. И-44 нче ф. 1 нче тасв. 107 нче эш. Б.352.
98. Шунда ук.
99. Исхаков Д.М. Этнографические группы... — С.85.
100. ЧӨБДА. И-46 нчы ф. 1 нче тасв. 65 нче эш. Б.15-17.
101. ЧӨБДА. И-87 нче ф. 1 нче тасв. 23 нче эш, 24 нче эш.

*Русчадан **Илдус Заһидуллин** тәрҗемәсе*

ЙОСЫФ АКЧУРА ҺӘМ АНЫҢ «ЯҢА ТӨРЕК ДӘҮЛӘТЕ УҢЧЫЛАРЫ» ӘСӘРЕ

МӘСГУД ГАЙНЕТДИН,
филология фәннәре докторы

БҮГЕНГӘ КАДӘР ЭТНИК ҺӘМ ХРОНОЛОГИК ЧИКЛӘРЕ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫ ТУПЛАП, СИСТЕМАЛАШТЫРЫП, ФӘННИ БӘЯСЕ БИРЕЛМӘГӘН МАТЕРИАЛЛАР 1928 ЕЛДА УК ИНДЕ БӨРТЕКЛӘП ҖЫЕП ӨЙРӘНЕЛГӘН. БУ ЕЛДА ТӨРЕК МИЛЛӘТЧЕЛЕГЕ ТАРИХЫ ФӘННИ СИСТЕМАГА САЛЫНЫП, ЙОСЫФ АКЧУРА ТАРАФЫННАН БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ МОНОГРАФИЯ БУЛАРАК (ТАРИХИ ЭСКИЗЛАР) БАСТЫРЫЛА.

Йосыф Акчура — Сембер төбәгенең атаклы сукно фабрикантлары Акчуриннар нәселеннән. Әнисе Бикбикамәрбану — атаклы Казан сәүдәгәре Юнысов кызы. Йосыф Сембердә туа, аңа ике яшь булганда, йөрәк өянәгеннән әтисе Хәсән Сөләйман улы Акчурин вафат була. Өч фабрика хуҗабикәсе булып калган әнисе бик тиз банкротлыкка юлыга. Бурычларын түләргә банктан ссуда өстенә ссуда алып, ниһаять, шул бурычлар аркасында эшне мәхкәмәгә китереп җиткерә. Киңәшчеләре төрмә, сөрген, Себер белән куркытып, аңа Төркиягә күчеп китәргә киңәш бирә. Шул рәвешчә, 1882-1883 елларда ана белән ул Истанбулга барып урнаша. 6-7 яшеннән Йосыф Төркиядә яши. Биредәге башлангыч мәктәпләрдә һәм, үсә төшкәч, хәрби уку йортларында белем ала. Алты ел Истанбулда яшәгәч, 1889 елда әнисе белән Казанга туганнарына кунакка кайталар. Казанда кыш чыгалар. Җәй башында Дәүләкәндә кымызда булалар. Кайтышлый, Уфада пароходка утырып, Мәкәрҗә ярминкәсенә киләләр. Аннан әнисенең Касыйм шәһәрендәге күп балалы кыз туганы Шакуловларда булалар, шуннан соң Ока, Идел буйлап Сембергә, әтисенең туганнарына юл тоталар. Илгә кайту, кунак булу көннәре, җәй буе диярлек пароходта Идел, Чулман, Агыйдел, Ока буйлап ил гизүләр хисчән үсмер күңелендә җуелмас тәэсир калдыра.

1892 елда Й.Акчура Истанбулдагы хәрби училищега укырга керә. 1895 елда җир тетрәү вакытында берләнбер таянычы — әнисе — фаҗигале рәвештә вафат була. Егет хәрби училищеда укыганда, «Яшь төрекләр» революцион хәрәкәтенә тартыла. Әйдаманлык гадәте буенча, бу яшерен хәрәкәтнең иң актив әгъзаларыннан булып китә. Кулга алына. Берникадәр вакыттан соң, яшь булуы сәбәпле, азат ителә. 1896 елда, лейтенант дәрәҗәсе алып, хәрби училищены тәмамлагач, Генераль штаб каршындагы югары хәрби уку йортына керә. Монда да «Яшь төрекләр» хәрәкәтендә актив эшчәнлеген дәвам итә. Биредә укуының кырыгынчы көнендә ул янә кулга алы-

на һәм Ливиядәге дәһшәтле Сахара ком чүленең үзәгенә мәңгелек сөргенгә хөкем ителә. 1899 елда, Ливиянең Триполис (Траблис) шәһәреннән балыкчы көймәсендә Урта диңгезне кичеп, Мальта утравына, аннан Парижга качып килә. Биредә эмигрант «Яшь төрекләр» сафына баса. Вакытны бушка үткәрмәү нияте белән, шунда ук Парижның Хәзерге заман сәяси гыйлемнәре институтына укырга керә. 1903 елда, өченче дәрәҗәдәге бүләк алып, институтны уңышлы тәмамлый һәм бабаларының туфрагына, Сембер өязендәге Зөябаш авылына кайта.

Й.Акчура Хәрби училищеда укыганда ук каләм тибрәтә башлый. Аның «Казан голямасыннан Мәрҗани әфәнде» исемле беренче мәкаләсе Истанбулда «Мөсәүвәр (сурәтле) мәгълүмат» газетасының 1897 елгы февраль санында басыла. Зөябашта Госманлы (Төркия) милләтчелеге темасына багышлап язган «Өч тарзы сәясәт» («Сәясәттә өч юнәлеш») мәкаләсе Каһирә шәһәрендә күптән түгел генә чыга башлаган «Төрек» газетасының 14, 22, 28 нче апрель һәм 5 май (1904 ел) саннарында дөнья күрә. 1904 елда ул Казан шәһәренә кайта. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә тарих, география, төрек теле укытучысы булып урнаша. «Дин моназәрәләрендә иркенлек хакында» исемле мәкалә язып, «Тәрҗеман»га җибәрсә дә, җизнәсе Исмәгыйль Гаспринский: «Әле вакыты килмәде...» — дип, басуны кичектерүне мәгъкуль күрә. Китап итеп чыгарырга уйлагач, цензор В.Д.Смирнов христианлыкка кагыла дип рөхсәт бирми. 1905 елда язган «Русия революциясе» дигән мәкаләсен үзенең башлангыч чор иҗаты сыенган урыны — «Шураи өммәт»тә бастыра. Шулай ук «Гыйлем һәм тарих» дигән китабын басмага әзерли. Шулай итеп Й.Акчураның гыйльми эшчәнлеге башланып китә.

Идел-Урал төбәгендә татарча газеталар бастырырга рөхсәт ителмәгән шартларда Й.Акчураның иҗтимагый хәрәкәттә активлыгы татар тормышында моңарчы күрелмәгән, гадәти булмаган сыйфатлы, затлы, нәтиҗәле җанлану күренеше буларак, аерым бер әһәмияткә ия. 1905 елгы революция шартларында татар җәмәгатьчелегендә

Йосыф Акчура

Й.Акчураның белеменә зур ихтыяҗ туа. Ул, җәмәгатьчелек таләпләрен тотрыклы рәвешкә кертеп, формалаштырып әйтә-яза белә. Габдрәшит Ибраһимов «Мөселман иттифакы» партиясен оештыру тәкъдиме белән Казанда күренгәч тә, бу эшне үз кулына ала. Аны татарның (һәм Россия мөселманнарының) чын сәяси партиясенә әйләндерү өчен күп көч куя. Й.Акчураның тырышлыклары нәтиҗәсез калмый. Дәүләт Думасы чакырыла башлагач та, хакимият аның депутат булуын теләмәвенә дә карамастан, җәмәгатьчелек Й.Акчураны Дәүләт Думасының мөселман фракциясенә киңәшче итеп сайлап куя. 1905 елның 17 октябрь манифесты матбугат иреге турында игълан иткәч, Й.Акчура «Казан мөхбире», «Әхбар», «Вакыт», «Тәрҗеман» газеталары битләрендә татар журналистикасын дөнья һәм заман стандартларына якынайту юнәлешендә нәтиҗәле хезмәт итә. Абруйлы остаз буларак, Б.Шәрәф аша Казандагы татар яшьләре хәрәкәте, Ф.Әмирхан аша шәкертләрнең «Әлислах» хәрәкәте белән җитәкчелек итә. Яңа уку планнарын, программаларын, методикаларын һәм башка уку-укыту методик кулланмаларын, укыту предметларын миллилек ягыннан яңартуда катна-

ша, яңа әдәбият өчен көрәшне эзгә сала. Болар һәммәсе дә Й.Акчура тарафыннан актуальләштерелгән фәнни миллилек һәм милли фәннилек нигезендә алып барыла. Й.Акчура миллилек һәм фәннилек принципларын татар тормышында хөррият (1905-1907) заманы таләпләренә җавап бирә алырлык кимәлдә алып бара, дип әйтергә була. Мөһаҗирлектә үскән Й.Акчура илгә кайтуының беренче елларында ук менә шундый яңа, милли халыкчанлыкның гәүдәләнеше булып күренә алырлык югарылыкка күтәрелә.

Й.Акчура 1908 елгы яшь төрекләр революциясеннән соң Төркиягә кайта. Анда «Төрек йорты» исемле журнал чыгара башлый, Истанбул университетында сәясәт тарихын укыта. Бер үк вакытта «Шура» журналы һәм «Вакыт» газеталарына да мәкаләләр яза. 1920 елларда Төркиядә республика урнашуына ярдәм итә, мәҗлес депутаты итеп сайлана, Мостафа Кәмалнең мәдәният һәм сәясәт мәсьәләләре буенча киңәшчесе була. Истанбул университеты профессоры буларак, студентларга белем бирә, фән белән шөгыльләнә. 1931 елдан Й.Акчура җитәкчелегендә Төрек тарих җәмгыяте уңышлы эшләп китә, ә 1932 елда галим — Беренче Төрек тарих конгрессының җитәкчесе. Й.Акчура 1935 елда вафат була һәм Истанбул шәһәре зиратында җирләнә.

Й.Акчураның дөньяга карашы Париждагы остазлары өйрәтмәләренә нигезләнгән милләтчелек һәм Көнбатыш Европа цивилизациясен мәйданга китергән заманча фәннилек дигән ике терәк баганага корылган. «XIX гасырда җиһан мәдәнияте тарихына иң күп тәэсир иткән нәрсә — миллият фикередер. Миллият фикере дигән бөек куәтне һичбер көч җиңә алмады. Йөзмеңләгән сугышчылардан торган гаскәрләр бу фикер каршында җиңелде. Бүген дә милләт фикерен җиңәчәк көч — куркыту, золым, туп, мылтык түгел, бәлки миллият фикеренең анасы һәм атасы — хөррият һәм тигез хокуклылык фикерләре генә аны җиңә алырлар», — дип яза. Й.Акчураның тәүге тапкыр 1928 елда дөнья күргән, 1981, 2001 елларда Төркиядә кабат бастырылган «Яңа төрек дәүләте уңчылары» исемле хезмәте дөнья күләмендә төркичелек милли хәрәкәтенең барлыкка килү сәбәпләрен, алшартларын, аңа нигез салган идеологларның эшчәнлеген бәян итә. Китапта сүз барган шәхесләрне Й.Акчура яхшы белгән, алай гына та түгел, үзе гыйлем иясе һәм җәмәгать эшлеклесе буларак, аларның кайберләренә йогынты ясаган.

Укучыларга тәкъдим ителә торган текст хезмәтнең 1981 елгы басмасы буенча тәрҗемә ителде. Шушы басманың «Сүз башы»нда Й.Акчураның кыскача биографиясе урнаштырылган. Анда бүгенге көн өчен яңалыклар юк диярлек. Хәзерге Тольятти шәһәре урынындагы Ставрополь дигән өяз шәһәрен Төньяк Кавказга күчереп, «Ставрополь төбәге аша Одессага чыгып, Төркиягә киткәннәр» дигәнгә охшашлы хата үрчетү генә бар. «Сүз башы» авторның Төркиядә басылган хезмәтләренең исемлеге белән тәмамлана:

1. Өч тарзы сәясәт [Сәясәттә өч юл]. — Истанбул, 1911. — 32 б. (Анкара, 1976).
2. «Шураи өммәттә» чыккан мәкаләләрем. — 1913. — 60 б.
3. Мәүкуфият [тоткынлык] хатирәләре. — Истанбул, 1913.
4. Тарихи сәяси нотлары [Сәяси тарих язмалары]. — Истанбул, 1920.
5. Шәрык мәсьәләсенә даир тарихи сәяси нотлары. — Истанбул, 1920. — 56 б.
6. Мөәсер Ауропада сәяси вә иҗтимаи фикерләр вә фикри җәрәяннар [Европаның тәэсирчән сәяси һәм иҗтимагый фикерләре һәм фикри хәрәкәтләре]. — Истанбул, 1923. — 94 б.
7. Сәясәт вә икътисад хакында бер кач хитаб (кайбер хәбәрләр). — Истанбул, 1924. — 221 б.
8. Тарихи сәяси [Сәяси тарих]. — Истанбул, 1927. — 480 б.
9. Заманымызның Ауропа сәяси тарихы. — Анкара, 1933.
10. Госманлы императорлыгының дагылма [таркалу] дәвере (XVIII-XIX гасырлар). — Истанбул, 1934. — 176 б. (2 нче басма, 1940 ел).
11. Төрек, Җәрман [Герман] вә славяннарың мөнәсәбәти тарихияләре. — Истанбул, 1934. — 32 б.
12. Госманлы дәүләтенең корылышы вә бу вакыяя даир [вакыйгага кагылышлы] башлыча мәнбәгъләр [төп чыганаклар]. — Анкара. — 14 б.
13. Төрекчелек. Төрекчелекнең тарихы. — Истанбул, 1978. — 253 б.

Минемчә, хезмәтнең эчтәлегеннән чыгып караганда, аны «Төрек милләтчелек хәрәкәтен башлап җибәрүчеләр» дип атау төгәлрәк булыр иде. Күрәсең, Й.Акчура, әсәренә исем куйганда, ул заман Төркия иҗтимагый фикере һәм тарихи историография традицияләрен исәпкә алган.

ЯҢА ТӨРЕК ДӘҮЛӘТЕ УҢЧЫЛАРЫ

ЙОСЫФ АКЧУРА

1928 ел.
Кызым Өлкән һәм углым Тугрылга багышлыйм.

ТЕОРИЯ ҺӘМ КӨНБАТЫШ ТӨРЕКЛӘРЕНДӘ ТӨРЕКЧЕЛЕК

БЕР МӘСЬӘЛӘ

«Төрек милләте» фикере төрекләр арасына кайчан, кайда керде? Бу факт әлегә җиңел булмаган бер тарихи табышмак хәлендә. Без бу мөһим тарихи мәсьәләне бу мәкаләбездә төгәл хәл итү фикереннән еракбыз. Мәсьәләгә карашлы кайбер моментларны каләмгә алу тәҗрибәсе генә. Дөрес, «Төрек елы»ның бу нөсхәсендә (1928 ел) әлеге тәҗрибәне 1908 елларга кадәр күзәткән идек. Тәңре насыйп итсә, ул сызыкны «Төрек еллары»ның киләсе саннарында азагына җиткерергә тырышырбыз. Асыл мәсьәләнең хәле, юлына күз сала башлаудан элек кулланылыначак ике аталманың — «төрекләр» һәм «милләтчелек фикере» тәгъбирләре нинди мәгънәне күз алдында тотуларын аңлатып үтик.

«ТӨРЕКЛӘР»НЕҢ ТӘГЪРИФЕ (БИЛГЕЛӘМӘСЕ)

«Төрекләр (төркиләр)[1]» дигән чакта, этнология, филология, тарихы тыгыз бәйләнештә булган, кайчакларда, «төрек-татар», кайчак «төрек татар-монгол» аталган бер расадан чыккан, гадәтләре, телләре бер-берсенә бик якын булган, тарихи хәятләре-язмышлары бер-беренә укмашып, катнашып үткән кавем һәм кабиләләрне күз алдында тоталар. Кайчакларда иранлы һәм европалы кайбер тарихчылар «татар» дип әйткәндә, күз алдында тоткан казанлылар һәм азәрбайҗаннар «кыргызлар», «якутлар» дип атап йөртелүче халыклар да төрекләр төркеменә керәләр.

МИЛЛӘТ ФИКЕРЕ

Һәр кавем һәм хәтта һәр кабилә үз үзенчәлекләрен башка кавем һәм кабиләләрдән аерым, өстен санап, аларга каршы куя, күпчелек очракта үзенең шул фараз иткән өстенлеген төп идеясенә, идеалына әйләндерә. Бу хис һәм идея миллият фикеренең инстинктив бер башлангычы дип уйлыйм. Төрки кавем һәм кабиләләрдә бу хис һәм идея һәрчак булган дип һичнинди куркусыз тәсдыйк итә алабыз. Исламга хезмәт заманында да төрекләр үз милли горурлыкларын искәрткәннәр. Шуубия* хәрәкәтендә төрекләрнең катнашы бәхәссез. Төрек милли горурлыгын ачык искәрткән «Диване лөгат-эт төрк» авторын кайбер көнчыгыш белгечләре (востоковед-ориенталистлар) шуубияче булган, дип язалар.

Ләкин темабыз итеп алынган милләт фикере бу хис һәм идея үсешенең бер этабы гына. Кабилә һәм каумият хисенең милләт дәрәҗәсенә күтәрелүе Көнчыгышта да, Көнбатышта да мәйданга килә. Европа кавемнәре бик

---

[1] Җәяләр эчендә тәрҗемәче шәрехләмәсе.
* Шуубия — исламда еретик агым.

күп сәбәпләр тәэсире астында, башлыча XV гасырдан башлап, миллият тарафына йөз тотып, ниһаять, XIX гасыр урталарына бүгенге мәгънәдәге милләтчелек фикере югарылыгына ирешә. Хәзерге замандагы милләт фикеренең, икенчерәк төрле әйткәндә, «милләт принцибының» эчтәлеге шул: «Бер милләт тәшкил иткән инсан төркеме мөстәкыйль бер дәүләт хәлендә оешып, яшәү хакына ирешкәннәр». Бу җөмләнең мәгънәсен ачык аңлар өчен, милләт сүзе белән аңлатылган реальлекне яхшы белү сорала.

«МИЛЛӘТ» АТАЛМАСЫНЫҢ БИЛГЕЛӘМӘСЕ

«Милләт» — нәрсә? Чынлыкта, милләтләр барлыгына да карамастан, милләткә билгеләмә бирү җиңел түгел. Милләтләрнең тарихи формалашуына булганы кебек үк, теоретик билгеләмәсенә дә сәяси мәнфәгатьләр катнашы һәм тәэсире бар. Бүген «милләт»кә иң тәңгәл диярлек бер билгеләмә табып күрсәтергә тырышырбыз. «Милләт»кә бик күптөрле билгеләмәләр бар. Формалашкан хәлгә ирешкән һәр милләт тирәлек шартлары күзаллаган идеяләре чикләрендә милләткә билгеләмә биргәннәр. Мәсәлән, алманнар (немецлар) һәм славяннар раса һәм телне (ягъни тарихи мәҗбүриятне), французлар теләк һәм телне (ягъни географик һәм тарихи мәҗбүриятне) милләтләрнең мәйданга килешендә һәм дәвамында төп терәк итеп алганнар. Мөмкин булган кадәр фактлар чикләрендә калырга тырышып, без «милләт»кә шундый билгеләмә бирәсе иттек: «Милләт — раса һәм тел бердәмлеге нигезендә төгәл рухи иҗтимагый берлек хасил иткән халык төркеме…» Бу билгеләмәдә төрле карашларга төп нигез итеп алына торган алшартлар да азмы-күпме чагыла, «милләтчелек фикере» нидән гыйбарәт икәне дә шактый ачыклыкка күтәрелә кебек.

Менә шулай мәгънәсе билгеләнгән «милләтчелек фикере» мәгънә чикләре һәм эчтәлеге бераз элегрәк билгеләнгән «төрекләр» арасына кайчанрак, кайсы җирдә, ничек килеп кергән?

«МИЛЛИЯТ ФИКЕРЕ»НЕҢ ТӨРЕКЛӘР АРАСЫНА ҖӘЕЛҮЕ

Милләтчелек фикере Европада тарала башлаган өчен, Европа белән тыгыз мөнәсәбәттә һәм бәйләнештә торган, Европа мәдәниятеннән азмы-күпме файда күрә башлаган төрек кавемнәрендә бу фикерләр башка төрки кабиләләргә караганда иртәрәк һәм интенсиврак тарала. Көнбатыш (Төркия), Кырым, Төньяк төркиләренең — Идел буе (Казан) төркиләре һәм Кавказда азәрбайҗан төркиләре шул мөмкинлекләрдән файдаланган. Чыннан да, XIX гасыр азагында төркиләрнең бу дүрт төркеменең дүртесендә дә миллият фикере мәйданга чыгып, киң җәелә башлаганын күрәбез.

МИЛЛИЯТ ФИКЕРЕНЕҢ УРТАГА ЧЫГУ РӘВЕШЕ

Миллият идеясе фикере Көнбатыш, Кырым, Азәрбайҗан, Төньяк төрекләренең кайсысына элегрәк кергән? Бу сорауга җавап эзләргә керешүдән элек, миллият фикере бер кавемдә барлыгын сиздергән милли эшчәнлек башланганын исбатларлык эшчәнлек кузгалганын табарга, билгеләргә тырышып карыйк. Миллият фикере игътибар казана башлаган бер кавем шунда ук бу фикергә чын мәгънәсендә ниндидер хокук дауларга керешми. Игътибар үзәгенә китерелүгә кадәр аралыклар аша кичәчәк. Шул аралыкларда башкарыла торган күп эшләр бар. Миллият фикеренә тартыла башлаган кавем үз милләтенең үткәндәге культура вакыйгаларына зур кыйммәт бирә башлый. Тел, культура проблемаларның иң мөһиме дәрәҗәсенә күтәрелә. Үз кавеме телен җентекләп тикшерә, өйрәнә башлыйлар. Телләренең киләчәге турында борчыла башлыйлар. Туган телен системалы (ысуллы-фәнни)

тикшерергә керешүне бу кавемдә миллият фикеренең барлыкка килүе дип билгеләп була. Һичьюгы бу кавемдә миллият хисе көчле булганын искәртә. Тел үзенчәлекләрен җентекләүләр, урта гасырлардагы «сарыф» (грамматика), «нәхү» (синтаксисларның) элементар чикләрендә генә калмастан, яңа заман филология ысуллары эзенә тартыла. Тел тикшерүнең яңа ысуллары, сүз тикшеренүләре кавем тамырларны өйрәнү ягына да күз салдыра. Филология халыкның иң борынгы дәверләрдә яшәешен, борынгы мәдәниятен, дастани (хыялый) вакыйгаларын искә ала. Филологиянең тарих белән арадашлыгы этнография һәм археология тикшеренүләренә мөрәҗәгать итүгә китерә. Шул рәвешчә, кавемнең бөтен үткән чорлары борынгы дәверләренә кадәр яктыртыла, кавемнең матди һәм мәгънәви традицияләре җанландырыла. Шул рәвешчә, халкының үткәнендәге географик, демографик, этнографик үзенчәлекләре, икътисады турында мәгълүматлар туплана һәм тәртипкә салына. Барлык бу мәгълүматлар кавемнең мәдәният хәзинәләрен, икътисади куәт мөмкинлекләрен, мәдәниятькә сәләтлелек үзенчәлекләрен өйрәнү мөмкинлеген тудыра. Нәтиҗәдә, кавемнең хосусиятен (үзенчәлекләрен), үз «минлеген» (характерын), шәхсиятен белеп, аңлап, файдаланып яшәү мөмкинлеге туа. Туган тел белән кызыксынуның шул үзенчәлеге әгәр, шулай миллият фикере нигезләрен өйрәнү, тикшерү дәрәҗәсенә җитсә, бу — милләтчелек фикере мәйданга килә, дигән сүз була. Югыйсә, фикернең ул эзгә төшүе тиешле шартлар җитешүен көтү позициясендә кала. Бу очракта миллият фикерчеләре белән кавем лидерлары көчләрен шул шартларны барлыкка китерү эшенә караталар.

Югарыда куелган сорауга, төрек кавемнәренең кайсысында иң элек миллият фикере уртага чыкканын билгеләр өчен, бу кавемнәрнең кайсысы телен, мәдәниятен, тарихын тикшерү, вакыт ягыннан иң әүвәл бу эшләргә керешүчеләрне билгеләү сорала. Бу хакта кулымда беркадәр материал бар. Әмма ул материалның мәсьәләне катгый чишәр өчен җитмәгәне сиземләнә. Минем фикерләр шул материалга гына нигезләнгән. Кимчелекле фикерләр тулы ачыклык кертмәгән материалга гына нигезләнгән мәгълүмат кына булса да, милли тарихыбызга хезмәт булыр дип уйлыйм.

ГАРБИ ТӨРЕКЛӘРЕНЕҢ ЕВРОПА БЕЛӘН БӘЙЛӘНЕШЛӘРЕ

Гарби, ягъни Сәлҗүк һәм Госманлы төрекләренең Европа кавемнәре белән бәйләнешләре бик искедер. Европа латин мәдәниятенең, фикерләренең гарби төрекләргә тәэсире һәм үтеп керүе XVIII гасыр урталарыннан аеруча активлаша башлый. Бу факт ислам мәдәнияте белән Европа мәдәнияте арасындагы мөстәкыйль тәңгәллек бозылу XVIII гасыр урталарыннан ислам мәдәнияте зарарына бара башлаганын күрсәтә. Госманлы дәүләтенең куркынычсызлык көчләре һәм идарәсе XVIII гасыр урталарыннан инде Европа мәдәниятенең һичьюгы матди мәдәнияте өстенлеген дәлилләгән катгый дәлилләр алдында калалар һәм күп кенә нәрсәләрне, катгый карышкан хәлдә, алардан кабул итәргә мәҗбүрләр. Төрекләргә мондый өстенлекләрне тану да, кабул итүе дә җиңел түгел. Күп үтмәстән, матди мәдәниятнең мәгънәви мәдәният белән дә иң тыгыз бәйләнештә булганы сизелә. XIX гасыр урталарыннан башлап, Госманлы дәүләтенең идарә башында торучылар кайбер госманлы яшьләрен фәкать матди мәдәният казанышларын гына үзләштерер өчен Франциягә, Англиягә җибәрә башлыйлар. Солтан Мәхмүт II заманында башланган бу хәрәкәт — аның варислары. Европага киткәннәрнең гадәтләре дә үзгәрә башлады. Теге яки бу Европа

иленнән бәхет эзләп Госманлы башкаласына килгән һәм ислам динен кабул итеп, дәүләт идарәсендә шактый югары дәрәҗәләргә ирешкән чит халык вәкилләре Госманлы тарихының һәр дәверендә булгалаган. Алар арасында атаклы кешеләр дә юк түгел.

XIX гасыр урталарында Польша азатлык көрәшчеләренең кайберләре Австро-Венгрия кысрыклау тәэсире аркасында Төркиягә күченеп килеп, миллиятчеләр санын арттыралар, һәм югары социаль катлау вәкилләре булган бу шәхесләр җитди гыйлем һәм сәнгать хадимнәре була. Госманлы өлкәсендә Европа мәдәнияте тәэсирен көчәйтәләр. Госманлы мәгърифәтчеләре болар белән аралаша — таныша, сөйләшә, телләрен өйрәнә — үзләрендә Европа мәдәнияте элементларын күбәйтә. Шул рәвешчә, Европага китмәгән Госманлы яшьләре дә, илләренә килеп чыккан европалылар белән бәйләнешләр аша алдынгы мәдәният тәэсиренә тартыла. Гаскәри хезмәткә кергән европалы хәрбиләр, офицерлар аша Европа мәдәнияте элементлары гаскәргә дә үтеп керә. Укый-яза белгәннәр, гыйлем ияләре, гаскәр һәм дәүләт идарәләре хезмәткәрләре катлаулары арасында Европа фикерләре җәелә. Шул заманнарда тыйб (медицина), мөһәндәс (техника), хәрби мәктәпләр, ниһаять, Галатасарай ачыла. Аларга Европадан әзерлекле педагоглар чакырыла.

Европа фикерләренең Госманлы төрекләре арасында, төгәлрәк әйткәндә, мөселман госманлылар эчендә җәелүендә мөселман булмаган Госманлы тәбагасының да тәэсире бар дип уйлыйбыз. Мәсәлән, иске Госманлы иле формалашуда югары урыннарны биләгән Фенәрле (Балкандагы бер төбәк исеме) бәйләре XVIII, бәлки XVII гасырдан бирле, инде Европа мәдәниятеннән актив файдалана иделәр. Диван һомаи (югары дәүләт идарәләре) тәрҗемәчеләре булган Әфлак (Валах, Румыния), Бугдан (Молдавия) бәйлекләренең алмашсыз диярлек түбән офицер чиннары (фельдфебельләре), гадәттә, Рум (Греция) өлкәннәре асылзадәләре саналган идарә (дәүләт) җитәкчеләре белән якын бәйләнештә булып, алар арасында барган мәдәни уяну күренеше белән якыннан кызыксына һәм бу эштә баш катыруда башлыкларыннан ерак тормый. Менә шулай төрле юллар белән Европа мәдәнияте, Европа фикере Госманлы мөселманнары арасына кереп тамырлана.

XIX гасырның беренче яртысы. Европада бу байтак яңа фикерләр кайнавы һәм ул фикерләрне яңа чынбарлык сызыгына чыгарыр өчен милләтләр, төркемнәрнең бәрелешләре заманы иде. XIX гасыр башында француз революциясе, Наполеонның императорлыгыннан соңгы шул алдагы елларда император хакимиятенә каршы тәңгәл милли аякланулар әзерләгән Италия, Германия, славян илләрендәге һәм Австриядәге милли хәрәкәтләр Германия, Италия, славян илләренең бердәмлеген һәм Австрия империясенең җимерелә башлавын мәйданга китерә. Хөрриятчелек, халыкчанлык, социализм мәзһәбләре фикерләре дә гасырның шул беренче яртысында камиллекләре югарылыгына күтәрелә. Гасыр урталарына таба, аеруча, Мәркәзи Европада, Госманлы солтанлыгының иске күршесе Габсбурглар илендә, бу күптөрле яңа фикерләрне юксынудан, булдыру теләгеннән туган зур бер эчке чуалышлар өермәләнүе купты (1848 ел революциясенә ишарә).

Европалашуга йөз тоткан Госманлы идарәчеләре һәм мәгърифәтчеләренең бу вакыйгаларны ишетеп, күреп өйрәнүләре һәм боларның сәбәпләрен тикшерүләре, әлбәттә, булган Әфлак-Бугдан (Румыния-Молдавия) каршылыклары, Мора (Грециянең Морея өлкәсе) күтәрелеше, серблар хәрәкәтләре дә күз алдында булып тормакта иде.

Әмма шундый хәлләргә дә кара-

мастан, искитмәле нәрсә: Танзимат дәверенә кадәр ул чор Госманлы язма әсәрләре мирасы арасында Госманлы дәүләтенең яшәеше һәм киләчәге белән бәйләнешле бу бик мөһим вакыйгаларның мәгънә эчтәлегенә ниндидер игътибар күрсәткән, Госманлы дәүләтенең нигез-яшәеш тамырларын тикшерүгә каратылган елларда язылган һичбер әсәргә мин юлыга алмадым...

ТАНЗИМАТ ҺӘМ ЯҢА ГОСМАНЛЫЛАР

Европада ташып кайнаган хокукый, сәяси, социаль, әдәби фикерләрнең кайберләре, ниһаять, мөселман госманлылар башына килеп җитә башлый. Бу хәл Танзимат заманындагы кайбер эшләрдә һәм язуларда чагыла. Төркиләрнең милли рухын ачыкларга тырышучылар, гомумән, бу халык, фикергә караганда, эшчәнлеккә күбрәк игътибар каратканын билгелиләр. Бу фикер бик үк хаталы булмаса кирәк. Чыннан да, төрекләрнең, назари уйлануларга караганда, гамәли нәтиҗәләренә карап эшкә алынуны өстен күргәнен раслаган фактларны тарихтан бик күп табып була. Без кузгаткан милли мәсьәләдә дә халыкның шул психологик үзенчәлеге өскә калыкканлыгын күрәбез. Европа фикерләре, табигате нигезләреннән тикшерелеп, шул нигезләрнең — Госманлы социаль хәятенә яраклаштырылуы — кулга керәчәк нәтиҗәләр билгеләнгәннән соң, ягъни уйлау, аңлау агымында ялыкканчы тикшерелеп, зиһен арганнан соң, җиңелчә караш рәвешендә үзләштерелгән кайбер Европа фикерләрен карарлаштыралар — кайбер гамәли нәтиҗәләрне генә Госманлы социаль хәятенә кертәләр. Югарыдан һәм түбәннән дә, ягъни хөкүмәт идарәсен кулларында тоткан дәүләт җитәкчеләре һәм бу хөкүмәткә буйсынудан баш тарткан мәгърифәтчеләр тарафыннан да шулай тәкъдим ителде. Югарыдан башланганы Танзимат дип, түбәннән килгәннәре «Яңа госманлылар» дип атала. Бу ике хәрәкәт эштә һәм фикердә бер-берсеннән бик ераклар. Һәр ике хәрәкәткә карашлы җитди әсәрләр табу, күрү бик кыен эш.

Габделгазизнең тәхеткә чыгуыннан 4 ел соңра оешкан «Яңа госманнар» җәмгыятенең 1865 елда оештыру җыелышы үткәрелә. Җәмгыять әгъзасы буларак, аның документлары, чыганаклары белән яхшы таныш Әбүззыя Тәүфикъ бәй «Яңа госманнар тарихы» исемле әсәрендә: «Җәмгыятьнең беренче чыганаклар тупламында (хәзерге «Төрек учаклары» Үзәк комитеты рәисе Хәмидулла Сөбхи бәйнең олы агасы) җәмгыятьне оештыручылардан Сөбхи пашазадә һәм Аятулла бәйнең «Италиядәге «карбонарилар хәрәкәте» һәм «Польшада яшерен җәмгыятьләр» исемле ике «мөһим» китабы бергә төпләнгән. Җыентыкта шагыйрь Нәмыйк Кәмал дә катнаша. Аятулла революцион җәмгыять оештыру фикеренә шул ике китапны укып килгән, күрәсең... Италия фидакяр яшьләренең тапкыр тәшәббесләре, бөек эшләре «күмерчеләр» турында укыгач, милли горурлык хисе һәм тәэссирләнүләре («Хиссиятләре»), арсландай күкрәп, шул юлга омтылганнардыр, хөррият шәрабеннән сәрхушләнгәннәрдер», — дип яза. Беренче җыентыкның шул тәэсирен күргән, аны сурәтләгән Әбүззыя бәйнең самими рухланулары шуны бик ачык күрсәтә: бу идеалист, аристократ хөрриятпәрвәр Италия үсмерләренең ул замандагы Европаны давылландырган фикер ташкыннарын ничек тә булса үз илләрендә гамәлдә аякка калкыту юнәлешендә җанлануларын гына ачык билгели алмаган. «Яшь Госманлы»ларның әле илләрендәге хәлне һәм вакыйгаларны өйрәнеп, тикшереп күрерлек теоретик әзерлекләре юк. Үзләреннән алда килгәннәр дә, үзләре дә, Госманлы социаль хәятен

тикшерер өчен, Европа фикере нигезен өйрәнеп, Европа тикшерү ысулларын кулланып, яңа бер фәнни система, бер идеология әзерләмәгәннәр. Карбонарийлар турындагы китапта, алар җәмгыяте уставын тәрҗемә итеп уку, шуның хөкемнәре нигезендә ниндидер эшчәнлек кебек бер тәэсир тудырып, һәр теләгеңә ирешергә юл ачар, теләгән нәтиҗәләрне кулга кертер дип уйлаганнардыр?..

Француз сәяси фикере идеологларыннан Энгельгард «Төркия һәм Танзимат» дигән атаклы әсәрендә «Яңа госманлылар»ны француз телендәгечә исеме белән атый. «Гәнҗ (яшь) төрекләр» аталмасы французчадан аталмадан барлыкка килгән. «Яңа госманлылар» һәм «Яшь госманлылар» исемнәре китапта эшчәнлек төшенчәсе рәвешендә кулланылган французчадан алынган аталмалар. Бу аталма «Яңа госманлылар» хәрәкәтендә, Төрек милли фикере барлыкка килүенә дәлил була алмый. «Яңа госманлылар» сәяси хәрәкәтенең программасы итеп Тунислы Хәйретдин пашаның 1868 елда француз телендә басылган «Ислам хөкүмәтләренә кирәкле реформалар» исемле китабын күрсәтәләр һәм кыскача бәян итәләр. Китапта Госманлы дәүләтенең төрле дин һәм җенестәге тәбагасы (подданныйлары) бердәм ислам солтанлыгы итеп карала. Тунислы паша карашынча, хәзерге солтанлыкны төзәтү өчен кирәк чаралар, башлыча, солтан Сөләйман Кануниның (1520-1566) «Канун-и сәяси»ен киңәйтүдән һәм төзәтүдән гыйбарәт. Госманлы солтанлыгының ул иске кануны төзәтелеп, киңәйтелеп яңартылса, түрәләр һәм галимнәрнең сәяси вазифалары законга нигезләнәчәк һәм парламентлы Европа илләрендәге парламент мәҗлесенең нәкъ үзе булачак, имеш. Энгельгард фикеренчә, Хәйретдин паша актуальләштергән күзаллаулар ул заманда мөселманнар арасында шәкелләнә башлаган яңа максатларның һәм укмаша башлаган бердәнбер җәмгыять — «Яшь Төркия» идеалларының «тәрҗемәсе». Энгельгардның ялгышуын билгеләп үтү белән генә чикләнәбез. Солтан Габделгазиз заманындагы «Яшь Госманлылар» программасының Хәйретдин паша китабында уртаклыгы, икесендә дә күзгә бәрелгән аныксызлык һәм мәгънә чикләре билгеләнмәү өстенлек итүдә, фикер төгәлсезлегендә генә. Бу вакыйгасызлык, фактсызлык «Яшь Госманлылык» хәрәкәтенең Танзиматтан соңгы елларда гына түгел, бүген балку дәверен кичерүче «Иттихад вә тәрәккый» дәверендә дә тулы күләмендә саклана. Танзимат заманы «Яңа госманлылары» эчендәге, Сөләйман Кануниның XVI гасырдан калган «Кануннамә»сен киңәйтеп төзәтеп, XIX гасырның соңгы чирегенә тамырландырырга теләүчеләр булганы кебек, шул ук вакытта хәзер инде күпчелекне тәшкил иткән кагыйдәләрне нигездән яңарту тарафдарлары да булган. Әбүззыя бәйнең «Яңа госманлылар тарихына» күз салыйк. Нәмыйк Кәмал, Аятулла кебек яшь мәгърифәтчеләренең асыл илһам чыганаклары инде солтан Сөләйман «Кануннамә»ләре түгел, бәлки Европа илләрендә гамәлдә булган конституцияләр. «Яшь Госманлылар»ның хокукый һәм сәяси корылмалары берсе-берсе белән аралаштырылулардан тулысынча баш тартмаган өч чыганак үсентеләреннән гыйбарәт булганын күрәбез. Аларның бу хокукый идеологияләре, шул ук вакытта инде аерым программа итеп эшләнгән, дип тә әйтә алмыйбыз.

Фикер системалауда Танзимат «Яшь Төркия»леләргә караганда да күбрәк шөгыльләнгән. Чит илләр кысуыннан туган кыенлыкларга каршы Госманлы дәүләте идарәчеләре кулланырга мәҗбүри гамәли һәм практик сәяси әмәлләр, административ һәм икътисади чаралар бердәмлегендә, Госманлы тарихында Танзимат дип атала. Танзиматның нигез сыйфаты —

тәкълидтер (иярү). Танзимат (тәртипкә салу) Европага охшаш тәртипкагыйдәлелеккә (законлылыкка) йөз бору димәктер. Дәрья (диңгез) флоты вәзире һәм Баш команданы Халил паша 1830 елда әйткән: «Русиядән кайтып киләм. Үткән көннәребездән, барыннан да артык Европага ияргәнебездән канәгать булдым. Әгәр аларга охшарга тырышмасак, безгә Азиягә качудан башка чара калмаган булыр иде», — дигән (Төркия вә Танзимат, 6 б.). Танзиматта тәкълид ителгән (ияргән) нәрсәләр нигез принциплар, ысулларда гына түгел, гамәли нәтиҗәләрдә дә булды. Танзимат — «Низами Җәдит»нең («Яңару кагыйдәләре» заманының) дәвамыдыр. «Низам-и җәдит» — Европа коралларын сатып алды. Европалыларга охшаш хәрби киемнәр тектерде. Европалыларның гаскәри өйрәтмәләрен тәрҗемә итеп кулланылышка кертте. Танзимат та — европалыларның көндәге тормыштагы киемнәрен һәркемгә кидерде. Теге яки бу рәвештә җәза һәм иҗтимагый идарәләрне Европа илләрендәгегә охшатырга тырышты. Танзимат хәрәкәте тагын бераз тирәнәя төшкәч, фикерләү, фикерне язу юллары, атау, аңлату күләмнәрендә Европа тәэсире көчлерәк сиземләнә башлады. Бу нәрсә мөселман Госманлы дәүләте социаль хәятендә дөньяга караш системасы үзгәрү башлангычы иде. Төркия һәм Танзимат авторы — Танзиматтан гомуми максат, гасырларча заманнардан бирле ислам социаль хәяте, мәгънә эчтәлеге белән, сәясәттән аерым яшәгән христиан социаль хәятенә якынлаштырудыр», — ди. Бу максат күренүе һәм гадәткә бәйләнешле юнәлеше буйсынучанлыкны нык көчәйтте. Фәкать эчке, фикри һәм вөҗдани өлкәләр генә фикер ярдәме белән яңартыла, берәр эшкә яраклаштырыла иде. Бу идеологик кимчелек соңгы заманнарга кадәр тискәре нәтиҗәләр генә күрсәтте.

Теория өлкәсендә Танзимат «Яңа госманлы»лар хәрәкәте белән тәмамлана. Танзиматның идарә хокукы чикләреннән читкә китәргә теләмәгән чара һәм кануннарның артык та сак адымлылыгы хокук өлкәсендә җөрьәтлелеккә кичеп, хөкемдар мөмкинлекләрен һәм хокукларын чикләп, халык хокукларын һәм хөрриятен киңәйтү әмәлләрен күбәйтү ягына йөз тота. Бер карашка, «Яңа госманлылар» Танзиматчыларның радикальләре булып күренәләр. Әмма бу радикальлек кайчак идеализм реакциясе аралаштырмасына гына әйләнгән була. Танзиматчылар «Яңа госманлылар» белән әледән-әле бәрелешеп торалар. Алар арасындагы каршылыкларның үзәге — хөкүмәт һәм хөкемдарның хокукы һәм хакимияте чикләренең төгәл билгеләнүе белән милләтнең хокук һәм хөрриятен тәңгәлләштерү мәсьәләсендә. Яңа госманлыларның сәяси китапларында «ватан», «милләт», «хокук», «хөррият» сүзләре бик күп очрый. Танзимат документларында мондый сүзләрне күп кулланулардан читләшәләр иде.

ТАНЗИМАТ БЕЛӘН ЯҢА ГОСМАНЛЫЛАРДА МИЛЛИЯТ ТӨШЕНЧӘСЕ

Танзимат һәм Яңа госманнар телендә «милләт» сүзе мәгънәсе мөһим әһәмият казана. Бу сүзне алар французларда кабул ителгән мәгънәдә куллана. Ләкин нык берләшкән француз милләте белән Госманлы тәбәгасын тәшкил иткән төрле кавемнәр берлеген аңлаткан «миллият» арасында зур аерма барлыгына дикъкать каратмаган булып күренәләр. Көнкүрештә кулланышка алынган Европа фикерләре һәм реаль эчтәлекләре, югарыда әйткәнебезчә, нигездән аерыла. Госманлы социаль хәяте нигезенә кадәр тикшерелүгә мохтаҗ. Госманлы социаль хәятендә «миллият мәсьәләсе», чынлыкта, тикшерелмәгән һәм ачыкланмаган бер мәсьәлә. Милләт термины мәгънәсенә ачык бер билгеләмә бирелмәгән. Танзимат һәм «Яңа госманлылар» иҗтимагый фикерендә дә милләт төшенчәсе яхшылап тикшерелмәгән, өйрәнелмәгән булуы

милләтнең билгеләмәсез калуының ачык бер дәлиле. Милләт терминына теоретик билгеләмә эзләү Госманлы империясе социаль хәяте эшчәнлеге җимерелүенә юл ачачагыннан, Танзиматчылар һәм Яңа госманлылар моны яхшы аңлаганнарыннан, ул эштән читкә посып яшиләр. Яисә Госманлы империясендәге барлык халыкларны чынбарлыкта барын бер милләт дип аңлатып, милләт аталмасын шул күзаллаулары чикләренә кертеп сөйлиләр. Икенче бер караш рәвешендә, Танзиматчылар да, Яңа госманлылар да, Ауропада бөтен сәяси хәятне болгаштырган милләтчелек хәрәкәтләрен, Госманлы өлкәләрендә булып үткән аерым халыклар күтәрелешләрен ишетмәгән яисә ул вакыйгаларның мәгънәләрен аңламаган төс күрсәтүләрен дә нинди дер теоретик бер күзаллау дип булмый. Шул рәвешчә ният итеп, гамәлдә милләт терминын тикшереп билгеләмә бирүгә караганда, чынлыкта юк һәм булмаган «милләт»не, караш-фикерләрендә генә тормышта бар саналган милләт фикерен буташтыруны өстенрәк күрәләр. Шулай икән, Яңа госманлыларның, мөселманмы ул билгеләмә объекты, төрекме, түгелме икәнен искә алмастан, бөтен Госманлы дәүләтенең барлык халкын, чынлыктан читләшеп карап, фикердә генә булган бер милләт итеп санауларына катгый бәя бирү сорала. Ягъни Яңа госманлылар да, Танзиматчылар кебек үк, хәзер кулланышта булган термин белән әйткәндә, Госманчылык позициясендә калалар. Ул елларда Ауропада «Яшь итальяннар», «Яшь швейцариялеләр» һ.б. кебек хөрриятпәрвәр, халыкчан оешмалар мәйданга килә башлаган чак. Төрекләрдә хөрриятпәрвәрләрне французлар «Яшь төрекләр» дип атадылар. Төрекчеләр ул исемне үзләре «Яңа госманлылар» дип үзгәрттеләр. Шул рәвешле Госманлылар сәяси аталмасы «Госманлы милләте» идеясеннән мәйданга килә. Бу атамага карата безнең фикеребез китаплардан, документлардан күбрәк мантыйк йөртү юлы белән килгән гомумиләштерүләргә таяна. Әсәрләр һәм документлар белән расланулар да, әлбәттә, сорала. Милләт атамасының шулай билгеләмәсез, гомуми хәлдә калуы кирәклеге һәм файдалылыгы белән генә билгеләнә. Сәяси мәгънәдә сүзнең табигый мәгънәсе, әлбәттә, күз алдында тотылмый. Дөрестән дә, Танзимат дәверендә «Туран», «Төреклек», «Туран милләте» кебек гыйбарәләр бөтенләй очрамый. Танзиматның кайбер буташтырылганрак документларында Төркиягә карата Төркестан дигән аталма сирәк кенә очраштыргаласа да, бу кайбер француз язмаларындагы «La Turqik» сүзенең тәрҗемәсе генә. Бу аталмаларның бүгенге мәгънәсе ул заманда да бүгенге мәгънәдә кулланылганын исбатлауга дәлил була алмый. Тик бу ул заманнарда милли хис һәм төшенчә булмаган дигән сүз түгел. Тел, әдәбият, тарих өлкәсендә ул мәгънә эзләре аз түгел.

ТАНЗИМАТ ӘДӘБИЯТЫНДА ТӨРЕКЧЕЛЕК ЭЗЛӘРЕ. ШИНАСИ ҺӘМ ЗЫЯ ПАША

Мәсәлән, Танзимат әдәбиятының атасы булган Шинаси тарафыннан Назири Зивар әфәндегә якынча 1845 елда язылган тәбрикнамә кереше муләммәсенең (ике телдә язылган бер өзекнең) беренче юл шигыре француз телендә, икенче юлы саф төрекчә; өченче һәм дүртенче юллар исә гарәпчә һәм фарсыча. Шагыйрьнең бу әсәрендә төрекчәгә дә, французча, гарәпчә һәм фарсычаларга кебек үк мөстәкыйль бер урын бирергә теләгәне аңлашыла. Шинасиның бу шигырь юлы ул заманга кадәр дә инде бик мул булган Бикташи әфсенләү такмаклары, гашыйклар (ашуг) җырлары, халык такмаклары кебек, эчке тойгыдан мәйданга килгән бер көй түгел. Европа яшәеше һәм сәясәтенең мөһим, хәтта ачы тәэсирләре белән танышканда, Парижда белем алучылар һәм язучылар очрашуларында катнашкан тирән белемле бер

төрекнең уйланып иҗат иткән шигыри юлы искә төшә:

Олылыгың диңгезендә
күрәлмәз кемсә кара
(Олугчылык диңгезендә
беркем бер кара тап таба алмас).

Бу шигырь юлы Шинасиның икенче мәртәбә Парижга киткән чагында беренче төрек теле сүзлеген төзергә керешү вакыйгасы белән бәйле. Ул чактагы, «Госманлы теле» дип аталган телне ил халкының сөйләм теленә якынлаштырыр өчен чиккән газаплары, гадиләштерелгән кайбер төрекчә шигырьләр (мәсәлән, «Каракош чебеше белән Карга» мәсәле) язгалаганын да искә төшерсәк, аны Көнбатыш тәэсирен Европага киткән башка иптәшләренә караганда тирәнрәк үзләштергән һәм аңлаган фикер иясе, язучы, тел һәм әдәбият өлкәсендә төрекчелекне башкалардан алданрак сиземләгән бер госманлы санарбыз дип уйлыйбыз. Ялгышмасак, бу Көнбатыш төрекләре тел һәм әдәбиятындагы беренче төрекчелек хәрәкәте XIX йөз урталарында туа, дигән сүз була.

Танзимат дәвере шагыйрьләреннән, «Яңа госманлылар» сәяси төркеменә дә тартылган Зыя пашаның тел, әдәбияттагы төрекчелеге Шинасидан да ачыграк. Мәшһүр «Шигырь вә паша» мәкаләсе бу мәсьәләдә катгый бер дәлил була ала. Зыя паша бу мәкаләсендә «Госманлы атамасын «Төреккә» каршы мәгънәсендә, ягъни Танзиматтан элеккеге мәгънәсендә куллана. Иске төрек шагыйрьләрен искә алганнан соң: «Юк, аларның һичберсе госманлы шагыйре түгел. Гаҗәп бит: үзебезнең милләтебезнең (ягъни төрек милләтенең) бер теле һәм бер шигыре бармы һәм аны яңарту (ислах) мөмкинме?!» — ди. «Эчләрендә өчтән бере төрекчә сүз. Аларның да үлчәме билгеләнмәгән. Төрекчә яисә госманлыча кагыйдәләре тәртипкә китерелмәгән» икәнлеген искәрткәннән соң, төрекләрнең табигый иҗатын, Вәйси вә Нәргисиләрнең прозасы юклыгын кистереп раслый. «Юк! Безнең үз шигыребез әле вилаятьләр халкы белән Истанбул гавамы арасында гына яши. Безнең шигырьләребез, шагыйрьләребезнең үлчәмсез (вәзенсез) дигән, сөймәгән гавам җырлары, думбра шагыйрьләре арасында «диеш», «өчләмә» һәм «Кыябашы» дигән аталмалар алган назым гына. Безнең үз шигыребез әле «Мөтәрҗим-и Камус» күрсәткән язма үрнәкләре рәвешендә генә... Чын дәртләр бер мәртәбә генә шул якка карасын, күрерсез, аз гына вакыт эчендә күпме җырчылар җитешер, акылыгыз хәйран калыр!»

Телдә төрекчелек мәсьәләләренә пашаның XIX гасыр азакларында ук куйган шул мәсьәләләргә хәзергәчә күп нәрсәләр өстәделәр, дип булмый. Зыя паша тел белемендә төрекчелекне киң иңләгән кебек, госманлы һәм төрек атамаларының да бер үк мәгънәдә икәнен аңлый. Шагыйрь һәм әдип Зыя паша иҗатында моңа күп мисаллар китерелә. Әмма аның иҗатында милләт һәм миллият сүзләренең сәяси эчтәлек күләмен нечкәләп тикшереп аңлатырга теләү әдәби әяргәләреннән төрекчелекнең очын эзләү белән мавыгуга китерер иде. Без Зыя паша әсәрләреннән аның сәяси төрекчелегенең җеп очын эзләү эше белән мавыкмыйбыз.

Төрекчәдән ***Мәсгуд Гайнетдин***
тәрҗемәсе

Дәвамы алдагы саннарда ■

ГЫЙЛЕМ, МӘГЪРИФӘТ НУРЫН ЧӘЧҮЧЕ...

ЛЕНАР ГОБӘЙДУЛЛИН

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ, ӘДӘБИ, ЛИБЕРАЛЬ-ДЕМОКРАТИК ЮНӘЛЕШТӘГЕ «КОЯШ» ГАЗЕТАСЫНЫҢ ТӘҮГЕ САНЫ КАЗАН КАЛАСЫНДА 1912 ЕЛНЫҢ 10 ДЕКАБРЕНДӘ ДӨНЬЯ КҮРӘ. ГАЗЕТА МӨХӘРРИЯТЕ БАСМА ТУРЫНДА ҺӘР САН САЕН: «МӨГАЕН, БЕР ПАРТИЯ ПРОГРАММАСЫНА ИЯРМИ ТОРГАН КӨНДӘЛЕК, ТӘРӘККЫЙПӘРВӘР, ТАТАРЧА ГАЗЕТАДЫР», — ДИП ЯЗА.

Танылган әдәбият белгече, био-библиограф Исмәгыйль Рәмиев «Вакытлы татар матбугаты» исемле китабында газета турында: «Милли буржуа-демократия газеталарыннан берсе чыга башлавы белән «Йолдыз»га көндәш булды. Һәр икесе фикер ягыннан бер үк төсле булса да, җай туры килгән саен, әрләшә тордылар. Моның («Кояш»ның) башкалардан аеруча алып әйтерлек хосусыятьләре юк иде, ләкин замандашлары арасында усалрак телле, җылдамрагы булды», — дип яза.

Редакциянең газетага «Кояш» исемен сайлавы тирән мәгънәгә ия. Кояш — XX йөз башы татар әдәбиятында аң-гыйлем, мәгърифәт таратучы, татар милләтенең тәрәккыятькә йөз тотуын гәүдәләндергән символик образ.

Газетаның беренче санындагы мәгълүматтан күренгәнчә, «Кояш»ның һәйәте тәхририясендә [редакциясендә] Зәкәрия Садретдинов*, Фатих Әмирхан, Габдулла Тукай, Гыймад Нугайбәк һәм башкалар мөшарәкәт итәләр [катнашалар]». Исмәгыйль Рәмиев язуынча, газетаның «наширләре — Кәримовлар фирмасы, мөхәррире — Зәкәрия Садретдинов. Соңыннан наширлеге дә аның исеменә күчте. Даими эшләүчеләре — Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Заһид Нуркин,

№ 1
قویاش

«Кояш» газетасының беренче саны. 1912 ел, 10 декабрь

* Зәкәрия Садретдиновның этисе — мәгърифәтче, мөдәррис, Ташкичү авылының имамы Садретдин Мәрҗани — Шиһабетдин Мәрҗанинең энесе.

Ибраһим Бикколов, Гыймад Нугайбәк һәм башкалар». Дөрестән дә, газетаның 1913 елның 12 маеннан (№119) дөнья күргән саннарыннан җаваплы мөхәррире һәм шул ук вакытта нашире Зәкәрия Садретдинов була. Газета И.Н.Харитонов лито-типографиясендә басыла башлый. Шул ук елның 2 августыннан (№186) газета яңадан «Матбагаи Кәримия»дә (лито-типография «Бр.Каримовы») басылса да (соңгы санына кадәр), наширлек эше Зәкәрия Садретдинов өстендә кала.

«Кояш» газетасында дөнья күргән зур һәм кечкенә күләмле рубрикалар, яктырткан темалар, ягъни редакциянең үзе игълан иткән программасы түбәндәгедән гыйбарәт: 1) хөкүмәт әһелләре вә әмерләре; 2) мәмләкәт эшләренә вә мосаләхе [ике хөкүмәт арасындагы] гомумиягә гаид баш мәкаләләр; 3) агентство вә хосусый мөхбирләр телеграммалары; 4) газета вә журналлардан; 5) Казан хәбәрләре; 6) шәһәр думасының мәҗелесләре вә земский собрания вә гомуми җәмгыятьләр; 7) мәхкәмә хәбәрләре; 8) хариҗи [тышкы] хәбәрләр; 9) дахили [эчке] хәбәрләр; 10) әтраф [тирә-як] хәбәрләре; 11) Волга вә Кама буйлары; 12) Идел өсте вакыйгалары; 13) мөселман галәменнән; 14) әдәбият, фөнун [фән] вә сәнаигъ [сәнгать]; 15) кәшфият [фәнни-техник яңалыклар] вә ихтирагат [уйлап табылган әйберләр]; 16) тиҗарәт [сату-алу] вә сәүдә хәбәрләре; 17) биржа мәсьәләләре; 18) йорт итү кинәшләре; 19) тыйб вә хыйфзыссыйхәт [сәламәтлек] мәсьәләләре; 20) тарих хәбәрләре вә тарихи вакыйгаларга даир бәяннәр; 21) хикәя, роман вә шигырьләр; 22) гавам өчен фәнни мәкаләләр; 23) дини вә фәлсәфи бәхәсләр; 24) яңа әсәрләр вә тәнкыйтьләр; 25) фельетон; 26) театр вә музыка; 27) аннан-моннан, кыйссалар вә ләтыйфәләр [мәзәкләр]; 28) табышмаклар; 29) тасвирлар вә көлдергеч рәсемнәр; 30) справка вә бәһаләр; 31) игъланнар.

Көндәлек газета буларак «Кояш» Казан губернасы һәм шәһәре проблемаларын гына яктыртып калмаган, ә үзенең игътибарын халыкара мәсьәләләргә, Россия империясенең төрле почмакларында яшәүче татар халкына да юнәлтергә омтылган. Газета үзенең тәүге сәхифәсендә «Кояш»ның хосусый мөхбирләре Русиянең мөселманнары күп яшәгән һәммә урыннарында булачактыр», — дип белдерә. Һәм вәгъдәсенә тугры кала да, моны газетага Россиянең төрле почмакларыннан килгән хатлар исбатлый. Шул исәптән, газета үзе дә Россиянең татарлар күпләп яшәгән төрле төбәкләренә таралган һәм аңа аерым урыннарда язылу да мөмкин булган: «Кояш» өчен абунә вә «Кояш»ка дәрҗ итәр өчен игъланнар кабул ителә: «Газетаның үз конторында, борадәран Кәримовларның Казан, Уфа, Минзәлә, Оренбургтагы магазиннарында, Казанда «Матбагаи Кәримия» конторында, Әстерханда Газыймҗан Халидовта, чит шәһәрләрдәге мөселман китапханәләренең һәммәсендә һәм дә идарә исеменә почта аркылы җибәрмәк мөмкиндер».

«Кояш»ның идарәханәсе Печән базарындагы «Амур» мөсафирханәсендә 37 нче номерда урнашкан. Газета редакциясенең сату-алу, сәүдә урыны белән янәшә урнашуы матбугатта вакыйгаларның оператив бирелешенә, эчтәлегенә һәм басманың чит төбәкләргә күпләп таралышына йогынты ясамый калмагандыр. Даими рәвештә чит җирләрдән Казанга килгән татар сәүдәгәрләре нәкъ менә «Амур» кунакханәсенә тукталган һәм газета идарәсенә хәл-әхвәл белешергә кергән.

Исмәгыйль Рәмиев: «Газета «урта кулда, дүрт битле, көндәлек булып дәвам итте. Баштарак техникасы ягыннан байтак ук күрекле иде, соң елларында кәгазе начарланды. 1918 ел башларында контрреволюционный юлдан барганлыгы өчен туктатылды», — дип яза. Дөрестән дә, газетаның 1917 елгы 21 октябрь (№1178) санынннан бизәлеше һәм форматы үзгәрә, кәгазь сыйфаты начарлана, югарыда искә алынган «Мөгаен, бер партия про-

граммасына иярми торган көндәлек, тәрәккыйпәрвәр, татарча газетадыр», дигән җөмлә төшеп кала. Бу күренешләр редакциядә, басмаханәдә килеп туган матди-техник кыенлыклар һәм большевиклар режимына яраклашырга омтылу теләге белән бәйледер. Ә 1918 елның 24 июнендә укучыларга газетаның соңгы саны (№1245) таралуы мәгълүм.

Вакытлы матбугат ул — җәмгыятьнең көзгесе. Революциягә кадәрге бер генә татар вакытлы матбугаты да дөньядагы, Россия империясендә һәм татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдәге, шул исәптән Казан каласындагы вакыйгаларга битараф булмаган. Алар көн кадагына суккан проблемаларны үзләренең укучыларына җиткереп барган.

Моннан бер гасыр элек Казан каласы һәм анда гомер сөргән татар халкы ничек яшәгән? Аларны нинди проблемалар борчыган? «Кояш» газетасының без мөрәҗәгать иткән «Казан хәбәрләре» дигән рубрикасында Казан каласының, аеруча анда яшәүче мөселманнарының милли, икътисади, мәдәни тормышларындагы яңалыклар даими рәвештә урнаштырылган. Шул ук рубрика кысаларында белдерүләр дә бирелеп, урлаулар, үтерүләр дигән махсус хәбәрләр дә басылган. Дөньядагы вакыйгаларны сурәтләгән «Хариҗи [тышкы] хәбәрләр» Россия империясендәге эчке вазгыятьне яктырткан «Дихили хәбәрләр», Казан губернасы шәһәрләре һәм авылларындагы вакыйгаларны тасвирлаган «Әтраф (тирә-як) хәбәрләре» рубрикалары белән беррәттән, «Казан хәбәрләре»н дә газетаның баш редакторы Зәкәрия Садретдинов алып барган.

Сезнең игътибарыгызга тәкъдим ителә торган материаллар 1914 елның гыйнвар аенда дөнья күргән «Кояш» газетасының «Казан хәбәрләре» рубрикасыннан сайлап алып бирелә. Биредәге кыска гына хәбәрләрдән йөз ел элек шәһәр татарларының рус һәм Европа мәдәниятенә якынаюлары, шул ук вакытта көндәлек тормышта милли рухны сакларга омтылулары, дәүләт оешмалары белән мөнәсәбәтләре, татар халкының иҗтимагый-мәдәни үзәкләре — «Шәрык клубы», хәйрия җәмгыяте, китапханәи исламия эшчәнлеге, татар байларының социаль һәм сәяси активлыклары, татар зыялыларының яшәү рәвеше, көнкүреше турында шактый кызыклы мәгълүматлар алырга мөмкин. Гомумән, әлеге мәгълүматлар аша Казан каласында көнчыгыш һәм көнбатыш телләрен белгән татар егетләренең, җырчы-артистларның, студентлар һәм курсисткаларның җирле иҗтимагый-мәдәни тормышка уңай йогынты ясаганлыклары күренә. Шул исәптән гасыр башы татар вакытлы матбугатында күтәрелгән кайбер проблемаларның бүген дә хәл ителмәгәнлеген беләбез. Шуларның берсе — Яңа Татар бистәсендәге мөселман зираты мәсьәләсе. «Кояш»та да, шулай ук башка газеталарда да зиратта мөселманнар өчен урын җитмәүдән зарланып язганнар. Бер үк вакытта газетага тәкъдим ителгән вакыйгалар, хәбәрләр, аеруча аның татар театры һәм мәдәни тормышына нисбәтлеләре тәнкыйть күзе аша үткәрелгән, ягъни вакыйгалар укучыга информацион характерда гына түгел, ә аналитик төсмердә дә тәкъдим ителгән.

Гомумән алганда, «Кояш» газетасындагы «Казан хәбәрләре» рубрикасында басылган информацион-аналитик характердагы мәгълүматлар XX йөз башы Казан шәһәрен һәм андагы мөселманнар көнкүрешен, проблемаларын «эчтән» күрер, аңлар һәм тоемлар өчен мөһим чыганак булып тора.

Әдәбият

1. Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты. Альбом. (1925-1905). — Казан: «Гажур» басмасы, 1926. — Б.30.
2. Гайнанов Р.Р., Мәрданов Р.Ф., Шәкүров Ф.Н. Татар вакытлы матбугаты (1905-1924): Библиографик күрсәткеч = Татарская периодическая печать (1905-1924): Библиографический указатель. — Казан: «Рухият» нәшр., 1999. — 310 б.
3. Миңнуллин Җ.С. Кояш // Татар энциклопедиясе. — Казан: ТЭИ, 2012. — Б.489-490.

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»:

1914 елның гыйнвар ае

Маскарад

Хәзер русларда Рождество һәм Яңа ел мөнәсәбәте белән театр, клуб кеби урыннарда һәм төрле собраниеләрдә маскарадлар ясала. Бу маскарадларда бик күп гади маскалы (битлекле) кешеләрдән башка, төрлечә киенеп килгән кешеләр дә күп була. Бу киемнәрнең күбесе бер нәрсәне тәҗәссем [гәүдәләндерә] яки кием эшли белүдә мәһарәт [осталыкны] вә сәнәгать күрсәтүдән гыйбарәт була. Маскарад театр кеби зуррак урында ясалганда, бундай киемнәрдән башка, шул җирнең яки эчке идарәнең кимчелекләрен, хариҗи [тышкы] тормышыннан берәр мөһим вакыйга һәм халыкның игътибарын җәлеп иткән кешеләрне тәҗәссем ителгән киемнәр дә күп була.

Бу җәһәттән маскарад шул җирдәге әфкяре гаммәнең [җәмәгать фикеренең] аз гына, бик сыек кына булса да, төсен күрсәтә торган була. Мәсәлән, бишенче, алтынчы елларда Казандагы маскарадларда әллә нинди сәяси темаларга киемнәр булса, унике, унөченче елларда инде андый киемнәрне очратып булмый. Русиянең берәр идарәсендәге җитмәгән җирләрен күрсәтә торган киемнәр хәзерге маскарадларда булса да, бик зәгыйфь була. Бу исә Казан халкында сәясәт белән шөгыльләнүнең кимүен яки ул мәшгулиятьне халыкка күрсәтергә теләмәвен, эчтән тынын белдертә.

Мәсәлән, бу ел Казанда, шәһәр театрында[1] ясалган маскарадта соңгы темага эшләнгән киемнәрнең иң мөһим дигәне авыл халкының көннән-көн фәкыйрьләнүен, бетә баруын күрсәтә торган кием иде. Гомумән, тормыштагы кимчелекләребез, лото уйнап-уйнап та «зур катюль» өчен бик күп кешенең фәкыйрьлеккә төшүен күрсәтә торган «кием» белән **тимер юллардагы крушениеләрдә[2] дәрәҗәле кешеләрнең ак булып, бөтен гаепнең вак хезмәткәрләргә төшүен** бәян итә торган киемнән башка, игътибар итәрлек бернәрсә дә юк иде.

Казан маскарадында безнең өчен игътибар итәрлек мәсьәләләрнең берәве, әлбәттә, маскарадта семьясы белән килгән **мөселманнарның күплеге** иде. Театрның ике ярусындагы лоджияларның һәммәсе дә дисәк ярарлык мөселман җәмәгатьләре белән мәшгуль иде. Моннан җиде-сигез ел элек мондый урыннарда безнең мөселманнар бик аз, бармак берлән генә санарлык күренәләр иде. Бер-ике ир булса да, хатын-кыз җәмәгате электә бер дә күренми иде.

Мондый урыннарда мөселман семьяларының күп күренә башлавы безнең өчен, безнең тәрәккыебез өчен файдалы эшме, түгелме — анысын хәзер әйтеп бирергә мин өстемә ала алмыйм. Фәкать мондый җиргә балаларны алып килү, гадәттә дә юк һәм мәкъбүл [кабул күрелгән] эш тә түгел. Ә безнең мөселман гаиләсенең арасында бу елгы маскарадта балалар да (7-12 яшьлек) байтак күренә иде. Балаларны мондый урыннарга алып йөргәндә, аларның рухи тәрбияле булуларына күп зарар итү бар.

Ә.М.

1914. — №303. — 2 гыйнвар

---

[1] Хәзерге Ирек мәйданында (революциягә кадәр «Театральная площадь») В.И.Ленин һәйкәле урынындагы бина.

[2] 1913 елның 6 ноябрендә (24 октябрендә) Мәскәү-Казан тимер юлының Түбән Новгород губернасына кергән Ужовка станциясендә пассажир поезды һәлакәткә очрый. 14 кеше фаҗига урынында һәлак була. Авыр тән җәрәхәте алган 15 кеше хастаханәгә озатыла. Аларның 8е шул ук көнне вафат була. Бу тимер юл һәлакәте вакытында барлыгы 70ләп кеше зыян күрә.

Губернаторның мөселманнарны зиярәт кылуы

3 гыйнварда* кич сәгать алтыда Казанның яңа губернаторы П.М.Боярский[1] җәнабләре мөселманнар арасына төште. Губернатор иң әүвәл Галимҗан хәзрәт[2] мәсҗеденә төште. Анда җыелган халык белән падишаһ әгъзәмнең сәламәтлеге өчен догалар кылынды һәм, мөселманнарның үтенүе буенча, губернатор мөселманнарның гарыз сәдакатьләрен [үтенечләрен] бәян иткән телеграмманы падишаһ әгъзәмгә җибәрергә булды. Шуннан соң Боярский җәнабләрен дамелла Галимҗан әл-Баруди хәзрәт үз өенә дәгъвәт итте [чакырды]. Губернатор бу дәгъвәтне кабул итеп, берничә минутка Галимҗан әл-Баруди хәзрәт ханәсенә[3] тәшриф итте [барып килде].

1914. — №305. — 5 гыйнвар

Губернатор җәнабләренә зиярәт

Казан могтәбәрләреннән беренче җамигъ[4] имамы мелла Сафиулла хәзрәт һәм шул ук мәхәлләдә назыйр Габдерахман әфәнде Кушаев[5], 2 гыйнварда Казан губернаторына менеп, губернатор җәнабләрен Казанга килү мөнәсәбәте берлән тәбрик иткәннәр.

Сафиулла хәзрәт, кыска бер нотык сөйләп, мөселманнар исеменнән губернаторның Казанга тәгаен ителүен тәбрик иткән. Губернатор җәнабләре Сафиулла хәзрәткә бөек илтифат күргәзеп, рәхмәт укыган вә тәшәккер иткән [рәхмәт белдергән].

Моның бәгъдендә [соңында] Габдерахман әфәнде түбәндәге нотыкны сөйләгән: «Имею высокую честь представиться Вашему Превосходительству: старший член Казанского Сиротского Суда, Попечитель Первой Соборной мечети города Казани, купец Адбрахман Абдуллович Кушаев, приветствую приезд Вашего Превосходительства как представителя Высочайшей власти, законности и порядка в нашем крае, желаю Вашему Превосходительству плодотворной и полезной работы на благо вверенного Вашему попечению народа. От имени Казанского Сиротского Суда и моих единоверцев мусулман счастлив поздравить вступление Вашего Превосходительства в управление здешним краем, будучи убеждён, что население **без различия религии и национальности** найдёт в лице Вашего Превосходительства справедливого и милостивого начальника!!!»

Губернатор җәнабләре Габдрахман әфәндегә тәшәккер итеп, бик мәмнүн [канәгать] булганын белдергән һәм һәрбер мөселман вәкилләренең өйләренә төшеп, визитларын кире кайтару лязим булса да, вакыт мөсагадәсе [мөмкинлеге] калмадыгыннан, һәрберсенә йөри алмавын сөйләгән һәм 3 гыйнварда Ак мәсҗедкә[6] төшәчәген белдергән. Бәгъдә [аннары] Сафиулла хәзрәт һәм Габдрахман әфәндегә утырырга урын биреп, бе-

* Даталар иске стиль белән бирелә.
[1] Пётр Михайлович Боярский (1870-1944) — рус җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, Казан губернасының соңгы губернаторы (1913-1917).
[2] Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Баруди (1857-1921) — дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Бу вакытта «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөдәррисе, Казанда бишенче мәхәллә мәчете имам-хатыйбы.
[3] «Галимҗан әл-Баруди хәзрәт ханәсенә» — Тихвин урамында (хәзерге Тукай урамы, 38 йорт) Галимҗан Барудиның әтисе Мөхәммәтҗан Галиев XIX гасырның икенче яртысында төзеткән зур таш йорт. Бишенче җамигъ мәчет тә (40 нчы йорт) шул ук урамда булган.
[4] Хәзерге Мәрҗани мәчете.
[5] Кушаев Габдерахман Габдулла улы (1862-1917 елдан соң) — 2 нче гильдия сәүдәгәр, 1909-1913 елда Казан шәһәре Думасы гласные, беренче җамигъ мәчет һәм «Мәрҗания» мәдрәсәсенең җәмәгать идарәчесе.
[6] Ак мәчет — Галимҗан Баруди имамлык иткән бишенче мәхәллә мәчете (Галиев мәчете). Мәчет 1798 елда сәүдәгәр Муса Мәмәш акчасына төзелә.

раз вакыт мосахәбә кылышканнан [кара-каршы сөйләшеп утырганнан] соң, губернаторның илтифатына [хөрмәтенә] тәшәккер кылып чыкканар.

Татар яшьләре кичәсе

Рождественский тәгътыйле [каникулы] вакытында рус мәктәпләрендә укый торган татар яшьләре буш була вә шул бушлыктан истифадә итеп [файдаланып], башка шәһәрләрдән дә Казанга шактый укучы вә укытучы яшьләр җыела. Шул мөнәсәбәт белән һәр елны укучы татар яшьләре бу вакытта хосусый кичә ясый. Бу кичә инде хәзер Казан яшьләренең гадәтенә (традициясенә) кереп китте. Бу кичәне яшьләр көз башыннан көтеп ала.

Менә шул кичәнең бу елгысы өченче кич Шәрык клубы залында ясалды. Кичәне ясаучылар тарафыннан хосусый дәгъвәт белән генә җыелган бу кичәдә татар мөхәррирләре, адвокатлары, курсистка, студентлары һәм башка укучылары хазир булып, барлыгы туксан кадәр кеше мөшарәкәт итте [катнашты].

Мөшарәкәт итүчеләрнең үз араларыннан бер оркестр һәм татар җырларын җырлар өчен кызлар вә егетләр катыш хор ясалган иде. **Татар музыкасы, татар җырлары, танцылар булды** һәм гаилә кичәләрендә уйнала торган уеннар иҗраэ origin ителде [башкарылды]. Кунакларга чәй, плау һәм фрукталар тәкъдим ителде. Яшьләр бик рухлы сурәттә, күңелле вә матур итеп вакыт үткәрделәр. Кичәне ясашуда бик тырышып хезмәт иткән студент Шәйхулла әфәнде Алкинга[1] һәм, акча алмыйча, Шәрык клубының залын биреп торган клуб һәйәте идарәсенә рәхмәт әйтмәскә мөмкин түгелдер. Шәрык клубы үзенең шул көнгә тәгаен иткән концертын кичектереп, татар яшьләрен үзендә кунак итте.

Кичә бик рухлы сурәттә төнге 3 сәгатькә кадәр сузылды.

1914. — №306. — 6 гыйнвар

Китапханәи исламиядә[2]

5 гыйнварда якшәмбе көн китапханәи исламиядә ханымнар нәүбәте [чираты] иде. Бу юлы китапханәгә ханымнар аз килде. Барлыгы 80 ханым вә туташлар хазир иделәр. Аннан алдагы якшәмбедә 93 ханым вә туташлар булган. Укырга йөрүчеләрнең күбесе җиткән туташлар икән. Бик рәгъбәт [кызыксыну] белән яңа әдәбиятны укыйлар. Ханым вә туташлар укыган көнне китапханәдәге тәртипне Насыйр әфәнде мактап бетерә алмыйдыр.

1914. — №307. — 7 гыйнвар

Мөселманча концерт

7 гыйнварда Казанның Купеческое Собрание[3] залында җырчылыкка хәзерләнә торган Фатыйма Гомәрова[4] файдасына Фатыйма туташның концерты һәм дә спектакль булды. Спектакль күңелле артистлар тарафыннан уйналды. Уен, әлбәттә, көтелгәнчә, тәнкыйдьтән түбән торырлык начар чыкты. «Диншик Гали» шикелле күңелле комедиядә бу әфәнде вә ханымнар уйнаганда, көчкә карап, тыңлап торырлык рәвештә генә бик йомшак вә үзенең рухы югалтылып

[1] Алкин Шәйхулла Сибгатулла улы (1893-1922) — 1913-1917 елларда Мәскәү сәүдә (коммерция) институтында укый. 1917 елда Милли Шура әгъзасы. Татар халкының милли-мәдәни мохтарияты нигезләрен эшләүдә катнаша. Милләт Мәҗлесе депутаты. Финанс нәзарәте рәисе (1917-1918). Балалар өчен хикәяләр авторы. — ТЭС. — Б.32.

[2] Китебханәи исламия — 1906 елда Казанда ачылган татар җәмәгать китапханәсе.

[3] Казан сәүдәгәрләр җыены бинасы — хәзерге көндә Островский урамындагы Яшь тамашачылар театры урнашкан бина.

[4] Гомәрова Фатыйма — беренче җырчы артисткаларның берсе, 1913 елда 13 яшеннән сәхнәдә җырлый башлый.

уйналды. Артистларның һичбер гримсыз-нисез гади киемнән сценага чыгулары, боларның театр галәменнән никадәр ерак торганлыкларын үзе ук күрсәтәдер.

Концерт кыйсеме чибәр генә үтте. Хосусән декламацияләр матур гына булдылар. Вәлишин[1] дә декламациядә яхшы гына кабилиять [сәләтле] күренәдер. Фатыйма туташның тавышы әллә ничек, әүвәлге түгел. Ул бераз кирегә киткән кебек күренә. Соңрак, Фатыйма туташ җырлаганда бик аз җырлады. Җырлаганда, бер-ике мисраг [куплет] белән генә канәгатьләнмичә, күбрәк җырлый төшәргә кирәк иде. Кичәге концертта пианинода уйнаучының һичбер уенны белмәве аркасында Фатыйма туташның җырлавы муаффәкыятьсез [уңышсыз] чыкты. Андый урында яхшы уенны белүчене куярга кирәк иде.

Кичәдә халык күп булып, Казанның зыялылары вә бай сыйныфы байтак барганнар иде. Боларны концертка китергән нәрсә, үзләренең сүзләренә аңлашылуына күрә дә, концерт вә театр булмыйча, клубның зал вә бинасының яхшы булуы булып, «Шәрык клубы»на бармаулары да, бинасы начарлыктан, имеш. Шуңа күрә, «Шәрык клубы» яхшы бинада булса, мөселман кичәләре, бер дә шөбһәсез, халык берлә тулы булачак икән, диясе киләдер.

Шәрык клубында

Чәршәмбе 7 гыйнварда «Ватан каһарманнары» белән «Мәсхәрәләнмеш ханым» уйналды. Тамашага килүчеләр бу елгы сезонда бер дә булмаган рәвешчә бик аз иде. Клубның бөтен залы, китапханә бүлмәләренең һәммәсенә җыелган кешеләр барысы йөзгә кариб [якын] кенә булды.

Театро әсәрләренә ярлы әдәбиятыбыз өстенә кайбер мәзмунлерәкләре [эчтәлеклерәкләре] тәкрар ителә [кабатлана] алмаска мәҗбүр булулары аркасында, сәхнәдә шушы «Мәсхәрәләнмеш ханым» кебек эшкә өйрәнмәгән кулдан чыккан сыек тәкълидләрне бик еш карау кешеләрне, табигый, бик туйдыргандыр инде. Бу көн «Шәрык клубы»на киләчәк кешеләрнең бер кыйсеме, табигый, «Купеческий клубта[2]»гы концертка киткәндер дип уйларга тугры килә.

«Шәрык клубы» идарәсе шушы концерт булачагын алдан белгән булса кирәк дип уйлана һәм шундый көндә, акыл җәһәтен игътибарга алып, яхшырак әсәрләр куйса, клуб залы бу хәтле буш калырга мәҗбүр булмаган булыр иде, диясе килә.

Уенчылар һич истиснасыз [шиксез] үз рольләрен менә дигән итеп үтәделәр. Тамаша кылучылар да уйнаучылардан мәмнүн калганлык, фәкать пьесаның начарлыгы сәбәпле, нарасыйлык сизелде шикелле.

«Ак»
1914. — №309. — 9 гыйнвар

Мөселман каберстаны эше

Шәһәребезнең мөселман каберстаны[3] эше, өч ай йөреп, максудка муафикъ булмаган рәвештә Петербургтан кире Казанга кайтты. Безнең белүебезгә күрә, аның болай теләгебезгә хилаф рәвештә кайтуына сәбәп — Петербургка җибәрелгән вәкилебез тарафыннан бәгъзе бер урыннарда объяснение бирелмәүдер. Петербургтагы түрәләргә безнең зиратыбыз нинди икәне мәгълүм булмаганга, шөбһәсез, бу эш каралганда, бәгъзе урыннарда тел белән объяснение бирелергә тиештер. Вәкилебез электән

---

[1] Вәлишин Мөхәммәт — артист.
[2] Шул ук Купеческое собрание бинасы.
[3] Казан каласында XVIII гасырның урталарында Яңа Татар бистәсе белән бер үк вакытта барлыкка килгән зират.

бу эшкә таныш булмаганга, объяснение бирә алмаган булырга кирәк. Бу да безнең ничә еллар шул эш белән мәшгуль булган кешене әллә нинди интригаларга бинаән [сәбәпле] бер тарафка ташлап, аның урынына мәсьәлә белән бөтенләй таныш булмаган адәмне җибәрүебез гөнаһының җәзасыдыр.

Хәзер зиратта урын беткәне барыбызга да мәгълүмдер. Бу эшнең бер чарасын күрергә кирәк. Хәзер бу мәсьәләгә ашна [таныш] адәмгә кирәк урында объяснение бирергә һәм шәһәр Думасыннан кулына уполномочия алып биреп, тәкрар [кабат] Петербургка җибәрергә кирәк дип уйлыйбыз. Зияратта урын беткән. Эшне алай-болай дип тартып-сузарга вакыт юктыр. Мөселманнар, моны аңлап, тиз чарасын күрергә тиешләрдер.

1914. — №310. — 10 гыйнвар

Сәях профессор

Германиядә Потсдам шәһәре дарелфөнүненең [югары уку йорты][1] профессорларыннан Н.Риссом җәнабләре бу көннәрдә шәһәребезгә тәшриф ителмештер. Профессор җәнабләре татарлар әхвале белән танышырга тели икән. Ак мәсҗедтә дә намаз вакытында хазир булган. Намаздан соң дамелла Галимҗан хәзрәт илә танышып, мәдрәсәи «Мөхәммәдия»не карарга мөсагадә [мөмкинлек] алган. Җомга көн Шәрык клубында театрны тамаша иткән. Кичә газеталар редакцияләрен, матбагаларны һәм китапханәләрне зиярәт иткән. Профессор җәнабләре русча белмәдегеннән, танышкан адәмнәре илә немецча, французча һәм инглизчә лисаннарында мөсахәбә [аралашкан] иткән.

Цензура комитетында татар пьесалары

Сәхнәгә куяр өчен рөхсәт мөһере басарга дип, Петербург цензура комитетына Шәрык клубы тарафыннан җибәрелгән 20дән артык татар пьесалары хакында бу вакытка кадәр бер хәбәр дә юк иде. Соңгы хәбәрләргә караганда, цензура комитетының мәэмүрләреннән [түрәләреннән] бер зат бу пьесаларга рөхсәт алу өчен тырыша икән. Мәзкүр [бу] әфәнде сүзенә караганда, ул, бу китапларга тиз көннән сәхнәгә куяр өчен рөхсәт мөһере бастырып, Шәрык клубына җибәрәчәк, имеш. Репертуарыбызның шундый фәкыйрь бер заманында бар кебек пьесаларыбызның рөхсәтле булуына шатланмый һәм аның хакында тырышучы затларга тәшәккер итмичә мөмкин түгел.

1914. — №311. — 12 гыйнвар

Профессор Риссом

Германиядә дарелфөнүн профессорларыннан Риссом җәнабләренең бу көннәрдә шәһәребезгә тәшриф иттеге газеталарда язылмыш иде. Профессор җәнабләре университет вә коммерческое училищеларны[2] тамаша иттеге бәгъдәндә коммерческое училище мөгаллимнәренә, әһле исламның гадәт вә әхвәлен истигъләям касдында [өйрәнү ниятендә] улдыгын гарыз итештер. Инде бу хезмәтне әда итмәк [башкару] хосусында коммерческий мөгаллимнәреннән Суглов җәнабләре шәкертләреннән Габделгазиз Баһаветдиновны[3] тәгаен итмештер.

Габделгазиз әфәнде мәмнүният илә кабул итәрәк, бәгъзе мәсҗед вә мөдәррис вә матбагаларны тамаша ит-

[1] Университет мәгънәсендә түгел, чөнки Потсдам шәһәрендә университет 1991 елда гына ачыла.
[2] Хәзерге К.Маркс урамында Казан дәүләт аграр университеты урнашкан бина.
[3] Габделгазиз Баһаветдинов — Шиһабетдин Мәрҗанинең оныгы.

тергән соңгында, әткәсе Борһанетдин әл-Мәрҗани[1] җәнабләренең йортына тәшриф иттермеш вә шунда профессор җәнабләре ике сәгать микъдары мәхдүмнәр илә голүм вә фөнун вә мөселманнарның әхваленә даир немецча мосахәбәт итмештер. Соңрак Габделхәмид Казаков[2] ул мәҗлескә тәшриф итәрәк бераз мөкяләмә иткәннән [сөйләшкәннән] соң, Шәрык клубын тамаша кылмак арзусы [теләге] илә мәзкүр клубка юнәлмештер. Профессор җәнабләре икенче көн дәхи Борһанетдин әл-Мәрҗани хәзрәт йортына тәшриф боерып, бер сәгать микъдары мосахәбәт иттеге соңында, Ибраһим Әмирхани[3] ул мәҗлескә килеп, инглиз лисанынча мөсахәбәт итмештер. Ул көн янә Печән базары мәсҗеден[4] һәм Матбагаи Кәримияне[5] зиярат итмешләрдер. Профессор җәнабләре зиядә мәмнүн [бик тә канәгать] булып, гали әл-хосус [аеруча] Габделгазиз әфәндедән Садри Максуди[6], Казаков һәм Әмирханов вә әмсали Ауропа лисанына вакыйф [телләрен белүче] кемсәләр илә таныштырдыгы өчен мәмнүниятен [шат булуын] изһар итмештер [белдергән].

1914. — №312. — 13 гыйнвар

Һиммәт ияләренә

Казан җәмгыяти хәйриясенең[7] приютында торучы балаларга кием-салым һәм башка кирәкле нәрсәләрне бу елгача бәгъзе бер һиммәт ияләре иганә тарикынча биреп килсәләр дә, бу елны бу әфәнделәрнең бәгъзеләре имтинаг иткәннәр [баш тартканнар]. Ләкин бу балаларның кирәк нәрсәләре бик күп. Җәмгыять акчасыннан алганда, бу приютка тәгаен кылынган сметадан тыш, күп расходлар тотарга тугры киләдер. Һиммәт ияләреннән кадәр хәл нәрсә илә, мәсәлән, киемлек, күлмәклек, кәләпүш, читек илә яки акча илә булса да иганә булынуларын вә иганәләрен җәмгыять хәйрия хәзинадары Нургазиз әфәнде Хөсәеновка тапшыруларын үтенәмен.

Приютның попечитель хезмәтен әда кылучы [башкаручы] Вәли Апанаев[8].

1914. — №313. — 14 гыйнвар

Мөселман банкасы[9]

Соңгы көннәрдә Казанның мөселман сәүдәгәрләре арасында мөселманнар

---

[1] Борһанетдин әл-Мәрҗани (1855-1916) — Шиһабеддин Мәрҗанинең улы, беренче җамигъ мәчет имамы.
[2] Казаков Габделхәмид Мөхәммәтшакир улы (1877-1917 елдан соң) — Казан сәүдәгәре һәм җәмәгать эшлеклесе. 1908 елда бертуганы Мөхәммәтрәхим белән «Казаковлар сәүдә йорты» ширкәтен оештыра. — ТЭС. — Б.282.
[3] Ибраһим Әмирхани — тәрҗемәче, дипломат, юрист. Язучы Фатыйх Әмирханның бертуган кардәше. Миллионер Әхмәд бай Хөсәенов хисабына 1908-1913 елларда Төркиянең Бәйрүт шәһәрендәге Америка коммерция колледжында укый, инглиз, гарәп һәм төрек телләрен өйрәнә.
1914 елда белемен арттырыр өчен Америкага китәргә җыена, әмма Беренче Бөтендөнья сугышы башлану сәбәпле, бу хыялы чынга ашмый кала. — Әмирхан Р. Әмирханнар. — 2005. — Б.68-88.
[4] Печән базары мәчете — хәзерге Нурулла мәчете. XIX-XX йөз башында Печән базары мәчете, җиденче җамигъ мәчет, Базар мәчете, Юныс мәчете, Баш мәчет, Ак мәчет исемнәре белән атап йөртелгән. 1845-1849 елларда сәүдәгәр Юнысовлар акчасына төзелә. — ТЭС. — Б.498.
[5] Матбагаи Кәримия — бертуган Мөхәммәтҗан һәм Шәрифҗан Кәримовлар тарафыннан 1900 елда Казанда ачылган беренче хосусый татар басмаханәсе.
[6] Максуди Садретдин Низаметдин улы (1878-1957) — юрист, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, 1901-1906 елларда Париж университетының юридик факультетында белем ала. 1906 елда Казанга кайта. Казан губернасыннан Дәүләт Думасы депутаты.
[7] Казан хәйрия җәмгыяте — 1898 елда татар эшкуарлары, сәүдәгәрләре теләктәшелеге белән ярлы мөселманнарга ярдәм итәр өчен ачылган җәмгыять. — ТЭС. — Т4.— Б.517-518.
[8] Апанаев Мөхәммәдвәли Мөхәммәдзакир улы (1899-1922) — скрипкачы, драматург, җәмәгать эшлеклесе.
[9] Татар вакытлы матбугатында мөселманнар өчен аерым банк ачу мәсьәләсе берничә тапкыр күтәрелсә дә, бу банкның ачылуы турында мәгълүматлар юк. Фәкать татар авылларында гына мөселманнар өчен вак бурыч ширкәтләре булганлыгы мәгълүм. Аларның эш тәртибе Россиядәге башка банклар кебек үк булган, ягъни шәригать тәртибе буенча гамәл кылмаганнар.

өчен бер взаимный кредит банкасы ачу мәсьәләсе бик кызу-кызу мөзакәрә ителә. Сәүдәгәрләр мондый бер банканы бик кирәксенәләр һәм аны ачарга тәшшәбес итәләр [тотыналар], бик тиз арада кирәк кадәр акча табылуына да ышаналар. Тиз көндә тиешле урыныннан рөхсәт алып, бу тугрыда бер җыелыш ясарга кирәк.

1914. — №318. — 21 гыйнвар

Мөселман капитан Габделкаюм әфәнде Старов[1] янында

24 гынварда Шәрык клубында булган спектакльдә мөселман капитан Габделкаюм әфәнде Старов та бар иде. Капитан формасында татар спектакленә килгән Габделкаюм әфәнде, табигый, күп кешенең игътибарын җәлеп итте. Спектакльдәге күп яшьләр аның белән танышып сөйләштеләр. Шулар арасында безнең мөхбиребез булып, аның белән танышырга вә татар тормышыннан читтә күп еллар үткәргән һәм беренче кат татар театрын күргән Габделкаюм әфәнденең тәэсирен сорарга муәффәкъ булды. Татар театрын күрер өчен, махсус Казанга килгән Габделкаюм әфәнде татар театры хакындагы тәэсирен бер сүз белән генә ифадә итә [аңлата]: «Бик һәйбәт!» — ди. Килүеннән бик мәмнүн [шат] булуын сөйли. Татар тормышының ничек баруы хакында озынрак итеп әйтә: «Мин утыз ел инде татар тормышыннан аерылып торам, татарлар шулкадәр алга киткәннәрдер дип тәсаувыр да итә [күзалдына дә китерә] алмый идем. Шул тормыш эчендә торганга, сезгә бәлки ачык күренми торгандыр, әмма читтән килгән миңа бу ап-ачык күренә. Татарлар бик зур адым белән алга таба баралар…»

1914. — №322. — 27 гыйнвар

Якшәмбе көн сәүдә иткән өчен протоколлар

Үткән якшәмбе көнне сәүдә иткән өчен, төрле частьларда полиция тарафыннан сәүдәгәрләр өстеннән протоколлар куелган.

Беренче частьта 34 сәүдәгәр өстеннән протокол куелган. Шулардан 33е мөселман сәүдәгәрләр[2]. Икенче частьта 58 протокол, һәммәсе мөселман өстеннән. Дүртенче частьта 5 протокол, һәммәсе мөселман. Бишенче частьта 6 протокол, 4се мөселман.

1914. — №323. — 28 гыйнвар

Дарелятим[3] хакында губернаторыбыз

28 гыйнварда Садыйк хаҗи Галикәевне[4] Казанның яңа губернаторы җәнабләре үз янына чакырып, Рома-

[1] Габделкаюм әфәнде Старов Зөя өязенең Акъегет авылында туган. 17 яшенә кадәр авыл мәдрәсәсендә укыган. Шуннан соң атасы белән Уфага күчкән. Анда сәүдә белән мәшгуль булганнар, тиздән атасы үлгән. Ул үзлегеннән русча укырга тотынган һәм Рыбнинскига барып, көймәчелек мәктәбенә кергән. Анда бер ел укыганнан соң, 1886 елда Каспий диңгезендәге пароходлардан берсендә, хатеремдә дөрес калган булса, Хөсәен Монакыйф пароходына киткән. Аннан Севастопольгә килеп, көймәчелек мәктәбендә ике ел укып, 1889 елда имтихан тоткан һәм чит мәмләкәтләргә йөри торган бер инглиз көймәсенә капитанның икенче ярдәмчесе булып хезмәткә кергән. Аннан соң табибларның киңәше буенча, Кара диңгез вә аңа тоташкан диңгезләрдә йөри торган бер көймәгә капитан булып күчкән. 1913 елның мартыннан бирле Балтыйк диңгезендә хезмәт иткән («Кояш» газетасы искәрмәсе).
[2] Якшәмбе көн христианнарның бәйрәм көне булганлыктан, бу көндә сәүдә итү тыела. Казан мөселманнары берничә мәртәбә бу көндә сәүдә итү мөмкинлеге бирүләрен үтенеп, шәһәр думасына мөрәҗәгать итеп карасалар да, уңай нәтиҗә булмый.
[3] Дарелятим — Казан шәһәрендә ачылган ятим балалар йорты. Бу социаль оешма татар байларыннан кергән хәйрия акчасына финансланган һәм мөселманнар китергән кием-салым белән тәэмин ителгән.
[4] Галикәев Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәдсафа улы (1847-1919) — сәүдәгәр, хәйрияче, абруйлы җәмәгать эшлеклесе, Казанның Болак арты өлешендә бик зур күчемсез милеккә хуҗа коммерсант, шәһәр Думасы депутаты. Аның Гостиный двордагы бер кибетенең еллык акча әйләнеше генә дә 1 миллион сумнан артып киткән.



Театр мәйданы. XIX гасыр азагы
Фото А.Дубин архивыннан

новлар сөяләсенең юбилее[1] шәрифенә ачылачак дарелятим мәсьәләсенең ни хәлдә икәнен сорашкан һәм дарелятим ачу мәсьәләсе ник тукталып тора, дигән.

Садыйк хаҗи моңа каршы дарелятимнең хәзергә кадәр уставы вә программасы эшләнмәгән икәнен бәян итеп, әле акча җыйганыбыз бөтенләй юк, чөнки акча җыярга рәсми рөхсәт алынганы юк, дигән һәм кемнәр күпме бирергә вәгъдә иткәнлекләрен күрсәткән.

Губернатор җәнабләре үзенең тиз көннән акча җыярга рәсми рөхсәт бирәчәген сөйләп, бу изге эшнең вөҗүдкә чыгуын теләгәнлеген аңлаткан. Яңа губернаторыбызның мөселманнарга мөтәгаликъ [бәйле] мәсьәләдә мондый хөсне тәвәҗҗеһ [яхшы теләктәшлек] күрсәтүен хәерле фал итеп каршы алмаска мөмкин түгелдер.

Мөселманнар кулында конфет фабригы

Казанның могтәбәр сәүдәгәрләреннән Вәлиулла Ибраһимов[2] вә борадары тарафыннан үткән ел бер конфет вә шоколад фабрикасы ачылган иде. Хәзер шул фабрика, эшен тәрәккый иттереп, бик матур төрелгән һәйбәт конфетлар эшли башлаган. Конфетлар арасында Мәскәүнең зур фабриклары конфетларына бирешмәслекләре бар. Мөселманнар кулындагы производствоның тәрәккыенә шатланмаска мөмкин түгел.

Шуны да әйтеп узарга кирәк: яхшы конфетларның кайберләренә матуррак татарча исемнәр кушылса, күңелле эш булыр иде. Моңа без Ибраһимовларның дикъкатен җәлеп итәбез.

1914. — №325. — 30 гыйнвар

Текстларны һәм искәрмәләрне басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.*

[1] Романовлар сөяләсенең юбилее — 1913 елда Россия империясендә Романовлар тәхеткә килүенең 300 еллыгын зурлап билгеләп үтәләр. Шул уңайдан алдагы елларда «рәхимле һәм гадел патша» хөрмәтенә төрле социаль-мәдәни объектлар ачарга планлаштырыла.

[2] Вәлиулла Ибраһимов — 2 нче гильдия сәүдәгәр. 1906 елдан хәзер Г.Тукай музее урнашкан Шамил йортының хуҗасы. Вәлиулла Ибраһимов шул ук йортта конфет лавкасы ача һәм соңрак Казанның «конфет патшасы» дип таныла.

РЕСПУБЛИКАБЫЗ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕН КАЙГЫРТЫП

ТР ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЫ, ТР ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНЕҢ МӨХБИР-ӘГЪЗАСЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГАН ХИМИГЫ **ЗЫЯТДИНОВ АЗАТ ШӘЙМУЛЛА УЛЫНА** ТИЗДӘН 75 ЯШЬ ТУЛА. ШУЛ УҢАЙДАН БЕЗ АҢА БЕРНИЧӘ СОРАУ БЕЛӘН МӨРӘҖӘГАТЬ ИТТЕК.

– Азат Шәймуллович, Сез – күренекле сәнәгатьче-нефтехимик һәм Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, сәнәгать һәм фән өлкәләрендә зур уңышларга ирешкән шәхес. Шушы ике юнәлешне ничек берләштерә, алай гына да түгел, аларны берберсе белән тулыландырып, хезмәт юлыгызны алып бара алдыгыз. Чишмә башы кайдан башлана?

— Минем тормыш юлымны билгеләгән «чишмә башы» тату һәм хезмәт сөючән гаиләбездән, бигрәк тә әтиәнинең — әхлак өлкәсендә булсын, хезмәткә, кешеләргә мөнәсәбәттә булсын — үрнәгеннән башлана. Минем өчен иң олы максат — аларга лаек булып яшәү.

Гаилә миндә җаваплылык һәм мөстәкыйльлек тәрбияләде. Шуңа күрә, 7 сыйныфны тәмамлагач, Казанга техникумга укырга китәргә дигән беренче зур карарны да мөстәкыйль кабул иттем.

Казан мине колач җәеп каршы алмады: торак эзләргә, яшәп торырлык акча юнәтергә, бер үк вакытта яхшы укырга кирәк! Ләкин максат булганда, кеше барысын да җиңеп чыга.

Армия сафларында хезмәт иткәндә, мин космоска очу хакында хыяллана башладым. Бик күпләр шуның белән янып яшәгән еллар иде бит ул. Шуңа да кайтуга Казан авиация институтына укырга кердем, Мәскәүгә, космонавтлыкка кандидатлар төркеменә алуны сорап мөрәҗәгать тә юлладым әле. Әмма бу теләк хыял булып кына калды.

Ул арада диплом алынды, гаилә корып җибәрдем … һәм төзелеп килә торган Түбән Кама шәһәренә эшкә чакыру алдым…

Азат Зыятдинов – «Түбәнкаманефтехим» ААҖнең фәнни-тикшерү үзәге директоры. 2004 ел

Дөресен әйтим, Түбән Камага мин фатир алыр өчен генә килгән идем. Имеш, фатир алабыз да, аны Казанга алмаштырып, кире башкалабызга кайтып китәбез… Күрәсең, язмыш кемгә кайда яшәргә, нинди һөнәр буенча эшләргә кирәклеген үзе хәл итәдер. Без дә бик тиз үз иттек колхоз басуында үсеп килә торган бу шәһәрне, ә мин — урман кисеп төзелә башлаган «Нефтехимия»не. Хезмәт юлымны смена мастеры, смена начальнигы буларак башлаган урын — изопентаннан изопрен каучугы алу заводының бер цехы (И-2) иде. Ә изопрен каучугының шиннар ясау

өчен бик кирәкле чимал булуына да тиз төшендек. Мине инде Дивинил заводын, аның да ДБ-6 цехын төзергә цех начальнигы урынбасары итеп күчерделәр. Тегесен-монысын табарга командировкаларга йөрткәли башладылар, хәйран гына уңышлы кайта идем. Шунысын да әйтим: ярты ел да үтмәде, мине яшь белгечләр Советы рәисе итеп сайладылар һәм баш инженер җитәкчелегендә оешкан кадрларны үстерү комиссиясендә яшь белгечләрне үстерү буенча җаваплы кеше итеп билгеләделәр. Ул вакытта «Нефтехим»да 650 яшь белгеч эшли иде. Аларны малосемейка, балалар бакчасы, бакча өчен җир, фатир белән тәэмин итәргә кирәк.

Мин эшкә чумдым, бары да әйбәт бара кебек... Ә күңел уйлана. Төрле коллективларда булып, «Нефтехимия»дә төп белгечнең технолог икәнлеген һәм яшь белгечләр Советы рәисенең, гадәттә, профсоюз, сирәк кенә партия эшенә күчү перспективасын аңладым. Әмма мине партия-комсомол эше кызыксындырмый иде. Нәселемне күркәм яктан таныту, авылдашларым, якташларым алдында хөрмәт казану өчен, йөрәк нindидер зуррак эшкә тотынырга өнди. Әйе, миңа Мәскәүдә аспирантурада технология буенча укырга кирәк дигән уй керде.

1972 елның март аенда СССР профсоюзларының XV съездына делегат итеп сайладылар. Шул көннәрдә мин Д.И.Менделеев исемендәге Мәскәү химия-технология институтының кибернетика кафедрасы мөдире академик В.В.Кафаров янына аспирантура турында сөйләшергә кереп чыктым. Ул сынауга чакырды. Мин, киләсе елда барып, сынау бирдем һәм аспирантурага кабул ителдем. Әмма берләшмә җитәкчесе Н.В.Лемаев: «Дивинил» заводын эшләтеп җибәргәнче, бу хакта сүз дә булырга мөмкин түгел», — дип кырт кисте. Мин укырга китүне кичектердем, башкача ярамый иде.

Без заводны 1974 елның язында эшләтеп җибәрдек һәм мин кабат генераль директор янына киттем. Ул: «Азат, мин сине озак көттердем. Күрәсең, теләгең ихластыр, бар, укы, кайткач, бергәләп эшләүне дәвам итәрбез», — диде.

Бер елга соңга калып булса да, Мәскәүгә аспирантурага китеп бардым. Мөгаен, «чишмә башы» шуннан башланадыр. Ә теге укырга китә алмаган бер елны мин химияне өйрәнүгә багышладым һәм Эстәрлетамак химия заводында баш инженер булып эшләүче якташыбыз, фәннәр докторы Гарифҗанов Гәбделбәр абыйга күп функцияле реактор ясаттым. Рәхмәт төшкере, ул күгәрми торган корычтан җиренә җиткереп эшләп тә бирде. Без аны, ГПТУ-44нең директоры Василий Иванович белән килешеп, җитештерү корпусының экскурсияләр залына урнаштырдык, кирәк булган саен, кереп эшли идек.

– Түбән Кама химия сәнәгатен аякка бастыруда, аны үстерүдә Сезнең өлеш гаҗәеп зур. «Түбәнкаманефтехим» ААҖдә Сез керткән яңалыклар нидән гыйбарәт? Биредә эшләгән елларда ирешкән иң зур уңышыгызны атасагыз иде. Иң кыен сынау нинди булды?

— Д.И.Менделеев исемендәге МХТИның кибернетика кафедрасында уку минем эш потенциалымны күпкә үстерде. Икенче фәнни җитәкчем Писаренко Виталий Николаевич белән төрле нефтехимия заводларына бергә йөри башладык: карашларым үзгәрде, мөмкинлекләрем дә артты. Диссертация яклап, Түбән Камага фәннәр кандидаты булып әйләнеп кайттым. Академик В.В.Кафаров, Н.В.Лемаев чакыруы буенча «Нефтехим»га килеп, матур гына очрашулар узды, һәм алар, миңа фәнни эшемне дәвам итү өчен, каталитик синтез лабораториясе булдыруны кирәк тапты. Озак та үтмәде, ул эшли башлады. Без адсорбция, десорбция, диффузия, катализ процессларын өйрәнүгә зур көч куйдык, завод проблемаларын барлап, процессларны камилләштерүгә юнәлтелгән фәнни ачышларыбыз гәмәлгә кертелде: «СК өчен эреткечләр җитештерү технологиясе», «Нефтеполимер сумала табу технологиясе», «Лак-буяу материаллары эшләү технологиясе», «Н-пентанны изомерлаштыру процессын көйләү»,

«ЭЛОУ-АВТ җайланмасы өчен деэмульгатор», «Бутан чистарту процессы», «Автобензин җитештерү технологиясе», «Гади полиэфирларның яңа төрләре». Болар комбинатның нәтиҗәле эшләвен тәэмин итте һәм күпмиллионлы икътисади табыш китерде.

Заман таләпләре сәнәгать, бигрәк тә аның әйдәп баручы көче булган фән алдында яңа бурычлар куя. Әлбәттә, «Түбәнкаманефтехим»га да кагыла бу таләпләр. Шуның өчен берләшмәнең яңа җитәкчелеге моңа кадәр эшләп килгән фәнни берәмлекнең статусын «Фәнни-технологик үзәк» буларак үзгәртеп, аның эшчәнлеген көчәйтү максатыннан, җитәкчелекне миңа — техник фәннәр докторына тапшырды. Җитәкчелеккә энергияле, эш өчен янып торган белгечләр тупланды. Заводлар һәм фәнни лабораторияләр арасында уртак эш темалары ачыкланып, ике яктан да алар өчен җаваплылар билгеләнде. Эшләнгән эшнең күләменә һәм әһәмиятенә карап, заводлар үз фондларыннан лабораторияләргә премия билгели башлады. Бу җаваплылыкны ике яктан да арттырды һәм уңай нәтиҗәләр дә үзләрен озак көттермәде. Альфа-олефин заводының уңышлы эшли башлавы, иң катлаулы технологияле этилен заводының куәте күпкә арту, фәнни үзәк тарафыннан алынган патентлар һәм аларның җитештерүдә гамәлгә кертелүе — уңышлы хезмәт җимешләре. Без алар белән горурланабыз. Этилен заводындагы җитештерү куәтен күпкә арттыруга китергән яңалыклар «Фәнни-технологик үзәк»нең үзенә дә танылу китерде: үзәкнең бер төркем галимнәре һәм завод инженерлары Татарстанның фән һәм техника өлкәсендәге иң зур бүләгенә — Дәүләт премиясенә лаек булдылар.

Иң зур уңышларыбызның беренчесе — ул, әлбәттә, дөньяда өченче булып («Эксон» һәм «Байер» фирмаларыннан кала) галобутил каучуклары (бромбутил, хлорбутил) ясау технологиясен булдыру. Әлеге технология гамәлгә куелды, инде еллык җитештерү күләме 160 мең тоннадан артты.

Зур уңышларыбызның икенчесе — Россия хөкүмәтенең яңа төр бутадиен каучуклар алу буенча 705 миллион сумлык Дәүләт контрактын оту. Бу уникаль приборлар, тулаем автоматлаштырылган полимерлаштыру процесслары өчен тәҗрибә реакторы булдыру дигән сүз иде. Без дәүләт контракты таләпләрен уңышлы башкарып чыктык. Нәтиҗәдә, бутадиен каучугының неодим һәм литий катализаторларында алынган яңа маркалары булдырылды һәм гамәлгә кертелде. Аларның гомуми куәте инде 180 мең тоннадан артып китте. Яңа тәҗрибә реакторы СКЭПТ каучугының һәм АБС пластикның яңа маркаларын алу мөмкинлеге бирде. Илкүләм генә түгел, дөньякүләм яңгыраш алган зур җиңү бу.

Иң авыр сынау — изопрен алуның яңа технологиясен гамәлгә кую иде. Чөнки изопренны «иске» технология белән алу бик кыйммәткә төшә, аның рентабельлеге юк дәрәҗәсендә. Шуны күздә тотып, «Нефтехим» җитәкчелеге, әле тулысынча әзерләнеп җитмәгән проектны алып булса да, аны үзебезнең җитештерү шартларында өйрәнергә карар кыла. Кышкы салкыннар вакытында җитештерүдәгеләр дә, фәнни үзәк галимнәре дә тәүлекләр буе заводтан чыкмый: режим күрсәткечләрен күзәтә, анализлар ясый, лабораториядә сынаулар уздыра. Башкарылган эшләрне һәркөнне иртә-кич штабларда тикшерү, бәяләү алып барыла. Шундый авыр хезмәт салып, изопрен алуның яңа ысулы гамәлгә куелды, аның үзкыйммәте исә элеккеге технология белән табылганыннан күпкә түбәнрәк иде. Производствоның уңышлы эшләве тәэмин ителде. Бу бөтен берләшмә белгечләренең уртак җиңүе булды. Газаплы җиңү.

– Азат Шәймуллович, Сез – Татарстан Дәүләт Советы депутаты. Әлеге югары вазифа зур җаваплылык йөкли. Түбән Камада эшләгән елларда, зур үзгәреш елларында да Сез Татарстан Югары советы халык депутаты булгансыз. Соңгы ике дистә елда сайлаучыларның гозерләре

ның үзгәреш кичердеме? Шәхсән үзегез сайлаучыларыгызның нинди наказларын үтисез. Алар белән ничек аралашасыз?

— Мин үзем халык депутаты буларак сайландым, милли блокта булдым. Шәһәребез сәяси мәсьәләләрдә шактый активлык күрсәтте. Әйтик, хәлиткеч карарлар кабул ителгәндә, Казаныбызга Чаллыдан, Түбән Камадан байтак халык килә иде. Дәүләт мөстәкыйльлеге турында Декларация, Телләр турындагы Закон кабул ителгәнне халык уңай үзгәрешләргә өметләнеп көтте. Без өметләнгәнчә үк килеп чыкмады. Шунысын да онытмаска кирәк: халык исеменнән зур таләпләр куйганда, урам митингларындагы халык саны 30-40 мең түгел, 130-140 мең булса, ул үтемлерәк яңгырый.

Мин моңа ышанып әйтәм, чөнки Декларация һәм башка җитди карарлар кабул иткәндә, халык таләбе һәм милли мәнфәгатьләрне яклаучы халык депутатлары эшчәнлеге нәтиҗәсендә, җитәкчеләребезнең фикер үзгәртүләрен күп тапкырлар күзәтә алдым. Халык бердәмлеге — зур көч, үзенә тиешле ихтирам таләп итә. Әгәр дә инде халык бердәм түгел, фикерләрендә, таләпләрендә тәвәккәл түгел икән, аның депутатлары да төрле фикердә.

Гомумән, ул елларда депутатның эше сәясәткә корылган иде. Хәзер хәл үзгәрде. Бүген инде торак шартларын уңайлаштыру, эш урыны, дәваланырга ярдәм сорау ... ягъни матди мәсьәлә беренче планга чыкты. Көчемнән килгән бөтен наказларны үтәргә тырышам, үзем үти алмаганнары буенча район хуҗаларына мөрәҗәгать итәм.

– Азат Шәймуллович, Сезнең ир-егет буларак мәйдан тоткан елларыгыз Түбән Кама каласында эшләү чорына туры килде. Илебез картасында пәйда булып, зур тизлек белән үскән шушы шәһәргә милли төсмер бирүдәниләр эшләдегез? Әйтик, Түбән Камада оешкан «Җидегән чишмә» оешмасы 1980-1990 елларда милли мәдәниятебезне пропагандалау, татарларны берләштерү, күренекле әдәбият һәм сәнгать әһелләре белән аралашу, сәхнә аша милли горурлык тәрбияләү, милли үзаңны уятуда бик үтемле чара булды. Республикабызның иң яшь шәһәрендә шаулап-гөрләп узган «Җидегән чишмә»нең очрашу-кичәләре бер феноменга әверелде. «Җидегән чишмә» кемнәрнең идеясе? Аның эшчәнлеге турында сөйләп үтсәгез иде. Бүген мондый идеяне тормышка ашыру мөмкин булыр идеме икән?

1990 елларда татарларның милли азатлык хәрәкәтенә Казаннан битәр Чаллы, Түбән Кама кебек шәһәрләрдәге милли берләшмәләр, зур оешканлык күрсәтеп, гайрәт, көч биреп торды. Ул елларның күңелегездә сакланган иң якты хатирәләре нинди? Шәһәрдәге уңай үзгәрешләр нәтиҗәсендә, Түбән Кама «татар шәһәре» буларак кабул ителә башлады, гәрчә биредә төрле милләт вәкилләре яшәсә дә. Ничек итеп тиз арада шундый үзгәрешләрне тормышка ашыра алдыгыз?

— Иҗтимагый хәрәкәтнең төп зарурлыгы — аның милли идеяләр генераторы булуда һәм халыкны шул идеяләрне тормышка ашыруга туплауда. Ул рәсми хакимияттән алдарак барырга һәм аңа дөрес юнәлеш бирергә тиеш. Бу бик авыр бурыч, шулай да алдагырак чорында ТИҮ җитәкчеләре эшне шул таләпләргә җавап бирерлек итеп оештыра алды, күпләргә үрнәк булды. Бу — халкыбызның милли рухы тиешле дәрәҗәдә икәнен раслый торган дәлил, безнең горурлыгыбыз. Үткән юлга йомгак ясап, һич кенә дә куертмыйча әйтеп була: иҗтимагый хәрәкәтне оештыручылар, аның беренче җитәкчеләре, шул исәптән беренче президенты Марат Мөлеков та — татар халкының зур рәхмәтенә лаеклы кешеләр.

Түбән Камада Татар иҗтимагый үзәге, иң беренчеләрдән булып, 1989 елның мартында оешты. Шуңа күрә сайлауларга да байтак әзерлекле килә алдык. Беренче ирекле сайлауларда Татарстан Югары советына халык депутаты итеп сайланырга теләгән партия комитеты, башкарма комитеты түрәләре тәүге турда ук төшеп калды, үзләренең кандидатураларын кабат куярга җөрьәт тә итмәде. Күрәсең, шок хәлендәрәк калганнардыр. Ә яңа кандидатлар, ни сәбәптәндер, Татар иҗтимагый үзәгенә килеп, программалары белән таныштырды, фатиха алырга тырышты.

Түбән Камада милли рух бөтенләй юк дәрәҗәдә иде. Татарлар җыелса, сүз шул хакта зарланышудан башлана...

Шәһәребездә Рахмай Хисмәтуллин журналист буларак та, шагыйрь буларак та бу юнәлештә башлап йөрде. Наил Нуретдинов, яшьләрне җыеп, «Җидегән чишмә» исеме астында кичәләр уздыра башлады. Әмма халык йөрми... Кичәдән соң вестибюльдә кичке уеннар да оештырып карыйлар (моның уртасында — Флёр белән Рәзинә Гәйнемөхәммәтовлар!), ләкин халык барыбер килми, 800 кешелек залда 100-150 тамашачы утыра.

Шушы зарларны тыңлагач, мин сорап куйдым: «Әдәбиятта, сәнгатьтә исемнәре танылган, хөрмәт яулаган шәхесләрне чакырсак?» «Алар килмиләр!» — дип өзеп үк җавап бирделәр. Шуннан мин: «Әйдәгез, үзем чакырып карыйм», — дип куйдым. «Кемне?» — диләр. Уйларга 1-2 көн сорадым.

Сибгат ага Хәкимгә 70 яшь тулып килгән вакыт иде бу. Аңа чылтыратып, юбилей тантаналарын Түбән Камада да уздыру тәкъдимен ясадым. Ул бер сорау гына бирде: «Кеше җыя алырсызмы соң?» «Кеше җыярбыз, шигърият бәйрәме ясарбыз», — дип ышандырдым да кемнәрне алып киләсен сорадым. «Кеше ияртеп йөрергә дә рөхсәтмени?», — дип аптырады Сибгат ага. «Кемнәрне алып килсәгез дә, алар безнең олы кунакларыбыз булырлар», — дидем.

Сибгат ага 1-2 көннән очрашуның вакытын, килүчеләрнең исемлеген хәбәр итте. Мин боларны түкми-чәчми Рахмай белән Наилгә җиткереп, хәзерләнә башлауларын үтендем. Шәһәр идарәсен, Башкарма комитетны үз җаваплылыгыма алдым. Бөтен Түбән Каманы афишалар белән тутырдык. Халык тамашага билет эзли башлады: шәһәр уянды!

Мәсгут абый Сибгатов, «Нефтехим» берләшмәсенең генераль директоры урынбасары, кунакханә, кунак итү мәсьәләләрен хәл итте. Рахмай сценарий язды, Наил киләчәк очрашу белән янып яши башлады. Сибгат аганы елаткан «Фазыл чишмәсе»н җырлап, су алырга килгән кызларның шагыйрьгә чиккән кулъяулык бүләк итүе — Наил уйлап тапкан матур мизгел булды...

Кичә тамашачы белән туп-тулы залда, күтәренке рухта, чын мәгънәсендә бәйрәм кебек узды. Чын сәнгатьнең, әдәби сүзнең битарафлыкны җиңүе иде бу!

Беренче кичә безнең эшебездә яңа юнәлеш ачты: халыкны зәвыклы сүз, затлы әдәбият-сәнгать ярдәмендә уятырга, милли хисен үстерергә, кешелек сыйфатларын көчәйтергә мөмкин!

Шуңа күрә «Җидегән чишмә»нең советын булдырдык: аны Мәсгут абый җитәкләде, мин «кунак чакыручы» вазифасында калдым, Наил — сәхнә өчен, ә Рахмай сценарийлар өчен җаваплы дип килештек. «Җидегән чишмә» исә гөрләтеп эшләп китте, халкыбызның талантлы, сөекле улларын-кызларын шәһәребездә танытты, аларга да илһам, үз халкының җылы хисләрен тату мөмкинлеге бирде, ахыр чиктә, Түбән Каманы милли җанлы, милли йөзле шәһәр буларак таныта башлады. Мин чакырган, шәһәребезгә килергә теләп ризалашкан талант ияләре арасында Б.Урманче, Ф.Кудашева, Б.Гайсин, Г.Бәширов, С.Садыйкова, Р.Яхин, М.Госманов, Т.Миңнуллин, Н.Нәҗми, Ә.Атнабаев, Р.Таҗетдинов, Г.Ахунов, М.Мәһдиев, Х.Бигичев һәм башкалар бар иде, бу очрашулар Түбән Кама тарихының аерылгысыз бер сәхифәсенә әйләнде.

Бүген мондый идеяне тормышка ашыру мөмкин булыр идеме? Бәлки булыр да иде, тик моның өчен үз халкын сөйгән, аның теле, сәнгате өчен җан атып йөргән Наилләр, Рахмайлар, Мәсгутләр кирәк...

«Җидегән чишмә» шәһәрдә милли хисне, кешеләрдә милли үзаңны кузгатты, Татар иҗтимагый үзәге исә шушы омтылышны урам исемнәренә, һәйкәлләргә, милли мәктәпләргә, балалар бакчаларына, мәчетләргә күчерде. Түбән Камада Габдулла Тукай, Бакый Урманче, Сөембикә, Чулман, Чишмәле урамнары барлыкка килде, шәһәребезнең иң гүзәл бер бакчасында Тукаебызга Б.Урманче иҗат иткән бюст куелды. Бүген бу бакча шигърият бәйрәмнәре уздыру урынына әйләнде.

Шагыйрьнең йөзьеллык юбилее уңаен-

нан, Кырлайдагы утыртып эшләнгән Тукай һәйкәле (Б.Урманче хезмәте) бронзадан коелды. Иске һәйкәл, мәктәп бинасы артына илтеп куелып, кирәксез калды. Мин, Арча районы җитәкчесе В.Миңһаҗев белән килешеп, һәйкәлне Түбән Кама шәһәренә алып кайттым; Г.Исмәгыйлев аны Медсанчасть бакчасына урнаштырды.

2012 елда, бик зур тырышлыклар куеп булса да, М.Җәлил һәйкәлен ачуга ирештек. Монда рәхмәтебезнең иң олысы «Нефтехим» берләшмәсе белгечләренә һәм җитәкчеләренә барып ирешсә иде. Шәһәр җитәкчеләре һәйкәлне ачуны лаеклы бәйрәмгә әверелдерделәр.

Шәһәребезне дүрт манаралы җамигъ мәчете бизи, Б.Урманче, М.Җәлил исемен йөртә торган татар гимназияләре, татар мәктәпләре һәм балалар бакчалары эшли. Кешеләрнең максатчанлыгы, милләтенә һәм милли мәдәниятә мәхәббәте тормышны үзгәртергә, әллә ниләр башкарып чыгарга сәләтле.

– Соңгы дистә елда җәмәгатьчелек фикере милләтне берләштерү мәсьәләсенә зур игътибар итә башлады, көн үзәгенә куйды. Хакимият һәм бигрәк тә мәдәният оешмалары бу юнәлештә системалы эш башлады сыман. Сезнеңчә, бүген татар иҗтимагый фикерен, мәдәниятен үстерү өчен, ниләр эшләргә кирәк?

— Татар халкының бер йомшак ягы бар — ул таркаулык. Шуннан котылу өчен бүген дә нидер эшли алмавыбызны мин бер үзенчәлек белән бәйлим. Татар әдәбияты, татар сәнгате, гомумән, татар дөньясы күпләребез, бигрәк тә җитәкчеләребез өчен Татарстан кысалары белән чикләнә. Бу ялгыш караш тарихи барышта татар халкын зур югалтуларга китерде.

Әйтик, заманыбызның бөек җырчысы Фәридә ханым Кудашева татар булып, гомер буе татарча җырлап та, Башкортстан һәм Россия Федерациясенең атказанган җырчысы гына була килде. Бик күп таләпләрдән соң гына, бик соңарып Татарстан хөкүмәте аны танырга мәҗбүр булды. Шундый асыл былбылны — татар халык былбылын — зур мәдәни бакчабызның Татарстан дигән өлешенә кертмәскә тырышу, аны Башкортстан чикләрендә торуга дучар итү — үзе бер ахмаклык. Ә сөекле шагыйребез Наҗар ага Нәҗми? Аның «Татар теле», «Бар» (татар барда, хәтәр бар) шигырьләре һәм, халкыбыз мөстәкыйльлеген яклап, А.Руцкойга язган ачык хаты өчен генә дә аңа «татар халык шагыйре» исеме бирелергә тиеш иде. Болардан тыш күпме шигырьләр, фәлсәфи җырлар, пьеса, мәкаләләр рухи дөньябызның кабатланмас бизәкләрен тәшкил итә. Күрмәмешкә тырышабыз! Китапларын да басмыйбыз, хөрмәтләмибез дә, янәсе, алар безнеке түгел. Алар — татар халкының үги балалары…

Ә асылташ иясез булмас, аны табып алалар, үзләренеке итәләр, алар белән инде башкалар горурлана. Әлбәттә, кемдер ота, ә татар халкы югалта гына, йөзегебез асылташсыз кала. Шул рәвешле, халкыбызның бөек биючесе Галия Измайлова — СССРның халык артисткасы — үзбәкнеке булып китте, заманының бөек җырчысы, СССРның халык артисткасы — татар кызы — Фатыйма Мөхтәрова азәрбайҗанныкы гына булып калмады, татарның уена да кермәгән «Азәрбайҗан анасы» дигән зур хөрмәткә лаек булды. Моңа үз илендә үз халкына сыену тапмыйча, казах композиторы булып киткән Латыйф ага Хәмидине, җырчы Абдуллиннарны, үзбәк горурлыгына әверелгән татар рәссамы Чыңгыз Әхмәровны һәм башка бик күпләрне өстәп булыр иде. Әмма ни файда? Ул бит безнең югалту, бөеклегебезне, зурлыгыбызны, байлыгыбызны югалту, ваклана, ярлылана бару. Ә бөтендөнья балет йолдызы Рудольф Нуриев? Ирек Мөхәммәдиев? Кайчанга кадәр татарның зурлыгын, бөеклеген Татарстан кысалары белән чикләргә азапланырбыз, рухыбызны вакларбыз? Мәсьәләнең бүгенге куелышы һәм чишелү ысуллары башка төбәк батырларын кертмәгән район сабантуен хәтерләтә. Әлбәттә, кемдер батыр калыр. Ә чын батыр татар халык батыры булырмы соң ул? Без бит «татарның рухи дөньясы» дигән олуг вә гүзәл диңгезне

Бертуган Зыятдиновлар. Уңнан сулга: Сәйдәш (икенче бала), Бакый (беренче бала), Тәэминә (алтынчы бала), Илгиз (бишенче бала), Фәния (өченче бала), Азат (дүртенче бала). Арча шәһәре. 2006 ел, февраль

туендырган зур Иделләрне генә билгеләп үтәргә тиеш. Караш тарлыгыннан арынып, үз балаларыбызны үги итмик.

Шөкер, Татарстанның үз академиясе бар. Фән өлкәсендә дә санап үткән ялгышлар кабатланмасын иде. Академиябез халкыбызның чит илләрдә, Россиянең бөтен өлкәләрендә, БДБ илләрендәге барлык мәшһүр галимнәрен барлап, аларны Татарстан фәнен үстерүдә файдалана алса иде. Бу — фән аша халкыбызны, дәүләтебезне танытуда гаҗәеп отышлы чара. Академиябез уставында әтрафлы әгъзалыкка зуррак урын биреп, аңа читтәге бөтен мәшһүр, зур галимнәребезне кабул итик. Алар күп, изге Ватаннары Татарстан белән бик кызыксыналар һәм мөмкин булган ярдәмне дә күрсәтергә әзерләр. Файдаланыйк, көчләрне берләштерик!

Бүгенге халәтебезне күзаллаганнан соң, милләт буларак халкыбызны саклап калу, мөстәкыйль дәүләтебезне торгызу өчен, үткәннәрдән нинди гыйбрәтләр алып, киләчәккә нинди бурычлар куярга кирәклек тә ачыклана. Дәүләтебезне югалтуның төп сәбәбе — бердәмлек булмау: бердәм булыйк! Милли горурлыгыбызны югалттык — бу сабакларның иң куркынычы. Телебезгә, динебезгә, гореф-гадәтләребезгә, моңнарыбызга кайтып, милли горурлыгыбызны да торгызыйк! Горур халык кол булмас!

– Туган авылыгыз Таузар (Балтач районы) белән элемтәләр ныкмы? Туган якта, гомумән, авыллардагы нинди күренешләр сөендерә, кайсылары борчу тудыра?

— Туган авылым белән элемтә сакларга тырышам. Бөтен билгеле бабаларым да Таузар зиратында җирләнгән. Минем күңелем туган авылымда.

Куандырганы — яшьләрнең йорт салулары. Хәзер ике катлы, заманча, бөтен уңайлыклары булган кирпеч йортлар үсеп чыга. Мәктәп, балалар бакчасы төзелә. Болар авылга тагын да ямь өстәр дип уйлыйм. Борчыганы — кайбер авылдашларның балаларын укырга күрше авылларга йөртүе, рус мәктәпләренә бирергә омтылуы. Рухыбыз ваклануы, коллык, мескенлек психологиясе халкыбызга нык үтеп керде. Арысландай егетләребез, эчеп, ялкауланып, бозыклык, җинаять юлларына басты. Сылу, тыйнак, сабыр кызларыбыз, асыл сыйфатларын югалтып, бозык мохиткә кереп бара. Гаиләләр таркала. Тырышлык, чисталык, гаделлек, сүздә тору, гаиләгә бирелгәнлек кебек халкыбызның асыл сыйфатларына кайту кирәк. Авылдашларыма да, милләттәшләремә дә: «Рухыбыз бөеклеген саклап, зур максатлар белән яшик!» — дип эндәшәсем килә.

*Әңгәмәдәш — **Илдус Заһидуллин***

ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ ТАРИХЫННАН

НАРДУГАН ҺӘМ СӘҮМӘТ

РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ,
филология фәннәре докторы

АЗМЫ-КҮПМЕ ДӘРӘҖӘДӘ КУЛЬТУРАЛЫ ХАЛЫКЛАР ЕЛ АЛМАШУ НОКТАСЫН КӨН ОЗЫНЛЫГЫНЫҢ ЕЛ ТӘҮЛЕГЕНДӘ ҮЗГӘРЕШ МОМЕНТЛАРЫНА БАГЛАГАННАР. ТАТАРЛАРДА УЛ НОКТАЛАРНЫҢ АТАМАЛАРЫ БАР: НӘҮРҮЗ, ҖӘЙГЕ НАРДУГАН, СӨНБЕЛӘ КӨНЕ ҺӘМ КЫШКЫ НАРДУГАН.

Мәгълүм ки, тарихта ел башы үзгәртелеп торган. Тик ул һәрвакыт әлеге нокталарның берсенә нисбәт ителгән. Европада һәм якын Шәрыкта антик заманнардан бирле Яңа ел башы дип язгы көн белән төн тигезләнеш көнен — 23 мартны, ягъни Нәүрүзне кабул иткәннәр. Юраулар-да киң кулланыла торган зодиакаль айлар Нәүрүздән башлана. Шуннан соң кайбер халыклар, шул исәптән руслар да, Яңа елны Сөнбеләгә — 22-23 сентябрьгә күчергәннәр. Һәм бер-ара татарларда да Сөнбелә (Сөмбелә) көне (аны **Кыз сырасы** дип тә атаганнар, чөнки Сөнбелә сүзе «сары чәчле кыз», «башак» мәгънәләренә ия) ел башы булган. 1699 елда Пётр Iнең «Яңа елны бәйрәм итү турында» Указы чыга. 1700 елдан Россиядә яңа ел Көнбатыш Европадагы шикелле, Гайсә пәйгамбәрнең (Христосның) туган көненә нисбәтләнгән һәм зодиакаль системадан чыгарылган. Шуңа бәйле рәвештә татарлар да ел башы итеп кышкы Нардуган башланышын, ягъни 25 гыйнварны кабул иткәннәр. Нардуган бәйрәме үзе ике атна — Раштуага кадәр диярлек дәвам иткән.

Болар барысы да, гомумән, киң билгеле. Хәзер без халыкка аз мәгълүм булган шәйләрне язмакчыбыз.

Гаҗәп рәвештә, **Нардуган** сүзе монгол теленнән алынган дигән фикер таралган. Хәлбуки, монгол телләрендә *«нар», «наран»* — «кояш» сүзе бик билгеле булса да, **Нардуган** дигән бәйрәм атамасы юк. Нардуганның асылы-чыгышы бөтенләй үзгә. Ул Һиндстаннан килә. Һиндстанда **налада** дигән үлән, үсемлек бар. Аның кызыклы үзенчәлеге — бер үк үсемлектә чәчәкләрнең төрле төстә була алуы (андый үсемлекләр безнең якларда да очрый, ләкин бик үк күзгә чалынмалы түгелләр). Һәм менә Һиндстанда наладаны, күкшенгәме, бүтән төрле чүлмәккәме салып, төрлечә юраулар өчен файдаланганнар. Әйтик, бер мән: «Фәлән төстәге чәчәк кулга эләксә, теләгем үтәлә», — дип юрый да, чүлмәктәге наладаның бер чәчәген өзеп, яктыга чыгара. Атаган чәчәге

чыкса, яхшы фал була һ.б. Тора-бара бу юрау катлауландырылган, төрле вариантлар барлыкка килгән.

Налада юравыннан *нард* уены үсеп чыккан. Бу уенда ике уенчы өсләренә саннар язылган фишкаларны тигез бүлешеп ала да махсус янчыкларга яшерә. Шуннан нард тактасына төшерелгән дүрткеллекләргә (яки нокталарга) фишкаларын куя башлыйлар — кая, ничек кую фишкаларга язылган саннар буенча башкарыла. Кәрт уеныннан аермалы буларак, уенчы нинди фишка эләгәчәген үзе дә белми.

Нардуган юраулары **нард** уены нигезендә яисә шуңа параллель рәвештә үскән. Баштан ук ул календарь юрау булган. Иранда бу уен-юрау (аңа зур әһәмият бирмәгәннәр) **нарди-оган** (*оган* аендагы *нард*) дип, Төркиядә *нард-у-фал* (нард буенча фал) дип аталган.

Нардуган юраулары тәүге чәчәкләр ярдәмендә башкарылган, Төркиядә чүлмәккә төрле чәчәкләрне салганнар һәм уен башчысы юрау китабыннан исемсез генә бер юралыш билгеләгән. Безнең якларда җиде яки җитмеш җиде төрле чәчәк салып юрау билгеле булган. Уен-юрауда катнашучылар үзләре өчен бер чәчәк исемен атаганнар. Шуннан уен башчысы, кулын күкшенгә тыгып, берәр чәчәкне тартып чыгарган. Юралыш шул чәчәкне атаучыга нисбәт ителгән. Җәйге нардуганда безнең якларда да чәчәкләр табу кыен булмаган, әмма кышын алай түгел. Шунлыктан күкшенгә чәчәкләр урынына исемле йөзекләр салганнар.

Бу уенны төрлечә катлауландырганнар. Мәсәлән, күкшенгә тутырасы суны Яңа ел башында — төнге сәгать уникедә бәкегә барып алганнар. Чөнки дөнья хәлләрен белеп торучы су җеннәре-шүлгәннәр нәкъ шул вакытта бәке аша ачык дөньяга чыгып йөриләр икән.

Бу Нардуган юраулары турында мин берничә тапкыр язып чыккан идем. Хәзер менә тагын бер кызыклы юрау — Сәүмәт турында беренче тапкыр язам.

Сәүмәт юраулары XIX гасырда ук онытыла башлаган инде. Шунлыктан аны хәтта фольклорчылар да белмиләрдер әле. Ул керәшен татарларын өйрәнгән Б.Г.Гаврилов мәкаләләреннән генә билгеле.

Сәүмәт — Яңа ел (безнеңчә — астрономик Яңа ел) төнендә ук атып юрау ул. Һәм аның кызыклы тарихы бар.

Борынгы гарәпләрдә ук атып юрау гадәте булган. Бу юрау өчен махсус «изге» уклар әзерләгәннәр. Ул укларны аерым хөрмәтле кешеләр үзләрендә саклаганнар. Шундый кешеләрдән Мөхәммәд пәйгамбәрнең дәү әтисе Габделмоталлап булган. Бермәл Аллаһтан күп догалар кылып, корбаннар биреп кенә сорап алуга ирешкән углы Габдулла нindидер сәбәпләр белән (сәбәпләре хакында мең ярым ел бәхәсләр бара) үтерелергә тиеш булган. Габделмоталлаб үзе хәким-судья була торып, үз улын үтерергә теләмәгән. Һәм җәмәга белән озак сөйләшүләрдән соң, хөкемне әлеге **сәүмәт** (гарәпчә — *сәхүмәт* — *сәхм* — «ук» сүзеннән) ярдәмендә үзгәрткән.

Күп тапкырлар юраулар соңында, үлем хөкеме йөз дөя корбан итү белән алмаштырылган. Габдулла исән калган. Хәер, ул озак яшәмәгән... Габделмоталлаб үз углын аклатуга ирешсә дә, дошманнары онытмаган бугай. Гадәттәгечә, Фәләстингә сәүдә кәрваны белән барганда, ул бер тукталышта кинәт үлеп киткән.

Менә шул вакыйга — үлем хөкеме йөз дөя бирү белән алмаштыру истәлегенә мөселман халыкларда Яңа ел кичәсендә ук ату гадәте калган. Мөселман тарихчылары хәзерге фейерверкны да шул вакыйгага баглыйлар.

Гомумән, татар халкында Яңа ел юрау һәм күңел ачу мәрәкәләренең күп төрләре билгеле. Без биредә шуларның икесенә генә туктадык. ■

Әдәбият

Мин дөньядан күпне өмет итмим,
Шигъриятькә яшим табынып.
Мин бәхетле — кеше күңелендә
Бер шигырем янса кабынып.

Разил Вәлиев

КУТАДГУ БИЛИК*

(Котайткыч белем)

ЙОСЫФ БАЛАСАГУНИ
(ЙОСЫФ ХАСС-ХАҖИБ)

Илбик әйтте: «Белдем, ачылды сүзең,
Гозер сорадың һәм котылдың үзең.

Миңа әйт инде — никадәр ирдәмең[1]?
Югары очасың болай телдә син».

Айтулды әйтте: «Күп миндәге ирдәм,
Күп кешегә тия миңардан ярдәм.

Кылмышым өметле, зур түгел яшем,
Барча бәк-өлкәнгә күптер хөрмәтем.

Йөзем күрекле һәм кылыгым гүзәл,
Ирешәм мин һәрбер максатка бермәл.

Кай капканы каксам, шунсы ачылыр,
Дошманча булмас һәм минемчә булыр.

Ләззәт тулы юлым, читләшә михнәт,
Сөенеч каршылый һәм кача хәсрәт.

Миңа карышканнар үләр азапта,
Миңа буйсынганнар җитәр максатка.

Мине екмакчылар үзләре ава,
Мине басмакчылар басылып кала.

Әйткәнемә дәлил — бардыр бер мәкаль
(Ишетсәң, белекле кеше, отып ал):

Бәхет кайда булса, шунда бар, йөре,
Кусалар да, көрәш һәм кайтма кире.

Бәхеттә бәхетле була белегез,
Бәхеттән шашмасын теләкләрегез!»

Илбик әйтте: «Белдем шәплекләреңне,
Кимчелекләреңне әйтеп бир инде».

Айтулды әйтте: «Кайбер кешеләр генә
«Кимчелегең бар», — ди. Көнчеләр генә.

Алар тинтәк диеп мине яманлый,
Белем сөюемне яшьлек дип аңлый.

Бу сыйфатым бер дә түгел яманлык,
Белем кирәк миңа, кирәк яңалык.

Бар иске нәрсәләр булыр кирелек,
Кире нәрсә исә — җирәндерерлек.

Яңасы булганда, янганы нигә?
*Яхшысы булганда, яманы нигә?***

Яңа нәрсәләрнең күп була таты,
Тырыша ир — татлы аның максаты.

Мине шуның өчен ваемсыз, диләр,
Ваемсызлык өчен гел гаеплиләр.

Бу бапта ап-ачык әйткән бер алпар[2]
(Югарыдагыны сүзе исбатлар):

«Гомер дигәнең бер җил кебек кичәр,
Җил алып киткәнне кем куып тотар.
Түрәгән[3] һәрнәрсә үлемгә дучар,
Түрәтүче зат ни теләсә — эшләр».

Куанма бәхтеңә — килер дә китәр,
Ышанма байлыкка — артыр да бетәр.

---

* Дәвамы. Башы журналның 2013 елгы 10, 11, 12 нче саннарында.
** Курсив илә язылган юллар нәкъ оригиналдагыча, тик сүзләрнең фонетик йөзе генә борынгыча.
[1] Ирдәм — ирләргә хас асыл сыйфатлар (түземлек, эш сөючәнлек, олы җанлылык һ.б.).
[2] Алпар — герой.
[3] Түрәү — барлыкка килү, туу.

Бу дәүләт дигәнең, тинтәк булмаса,
Кузыем[4], шәп булыр иде ләбаса.

Килгән дәүләт китмәс булса әгәр дә,
Төнгә әверелмәс иде көннәр дә».

Илбик әйтте: «Белдем елгырлыгыңны,
Ләкин холкыңда бер карар булырмы?»

Һәм Айтулды әйтте: «Юктыр карарым,
Җор[5] кебек елгырмын — әйтәмен барын.

Мине эстәгәннәр тапмас тиз генә,
Тапсалар да, сала алмаслар йөгән.

Мине тапкан кеше нык тотсын, бөреп,
Качалмаслык итеп, әйтәм, кистереп».

Илбик әйтте: «Ниткән бөреп тоту ул?
Нәрсә ул һәм ничә өлештән торыр?

Әйт, Айтулды, бөреп тоту ул ничек?
Сине бөреп тотыйк дип, хәзер нишлик?»

Айтулды әйтте: «Шул миңа бәй-кешән,
Берничә нәрсәдә, күр, бирим нишан[6].

Мине тапкан кеше саф, алчак[7] булсын,
Күңеле, теле-сүзе дә йомшак булсын.

Тотнаклы булсын ул — горур булмасын,
Яман-явыз эшкә якын тормасын.

Чамасында тотсын булган байлыгын,
Эзлекле күзәтсен юлын-юрыгын.

Үзеннән олыга хөрмәт күрсәтсен,
Үзеннән кечегә җылы сүз әйтсен.

Шәпләнеп, һичкемгә хөсет кылмасын,
Кечеләрне мыскыл итеп көлмәсен.

Гамьсез йөреп, хәмер шәраб эчмәсә,
Ялкаулыктан малын-ниен чәчмәсә,

Тотылмаса төрле хәйлә-мәкергә,
Булса шәп холык һәм тугрылык бергә —

Болар бары котны саклау нишаны.
Шулар булса бәхет-кот качмас, калыр.

Әйткәнемә дәлил — бер шагыйрь сүзе
(Шагыйрь сүзе, диләр, хакыйкать түзе[8]):

«Дәүләт киек кебек — кача кешедән,
Әгәр тотып алсаң, шундук кешәнлә.

Асрый белсәң әгәр, илләшер[9], торыр,
Тик асрый белмәсәң, качар, ычкыныр».

Илбик әйтте: «Кучтым, моңа төшендем,
Сөйдем сине, син тик качасың инде.

Булмаса гамьсезлек вә исәрлегең,
Ни шәп булыр иде миңа килүең.

Вәләкин гамьсезсең һәм дә вафасыз,
Бирәсең гел вәгъдәсезлек җәфасын.

Берара анадан шәфкатьлерәк син,
Гүя, уч төбендә генә йөртәсең.

Берара күрмисең — йомыла күзең,
Бөтенләй үзгәрә холкың һәм сүзең.

Җыясың да кинәт барсын чәчәсең,
Мин чакырам, ишек ябып качасың».

Ә Айтулды әйтте: «И, котлы илбик,
Бар яхшы һәм яман ягымны белдең.

Мине тапкач, ныклап тотыйм, дисәң син,
Әйтеп бирдем — үзең хөкем йөртәсең.

---

[4] Кузый — кәҗә бәтие, борынгы телдә тиктормас малайларга иркәләү сүзе.
[5] Җор (йор) — кыр кәҗәләренең бер төре (хәзерге көндә юк — кырып бетерелгән). Чагыштыр: русча — юркий.
[6] Нишан — күрсәткеч (указатель).
[7] Алчак — ачык күңелле.
[8] Татар сөйләшләрендә түз — «нигез, үзәк» (Мәкаль: Картлар сүзе — акыл үзе).
[9] Илләшү — ятлар белән килешү, дуслашу.

Мине тотып, башка бөркәү салмасаң,
Киектәй качам мин — җитә алмассың.

Ни ди, ишет, күпне сынаган бер карт
(Тәҗрибәле картлар сүзен тоту шарт):

«Бәхет килсә, китә, тота белмәсәң,
Ала биргән ашын, әгәр җиймәсәң[10].

Бәхет — елгыр, тапсаң, изге бел аны,
Сакламасаң, ышан — ул китте, барды».

Илбик әйтте: «Болар да аңлашылды,
Тик әйт: ни белдерә исмең — Айтулды.

Нидер ул, мәгънәсен әйтеп бир миңа,
Белим һәм ышаныйм әле бер сиңа».

Һәм әйтте Айтулды: «Минем атымны
Атаганнар, айга тиңләп затымны.

Ай туганда, тәүдә тар гына була,
Тик көннән-көн артып, бөтенләй тула.

Ай тулыша, күкне-җирне яктырта,
Кинәнә бар дөнья шундый яктыга.

Тәмам тулып җиткәч, соңгы мизгелдә,
Ай кими башлый — моң керә йөзенә.

Кими, кими ай һәм беркөн юк була,
Тагы бер кич үткәч, бар була һилал[11].

Менә мин үзем дә нәкъ шул төслемен,
Әле бармын, әле юкмын-гизлемен.

Йончыган кешегә йөзне борсам да,
Аның күрке арта, шулай, чыннан да.

Берәү баеп, калкып, таралса даны,
Барсы юкка чыгар, ташласам аны.

Таралыр-чәчелер җыйган маллары,
Элеккедән түбән төшәр аннары.

Монда бик бап килә бер шагыйрь сүзе
(Шагыйрь сүзе — надан кешегә күзлек):

Кешегә кот кунса, аты дан алыр,
Тулган айдай калкыр, балкыр нурлары.

Тик тиле бәхеттән булма һавалы:
Һәр кямалның, шиксез, була зәвалы[12].

Янә мәгънәле бер сүз әйтим сиңа,
Ышан да игътибар ит менә шуңа.

Бөреҗләрдә айның анык өе[13] юк:
Әйләнеп-тулганып йөри боегып.

Сәратан[14] бөреҗе, диелә бу ай,
Аның йолдызлыгы әйләнер булгай.

Кай бөреҗгә керсә дә, ай тиз чыга,
Гүя кунак хуҗа гозерен[15] ега.

Күр, мин үзем дә шуның шикелле:
Кәефем берчә шәп, берчә — төшенке.

Киләмен-китәмен, йөреп торырмын,
Дөньяны гизәмен, юк бер урыным.

Шунлыктан исемем Айтулды — ай мин,
Фикерле бер белкә кушкан шулай дип.

Мин — дәүләтмен, аның моң һәм ирдәме,
Әйтеп бирдем шуның чирен һәм ямен.

Хезмәтемдә калдыр, әгәр теләсәң,
Теләмәсәң инде — үзең беләсең».

Илбик әйтте: «Тыңлап барча сүзеңне
Күңлем яктырды, белдем үзеңне.

[10] Җий-ү — тәмләп ашау.
[11] Һилал — яңа туган ай.
[12] Кямал — камиллек, зәвал — бетү, югалу. Татар мәкале: «Һәр кямалның зәвалы була». Безнең тәрҗемәдә шул кулланылды. Төп текстта бу мәкаль юк.
[13] Бөреҗ өе — зодиакаль йолдызлык (алар унике була).
[14] Сәратан — зодиакаль ай исемнәренең берсе, кысла.
[15] Гозер — үтенеч.

Теләр идем күптән синдәй кешене,
Тәңре бирде ирнең асылын — сине.

Ходай теләгәнен бирсә кешегә,
Моңа җавап булыр мең шөкер генә.

Моннан соң миңа һич армый-талмыйча,
Шөкер кылу кирәк бер туктамыйча.

Ни ди, ишет, әнә акылдар белкә
(Үзе киткән, китап калдырган безгә):

«И, нигъмәт иясе, исән-тыныч тор:
Шөкер ит — шөкерең бәхет арттырыр.

Нигъмәт иясе еш оныта шуны —
Шөкер итсәң, нигъмәт тагын артуны.

Азын күп дип шөкер кылыгыз,
Ә күп булса, нигъмәт кадрен белегез.

Бер шөкердән нигъмәт арта ун тапкыр,
Һәрбере ун булып әйберең артыр».

Илбик алкышлады бу Айтулдыны:
«Кичә-көндез миңа якын бул», — диде.

Күп бирде мал-туар һәм күп мактады,
Алтын-көмеш белән дә бүләкләде.

Барча сүз һәм серен бүлеште илбик,
Аңардан сорады киңәш һәм белек.

Айтулды да, күреп мондый хөрмәтне,
Булды чын күңелдән тугры хезмәтче.

Бераз вакыт узгач, уйлады илбик:
«Барыннан да уңай бу хезмәткәр», — дип.

КӨНТУГДЫ ИЛБИК АЙТУЛДЫГА
ӘКӘМӘТ РӘВЕШТӘ КҮРЕНӘ

Шулай беркөн илбик ялгызы калды,
Бөтенесен куып, уйларга талды.

Иректе. Чакырды: «Керсен Айтулды».
Теге керде. Торды, кушырып кулны.

Илбиккә тегеп күз, тек-үрә катты.
Илбик ачмады сүз беркадәр вакыт.

Ымлады аннары күзләре белән:
«Килеп утыр, — диеп, — урын бар менә».

Утырды Айтулды әкрен, сак кына,
Инде җиргә карап, куркыбрак кына.

Илбиккә астыртын гына күз салды:
Чырае җимерек, йөздә — усаллык.

Көмеш көрсиендә ул утыртмакта,
Ә көрси никтер нык өч аякта.

Кулында бер үткен пычак, бик хәтәр,
Сул ягында агу, уңында — шикәр.

Безнең Айтулдыбыз, күргәчтен моны,
Курыкты, хәтта ки куырылды тыны.

Бераз торгач, башын күтәрде илбик,
Айтулдыга дәште: «Якынрак кил, — дип. —

Ник эндәшмисең — нәкъ телсез һәм аңсыз —
Мине монда күреп бу хәлдә, ялгыз?»

Һәм Айтулды әйтте: «И, илбик, котлым,
Үзем сүз башларга мин ничек кыйыйм?

Бүген кыяфәтең шәп түгел бер дә,
Имәнәмен шуңа, и, зирәк белкә.

Бер акылдар, әнә, халыкка әйткән:
«Якын барма, — дигән, — ярсыган бәккә».

Тагын да яхшырак әйткән бер белкә:
«Агу һәм ут кебек ачулы бәкләр.

Әгәр бәк пошынып, булса ачучан,
Якын килмә аңар, акыллы булсаң.

Әгәр бәк пошынса, ачуы килеп,
Ерак тор — чирләрсең, зәхмәте тиеп».

Бу уңайдан килә бер сүз хәтергә
(Аны искә ал һәм онытма бер дә):

«Ачуланса, килмә син бәккә якын,
Югыйсә намусың тапталыр, хакың.

Көр арыслан кебек бәкләр ул чакта,
Башыңны да кисәр, и, фикре яктым».

Илбик әйтте: «Ачык әйт әйтер сүзең,
Нигә гаҗәпләндең, шулай да, үзең?»

Һәм Айтулды әйтте: «Гаҗәбе шулдыр:
Ни белдерә көмеш көрси — бу урдың?[16]

Икенчедән, пычак нәрсәгә тагын?
Бик аңлыйсым килә мәгънәсен аның.

Өченчедән, нигә уңдагы шикәр?
Һәм сулдагы агу нәрсәгә сиңар?

Багып күрсәм исә — ачулы идең.
Бу хәлеңне күргәч аклымны җуйдым.

Син ачулы булгач, имәндем үзем,
Нинди сүзләр әйтим, ничек тел языйм?»

КӨНТУГДЫ ИЛБИК АЙТУЛДЫГА
ГАДЕЛЛЕК СЫЙФАТЫН АҢЛАТА

Илбик әйтте: октым[17] сүзең билгеләп,
Ачыймчы сүземне сиңа өлгеләп.

Мин сине күргәч үк чакырганда,
Урын бирдем хөрмәт белән янымдан.

Таң калырлык эшләр сөйләп күрсәттең,
Әмма асылыңны син яшергәнсең.

Ачуландым шуңа һәм син курыктың:
Каһәремне күреп калдың ич тып-тын.

Син әйттең: «Мин котмын, шуны тор белеп,
Сиңа төшендерәм, аңла, төшенеп».

Ниләр әйткән булсаң — озак шәрехләп,
Аңларга тырыштым, йөрдем хәтерләп.

Гозереңне кабул иттем, кичердем,
Кадереңне белдем эшең өчен мин.

Һәм менә бүгенге бу кылыкларым
Сиңа әзерләгән җавап һөнәрем.

Мин инде сурәте гадел хөкемнең,
Үземне күрсәтим — шуны телимен.

Бу үзем утырган көрси, күр аны,
Өч аяклы. Нигә икән, туганым?

Чөнки өчаяк ул аумый — селкенми,
Һәм бер аягы да буш тора белми.

Әгәр өч аякның булмаса бере,
Торалмас көрси — ул авар, түңелер.

Өчаяклар һәрчак тотрыклы шулай,
Дүртаякның берсе чатан булгалый.

Ни тотрыклы булса, ул бөтен шиксез.
Бөтен кемсәләрнең кылмышлары төз.

Ни нәрсә тигезсез, селкенеп торса,
Аның асылында була бер ноксан.

Селкенүчән нәрсә авып та китә,
Селкенмәсә исә, аумый ничек тә.

Минем карарым да икеләнүсез,
Ничек кенә булсын — хәл кылам үзем.

Гаделлек буенча карар кыламын,
Бәкме, әллә колмы — карамыйм аны.

Хөкемем минәзе[18] — менә бу пычак:
Кирәк — кисәчәк ул, кирәк — чәнчәчәк.

Пычак кебек катгый карар чыгарам,
«Юк!» — димен, нигезсез дәгъваны карап.

Шикәр — миннән ярдәм сораучыларга,
Капуыма килеп торучыларга.

Алар китәр миннән шикәр-бал кабып,
Кашлары язылып, сөенеч табып.

Агу исә шундый кешеләр өчен:
Гаделсезлек кыла, кулланып көчен.

[16] Оригиналда — уруң. Татар сөйләшләрендә урдын — туку ыстаны.
[17] Себер сөйләшләрендә дә ок-у — «оту, аңлап алу» (оригиналда шул сүз бар).
[18] Минәз — образ (кайбер әдипләр бу сүзне русча «образ» урынына кулланалар да инде).

Җәнҗалчыга шундый хөкем чыгарам —
Миннән агу капкан кебек чыгалар.

Бу каш төюләрем, усал чыраем —
Көчләү-талау әле күп, дип уйлавым.

Кирәк — углым, кирәк — якын-ерагым,
Кирәк — ут, кирәк — су, кирәк — кунагым.

Бийлек бизмәнендә барсы да тиңдер:
Берәү дә имтиаз тапмастыр миндин.

Гаделлек бизмәнем өчен тиң барсы:
Берәве дә аерым яклау тапмастыр.

Бийлекнең нигезе, бел ки, тугрылык,
Тугрылыклы бийнең булыр абруе.

Шуның кебек һәрбер акыллы кеше
Тугры сүзне тотса, уңар һәр эше.

Тугрылык, димәк ки, бийлек дивары,
Ә нигезе — тугры бару юллары.

Гадел, тугры булып калалса илгә,
Киләчәк теләгән уңышы бийгә».

Сорады Айтулды: «И, котлы илбик,
Нилектән аталдың син Көнтуды дип?»

Илбик әйтте: «Холкым булсын дип күркәм,
Кояштай булсын дип куйган бер белкә[19].

Кояшны күр: һәрчак туп-тулы тора,
Яктысы сүрелмәс туп булып тора.

Минем кылмышларым да шуңа охшаш:
Беренчедән, миңа гадел караш хас,

Икенчедән, һәркөн вактында чыгып,
Һәркемне тиң күреп яктырта кояш.

Минем кагыйдәм шул: югалмыйм үзем,
Һәр инсанны тигез күрәдер күзем.

Өченчедән, кояш җылыткач җирне,
Язын дала чәчәк ата мең төрле.

Каю җиргә җитсә минем хөкемем,
Кыя-таш булса да, гөлгә төрелер.

Чыгар кояш яхшы-яман, димидер,
Җылы-яктыны һәркемгә тиң бирер.

Минем дә кылыгым шундый, билгеле,
Илемдә һәркемгә тия тиң өлеш.

Тагын шунсы бар: тик кояш берүзе
Һичкайчан үзгәртми торган бөреҗен.

Арыслан бөреҗе бүген — тибрәнмәс,
Тибрәнмәгәч, юлдан читкә тибелмәс.

Талигым чагыла минем холкымда:
Үзгәрмичә янам яшәү утында».

АЙТУЛДЫНЫҢ ИЛБИККӘ
АҢЛАТМАСЫ

Һәм Айтулды әйтте: «Котлы солтаным,
Киңәйсен илең һәм таралсын даның!

Сиңа үзем килдем, озын юл йөреп,
Мәшәкатьләр чигеп, арып, тилмереп.

Синең шундый холкың, ирдәмлекләрең
Өчен тырыш хезмәт итү теләгем.

Әйтеп бир: нишләргә, ни күверергә,
Ни эш илә сезне сөендерергә?

Ниләр эшләсәң дә, бий шатланмаса,
Хезмәтең мәгънәсе китә ләбаса.

Ни ди Ила[20] ире — котлы, ирдәмле,
(Хезмәт илә хөрмәт табу үрнәге):
«Биләр теләгәнчә, тырышып эшлә,
Һәм сиңа ачылыр барча ишекләр.

Белеп хезмәт итсәң — урының түрдән,
Әгәр каршы килсәң — төшерсең күздән.

---

[19] Белкә — мәҗүси мулла.

[20] Или елгасы буе булса кирәк. Или — Балкаш (Балхаш) күленә коя торган зур елга, караханилар дәүләте Или бассейнын биләгән.

Сөендерә генә хуҗаны колы,
Ачылачак аңар уңышлар юлы».

ИЛБИКНЕҢ АЙТУЛДЫГА
ҖАВАП СҮЗЕ

«Сүзеңне тыңладым инде, — диде бий, —
Мине дә сөендер, үзеңне дә бел.

Сиңа әйтеп бирим: ниләр яраксыз,
Нәрсәдән азат бул һәм дә ерак тор.

Мин иң яратмаган нәрсә — ялган ул,
Яратмыйм, шулай ук көчлек кылганны.

Каты кыланса кол, сок[21] булса үзе,
Кызып китүчән һәм оятсыз күзле,

Явыз-усал яки үпкәчел холык,
Эшлексез, эчүче йә кулы кыек —

Мондыйлар кирәкми, ярамый миңа —
Шуны ачык әйтеп куямын сиңа!

Ярыйм дисәң миңа, и, егет кучтым[22],
Мәкүр юньсезлекләр сиңа ят булсын.

Шулай итсәң, миңа якын торырсың,
Кадер-абруеңны гел арттырырсың».

АЙТУЛДЫНЫҢ ИЛБИККӘ СОРАВЫ

Һәм Айтулды әйтте: «Ишеттем моны,
Тагы бер сорау бар — әйтеп бир шуны:

Кем ул изге дигән, нинди кылыклы,
Нинди кеше була изге холыклы?»

ИЛБИКНЕҢ ҖАВАБЫ

Илбик әйтте: «Изге — ул шундый кеше —
Халыкка файдалы һәрбер кылмышы.

Бөтен халыкка ул кылыр изгелек
Һәм һичкемгә михнәт кылмас, и, егет!

Кешегә — һәркемгә файда китерер,
Азрак алыр илдән һәм күбрәк бирер».

АЙТУЛДЫНЫҢ ТАГЫН БЕР СОРАВЫ

«Янә аңлашылды, — диде Айтулды, —
Тагын бер теләгән соравым калды:

Миңа син тугрылык турында сөйлә,
Аның яктылыгын, нурын да сөйлә!

«Тугрылык юлы», дип әйткәннәр — ни ул?
Һәм ничек табыла икән андый юл».

ИЛБИКНЕҢ ҖАВАБЫ

Әйтте илбик: «Будыр тугрылык төше[23]:
Телең, күңлең белән берегә эшең.

Тышы эче кебек, эче нәкъ тышы.
Менә шундый була чын тугры кеше.

Күңелен учына тотып күрсәтсә,
Оялырлык булмас шунда һичнәрсә.

Тугрылык бәхетнең үзе белән бер,
Иң тугры — иң дөрес кеше буладыр.

Кеше кыйммәт түгел, кешелек кыйммәт.
Тугры, чын кешегә мактау вә хөрмәт».

АЙТУЛДЫНЫҢ ТАГЫН БЕР СОРАВЫ

Һәм әйтте Айтулды: «Бәхетле илбик,
Инде бу сүзләрнең мәгънәсен белик:

Изге кеше исәр була аламы?
Исәр изгелекккә ирешәләме?»

ИЛБИКНЕҢ ҖАВАБЫ

Илбик әйтте: «Изге ике төрледер:
Берсе яхшы юлдан гына йөридер.

Ул изге зат булса тумыштан изге,
Тугрылык юлыннан ул чыкмас инде.

[21] Сок — һәрнәрсәне үзенә алырга торган, комсыз.
[22] Кучты — дус хезмәтче, «ординарец».
[23] Тош — ядро, үзәк.

Икенче төрлесе ясалма була.
Яманга катылса, яман да була.

Ике төрле була исәр яманнар,
Икесе дә бериш дип үк санала.

Яман булып туган икән кайбере,
Тәмам үлмәенчә юылмас кере.

Үзгәрүчән була кайбер исәрләр:
Аларны изгеләр изге итәрләр.

Туа изгеләрнең рухы нурлыдыр,
Алардан бар дөнья канәгать булыр,

Туа[24] яман булса, юк дару уты:
Бәла ул дөньяга, халыкка йот[25] ул.

Бу хакта төркичә бар яхшы мәкаль
(Ишет миннән, отып, хәтереңә сал):

«Ана сөте синең җанга ни салыр,
Кабергәчә шул аң күңлеңдә калыр».

Туган табигатең калыр шул килеш,
Үлем бозмаганчы, бозылмас, имеш,

Карында барлыкка килгән хәтерең
Кара җир куйнына китәр, батырым.

Әгәр яман белән дус булса изге,
Аның үз холкы да бозыла инде.

Әмма изге кеше сөйсә исәрне,
Ул аны, юл табып, изге итәрлек.

Тагы бер күренеш: изге һәм исәр
Бергә булса, кайчак төз юлдан китәр.

Бийе изге булса, халкы төз була,
Йөреш-торыш, холкы шелтәсез була.

Бийләр изгеләрне якын итсәләр,
Изге булып китә барча исәрләр.

Бийләр яманнарга иш-дус булсалар,
Яманнар халыкка, илгә кул сала.

Яман баш күтәрсә, изгегә юк көн.
Яхшылар күп булса, яманга читен.

Никадәрле изге булсалар бәкләр,[26]
Бөтен халык изге була шулкадәр.

Илдә бәкләр булса явыз һәм тупас,
Сөенеп елмайган кеше табылмас.

Дөрес эшли бик тә идарәчеләр,
Яманны зинданга бәреп кертсәләр.

Әгәр яхшы булса илнең башчысы,
Яхшы эшләр эшли халык — барчасы.

Әгәр бәкләр яхшы булса үзләре,
Халык баер, барча дөнья төзәлер».

АЙТУЛДЫНЫҢ ТАГЫН
БЕР СОРАВЫ

Һәм әйтте Айтулды: «Аңладым моны,
Илбик игълан иткән бу сүзләр тугры:

Яхшыны якларга кирәк, дигәнең,
Файдалы эш эшлә күбрәк, дигәнең,

Милекне бар кеше теләр — арзулар[27],
Ләкин нинди була турырак юллар?»

ИЛБИКНЕҢ ҖАВАБЫ

Илбик әйтте: «Асыл нәрсә — яхшылык,
Асыллар һәр эштә яхшылык кылыр.

Асылларча төгәл башкар һәр эшне,
Шулай итү һәркем өчен килешле.

Исәрлек, яманлык — түбән гамәлләр,
Явызлык, ялганлык кылучы — исәр.

[24] Туа — тумыштан.
[25] Йот — даланы боз каплау хәле: йот вакытында, гадәттә, далада кипкән үлән ашап кышлый торган терлекләр күп үлә (хәзерге заманда терлекләрне дала халыклары да кырда кышлатмыйлар инде).
[26] Бәк — бийнең идарәче кардәш-ыруы, аристократия вәкиле.
[27] Арзу — кадерле теләк.

Очсыз булса әйбер, гел җирдә ятар,
Кыйммәтле нәрсәләр, бел, түрдә ятар.

Яхшылык мендерә өске сызыкка,
Явызлык төшерә абруйсызлыкка.

Моңа охшаш бар бер зирәк әйткән сүз
(Ошбу сүзне отсаң, файдасы хәтсез):

«Изгелек-биеклек, һәркем менәлмәс,
Чын изгелек юлын күпләр беләлмәс.
Чын изгелек кылу җиңел эш түгел:
Белексез игелек файда бирәлмәс».

АЙТУЛДЫ СОРАВЫ

Һәм Айтулды әйтте: «И, котлы Илбик,
Мактаулы авыр эш икән изгелек.

Монда буладыр еш ялгышлыкларың,
Шуны белим дисәң, байкап[28] буламы?»

ИЛБИКНЕҢ ҖАВАБЫ

Илбик әйтте: «Изге һәргиз[29] мактала,
Яманнарга үгет биргән чакта да.

Дусларыңа ярдәм итүең тиеш,
Әмма явызларга ярдәм — ялгыш эш.

Изгеләр басымчак булганга күрә,
Яманнар шәпләнеп көн күрсәтмиләр.

Игелек кылганга игелек килер,
Тик игелек кылу базар түгелдер.

Игелектән әҗер көтсәң бүген үк,
Бу — хата. Калырсың соңра үкенеп.

Бер изге теләктәш ни дигән, ишет:
«Игелек кылуны үзеңә иш ит.

Кем изгелек кылып, яманлык күрсә,
Үкенмәс барыбер чын изге кемсә».

Игелек кылу соң җиләтәмени[30]?
Бире кил, аңларсың — мин сөйләп бирим.

Зыян итмәс бүген — игелек кылсаң,
Иртәгә үк файда китерер, ышан.

Бүген сиңа уңыш насыйп булса да
Очынма, иртәгә килер бер каза.

Игелек — уңда ул, яманлык — сулда,
Тәмуг — шул тарафта, оҗмах — уң кулда.

Никадәр шәпләнсә бүген бер тинтәк,
Шулчаклы иртәгә ул үкенәчәк.

Ничек ялгышса да бер изге кеше,
Үкенмәс — иртәгә төзәлер эше.

Хакыйкать шулдыр ки, Айтулды, бел син:
Үкенеч юк, калса яхшы исемең.

Әйбәт әйткән бер ир шундый тугры сүз
(Шундый тугры сүзләр акылга нигез):

«Кем яманга каршы кылса яхшылык,
Ул — изге, кил, туган, аны алкышлыйк.

Әйтегез, кем сөймәс сезне, изгеләр!
Килегез, мин мохтаҗ сүзләрегезгә.

Изге кеше нинди сәер булмасын —
Аңар килә минем хезмәт кыласым».

Әгәр бийлек килсә явызлык аша,
Кирәкмәс бу бийлек, син аны ташла!

Кызыгы аз аның, үкенече зур,
Исәр бәндә генә шуңа кызыгыр.

Бу бапта бик әйбәт бер шагыйрь сүзе
(Һәм әгәр укысаң, ачылыр күзең):

«Изгелек кылгучы кайчан үкенгән?
Яманатлы бәндә ни шатлык күргән?

Яманлык азагы үкенеч булыр,
Яхшылар яманга да ярдәм кылыр».

Яманнарны ничек мактамак кирәк?
Исәрләрне ничек акламак кирәк?

[28] Байкау — төшенү.
[29] Һәргиз — һәр очракта.
[30] Җиләтү — туйдыру (берәр әйбер, ят күренеш турында).

Түбәнлек, кыргыйлык булыр һәрдаим
Исәрләрнең эше, и бәк-фидаин[31].

Бәла имгәк булып, соңын үкенеп
Елауларга, егет, калмасын көнең.

Ничек мактамассың изге кешене —
Ачылсын, дип, сиңа оҗмах ишеге.

Юмартлык, кешелек, ярдәм — изгелек
Яхшы кешеләрдән килә, билгеле.

Изге кеше барча изгенең ише,
Изге дус ул барча дус-иш изгесе.

Ишең изге булса, эшләр эшләнә,
Изге дус кирәк бер максат эстәсәң.

Куаныч-юаныч, канәгатьлекләр
Булыр изгеләргә мөкәфәт-бүләк.

Менә шул, Айтулды, сорауларыңа
Җавап, — диде илбик, — тик тыңла гына».

Җир үпте Айтулды һәм басты үрә,
Әйтте: «И, ыек бәк[32], и изге түрә!

Җиһан хакиме бул, озын гомердә
Изге бул, чир, кайгы күрмичә бер дә.

Аерылма бийлек[33] бөеклегеннән,
Ләззәтләнеп яшә сөенеч белән.

Олуг хөкемдар бул күп илләргә син,
Билегең[34] һәрдаим ныгып, җәйрәсен.

Теләк-арзуларың ташылып торсын,
Дәүләт капкалары ачылып торсын.

Сөенечләр өер-өер килсеннәр,
Дошманнар сагышта көеп үлсеннәр.

Табынсаң, белдекле хуҗага табын,
Белдеклеләр белә табугчы[35] хакын.

Югыйсә табынма. Табын, табынсаң,
Көмеш капкалы бер алтын өй булса.

Саранга табынма, табыныйм дисәң,
Гомереың зая булыр, ә башың — исәр.

Саран үзенә дә хәтта кызгана,
Бәс, ул бүтәннәргә ни бирә ала?»

Шулай дип Айтулды хушлашты, чыкты,
Өенә юнәлде. Йөзе шатлыклы.

Тайпылмый хезмәттә булды һәрчакта:
Төннәрен — ятакта, көндез — аякта.

Күрсәтте күндәмлек, эшен булдырды,
Бий аны көннән-көн якынлаштырды.

Шулай итеп шактый вакытлар узды,
Эшләп, йөзен якты кылды Айтулды.

ШУЛ БАПТА КИ СӨЙЛӘҮМЕ ЯКИ СҮЗСЕЗ ТОРУМЫ ЯХШЫРАК

Бермәл Айтулдыны чакыртты илбик
Һәм ымлап күрсәтте, шунда утыр, дип.

Айтулды утырды вәкарьле генә,
Күз тегеп бара ул, юл бирми телгә.

Илбик әйтте: «Әйдә, сөйлә, Айтулды.
Нигә тик торасың, сиңа ни булды?»

Айтулды әйтте: «И бәкләргә бәгем,
Хуҗасын күргәч, кол тота йөрәгем.

Хуҗа сүз әйтмәстән, нәрсә сөйләргә?
Әхвәлне белмичә, нәрсә сорарга?

Әнә ничек әйткән күп белекләләр:
«Сорамыйлар икән — телгә дә килмә».

Бар кеше берәүгә башлап сүз әйтсә,
Сөйләшү ялганып китә, гадәттә.

[31] Фидаин — үзен фида кылучы.
[32] Ыек бәк — борынгы титул — тәңредән җибәрелгән бәк, хөкемдар.
[33] Бийлек — бий булу вазифасы.
[34] Билек — кечкенә дәүләт яки идарәви өлкә, губерна.
[35] Табугчы — буйсынмыш, вассал.

Сорамастан элек сөйләнгәннәргә
Өлкәннәр бик белеп «хайван», дигәннәр.

Килделе-киттеле булса бер тиле,
Сорамастан бийгә ачадыр телен.

Кызыл тел кыскартыр яшәр яшеңне,
Исәнлек теләсәң, яшер сүзеңне.

Ишет, әнә, тыйнак, басынкы ирләр
Иминлекне уйлап, менә ни дигән:

«Кара башыңа яу кызыл тел булыр,
Башашар җен, кызыл аждаһа шулдыр.

Башын саклаучылар телләрен тыяр,
Телдәрләр, көт тә тор, башларын җуяр».

ИЛБИКНЕҢ СҮЗЕ

Илбик әйтте: «Әйе, сүзең аңладым,
Сүзең көмеш булса, дәшмәвең — алтын.

Ике төре була мокыт кешенең:
Берсе надан, берсе ачалмый телен.

Телсезләр телләрен йөрттерә белми,
Наданнарның теле тик тора белми.

Наданнарның теле торсын ул биктә,
Галимнәрнең теле йөрсен иректә.

Галимнәрнең теле — чүлдәге сулар,
Сугарырлар җирне, игеннәр уңар.

Белекле кешенең сүзе кыйммәтле,
Саф сулы чишмәнең суы кыйммәтле.

Белеклеләр алар гөлзар шикелле,
Һәр адымда чишмә чыгар шикелле.

Белексез кешенең күңеле чүл кебек —
Елга җибәрсәң дә, китәр ком күмеп».

АЙТУЛДЫНЫҢ СҮЗЕ

Тик Айтулды әйтте: «Беләсез, илбик,
Телгә тилчә тисә, китә тереклек.

Тере кеше ничек инде сөйләмәс?
Кирәк сүзне юньле кеше кизләмәс.

Сораган чакта һәр кеше сөйләсен,
Сорамаган чакта сүзен кизләсен.

Сорау бирү гүя иркәк[36] хакыдыр.
Тиешле җавапка инәк[37] хаклыдыр.

Бер иркәк-инәктән күп бала туар,
Бер сорау-җаваптан хәтсез сүз чыгар».

ИЛБИКНЕҢ СОРАВЫ

Әйтте илбик: «Әйе, сүзләрең дөрес,
Сүз артыннан чыга бер түгел, йөз сүз.

Бу тел зыяннарын ишеттем, белдем,
Тик бер дә файдасы юкмы җор телнең?

Тел афәтеннән бик курыксаң үзең,
Нигә әле бик күп сөйләнә сүзең?»

АЙТУЛДЫНЫҢ ҖАВАБЫ

«Күп, — диде Айтулды, — сүзнең файдасы.
Аны белмим хәтта ничек әйтәсе.

Хәерсез сүз чыга белексез телдән,
Белексез булганга, хайван син, диләр.

Урынсыз сүз әйтә җаһил, әлбәттә,
Егет башын ашый буш сүз, гадәттә.

Зыянлы-яман тел тора, ди, биксез,
Сөйли белсәң, ләкин файдасы чиксез.

Кара халык карны туйса, сыерча
Көйшәп, юк-бар сөйләп, тәнен симертә.

Ашый да йоклыйдыр, димәк бу — хайван,
Хайван диюем тик шуңа мисалдан.

Белекле кешеләр махсус ач тора —
Җан азыгын заһид булу арттыра.

Рухисызлык керсә, керә тамактан,
Җан азыгы исә керә колактан.

[36] Иркәк — ир җенесле зат.
[37] Инәк — хатын җенесле зат.

Белкәлек билгесе ике төрледер
(Шул икедән гөлдәй якты йөз килер):

Белкә телдә тыйнак, ашауда җыйнак.
Шуларның файдасы дәрьядан зуррак.

Белекле баш була тамакка, телгә,
Кеше шундый булса, димәк, ул — белкә».

ИЛБИКНЕҢ СОРАВЫ

Илбик әйтте: «Белдем сүзнең асылын,
Аның ничек нинди төсмер алуын.

Сүз каян чыгар һәм кая юнәлер?
Минә шуны миңа әйтеп бир әле.

Кайчан сөйләү кирәк һәм дә никадәр,
Галимнәр бу хакта нәрсә әйтәләр?»

АЙТУЛДЫНЫҢ ҖАВАБЫ

Айтулды: «Тирәндер, — диде, — сүз сере.
Сүзнең әйтеләдер тик уннан бере.

Әйтелмичә калган өлеше сүзнең
Бик еш кына була сассы[38], ямьсезе».

ИЛБИКНЕҢ СОРАВЫ

Өстәп әйтте илбик: «Сүзнең файдасы
Вә зарары нинди, әйтеп карачы?»

АЙТУЛДЫ ҖАВАБЫНЫҢ ДӘВАМЫ

Һәм Айтулды әйтте: «Сүз күптер, әгәр
Сорамыйча сөйләп җанга тисәләр.

Сүз аз була, әгәр соралган кемсә
Һәрбер сорауга бер сүз җавап бирсә.

Бу бапта бер шагыйрь әйткән шул сүзен
(Бу сүзе илә ул ак иткән йөзен):

«Әйтереңне җиде тапкыр уйла син,
Тик әйтә башлагач, артык сузма син.

Күп тыңла, аз сөйлә, дигән бабайлар,
Акыл белән уйлап сүзеңне сайла».

ИЛБИКНЕҢ СОРАВЫ

«Риза, — диде илбик, — ошбу сүзләргә
Тагы бер сүзем бар, син әйт, гизләмә[39].

Кемеңнән ишетү кирәк сүз чынын?
Һәм кемгә әйтергә? Аңлат син шуны».

АЙТУЛДЫНЫҢ ҖАВАБЫ

Һәм Айтулды әйтте: «Сүзне белкәдән
Ишетеп әйт шуңа, кайсы ки надан.

Олыдан ишетеп кирәкле сүзне
Кечегә әйтеп бир, тыңласа үзе.

«Тыңла күмәртәләп[40], берәмләп сөйлә» —
Белекле бөкәләр[41] менә ни диләр.

Күп сөйләп акылдар булмастыр кеше,
Күп тыңлаган булыр белкә, ил башы.

Биллур[42] булсын инсан-нурлар тупласын,
Буш сүзгә мавыгып йөрер булмасын».

ИЛБИКНЕҢ СОРАВЫ

Янә әйтте илбик: «Бу аңлашылды,
Тагы бер сорау — аңлат ансын да.

Кайчан, кайда телне тыеп сөйләргә?
Серне кайчан ачып, кайчан гизләргә?»

АЙТУЛДЫНЫҢ ҖАВАБЫ

Һәм Айтулды әйтте: «Тыңлачы, Илбик,
Бер дә сөйләмәсәң — беленмәс белек.

Сүгеп булмый сүзне — файдасы хәтсез,
Тик бер сүз — акыллы, ә бер сүз — мәнсез.

[38] Сассы — начар исле.
[39] Гизләмә — яшермә.
[40] Күмәртә — күпләп, өемләп (мәгънәдәш сүзе — «запас», «күмү» тамырыннан).
[41] Бөкә — мәҗүси батыр, юлбашчы.
[42] Биллур — бериллий. Бериллийле кайбер минераллар көндез нур туплап, төнлә шактый вакыт якты, нурлы булып торалар.

Бу сансыз-санаксыз төрле халыкка,
Ходайның барлыгын тик тел таныта.

Түрәткәчтен тәңре — халык мең төмән[43]*,*
Алар ихлас мактый хакны тел белән.

Җанлы тәндә ике иң кирәклесе:
Берсе — күңле, берсе — телдәге сүзе.

Күңел яралтылган ихлас сүз өчен,
Сүзең кыек икән — юк рухи көчең.

Сүзең тугры булса, файдасы шиксез,
Кырын-кыек сүз ул — сугүгә тиң сүз.

Сүзең тугры булса, эшләт телеңне,
Уең кыек булса, тешлә телеңне.

Әгәр сөйләмәсәң, чукрак диярләр,
Әгәр күп сөйләсәң, яңшак[44] диярләр.

Кешенең яманы — яңшак, такылдык,
Кешенең яхшысы — юмарт, акыллы.

Бу сүзләрдән Илбик шатлыкта булды,
Күзен күккә тегеп, бер дога кылды.

Ходайга шөкер, дип мактады һаман:
«И иям, син газиз, син — чын миһербан.

Миңа син исәпсез изгелек кылдың,
Мин — сиңа бурычлы, языклы колмын.

Теләгәннәремне бирдең барын да,
Рәхәт-ләззәтен дә, дөнья малын да.

Шөкеремне тагын ничек белдерим?
Җаныма кер үзең, шунда бел инде».

Сүзен кисте, дәүләт казнасын ачты,
Ярлыларга хәер өләште-чәчте[45].

Айтулдыны исә нык хөрмәтләде,
Кулдан бүләкләде, телдән мактады.

Вәзирлек тамгасын[46], тәгәчен[47], тагын
Тугын[48], барабанын бирде, куягын[49].

Кулын озын[50] кылды күрше илләргә,
Дошман мәҗбүр булды артка чигәргә.

Һәм Айтулды барча эшкә баш булды,
Үзе эше — язмышы өчен шат булды.

Халык баеп, һәммә җирдә гөл бетеп,
Илбигенә дога кылды ил-көне.

Халык мохтаҗлыктан, яудан котылды,
Кузый, бүре, бергә йөреп, дус булды.

Төзекләнде ил һәм төзелде заңнар[51],
Илбикнең дәүләте күмелде данга.

Шулай ил беркадәр тапты бәхетен,
Төзелде ил-халык, барчасы бөтен.

Гөрләде һәр җирдә яңа калалар,
Алтын-көмеш арта торды казнада.

Сөенде канәгать хөкемдар үзе,
Җиһанга җәелде даны һәм сүзе.

Дәвамы алдагы саннарда

Филология фәннәре докторы, профессор
Рифкать Әхмәтҗановның
шигъри тәрҗемәсе ■

[43] Мең төмән — миллионнарча (төмән — ун мең).
[44] Яңшак (татар сөйләшләрендә дә кулланыла) — лыгырдык һәм сукранучан.
[45] «Чәчү» сүзенең борынгы (төп) мәгънәсе — хәер-садака, корбанлык бирү.
[46] Тамга — биредә пичәт, мөһер.
[47] Тәгәч — махсус савыт, кружка.
[48] Туг — байрак, әләм.
[49] Куяк — тиредән эшләнгән шайман (броняле өске кием) — парад формасы. Күренгәнчә, борынгы төрки вәзирләренең таныклык билгеләре — пичәте, тәгәче, әләме, куягы булган.
[50] Кулы озын — хакимиятле, ихтыярлы.
[51] Заң — төгәл закон; мораль, әдәп; «заң» сүзе татар мәкальләрендә дә очрый.

ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ,
ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ

РАЗИЛ ВӘЛИЕВ

(04.01.1947)

...Әйе, минем көчле рухымнан
җир вә күкләр калтырар.
Һ.Такташ

***

Елый-елый, сугыша-сугыша җирдә,
Акыл күпме җавап эзләгән...
Я дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Я булмаса үзем үзгәрәм.

Аңламыйлар, җилне зәңгәр дисәң,
Тормышыбыз — Сабантуй дисәң.
Һәрнәрсәгә минем үз атамам:
Айны кояш диям, теләсәм.

Чәчәкләргә үз исемем бирәм,
Мең терелә́м көнгә, мең үләм.
...Үлем белән якалашканда да,
Акны кара диеп сөйләмәм.

Дуслар юкта чын дуслыкны мактыйм...
Бу дөньяда яшәү — мең рәхәт!
Адашыпмы, кайчак килеп чыга
Безнең йөрәккә дә мәхәббәт.

Кайчак ялгыш уңны, сулны бутыйм,
Булгалый ла инде, булгалый...
Кешеләрдән гел яхшылык телим,
Мин хыялый бугай, хыялый.

Хаксызлыкны күреп ярсыйм, шашам,
Матурлыкны күреп тезләнәм.
Я дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Я булмаса
Үзем үзгәрәм.

* Шагыйрь Разил Вәлиевнең кайбер сүз энҗеләре белән журналның башка битләрендә танышa алаcыз.

ЧИШМӘ БАШЫ

ЛЕНА ГАЙНАНОВА,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре,
Гаяз Исхакый исемендәге премия лауреаты

«ХӘЗЕР ЯЗГАНЫҢНЫ УКЫП ТА БИР ИНДЕ, СЕҢЛЕМ», — ДИ АПА. ШӘМСЕНИСА, ӘЛЕ ГЕНӘ ҮЗЕ ЯЗЫП ТӘМАМЛАГАН ХАТНЫ КУЛЫНА АЛЫП, КЫЧКЫРЫП УКЫЙ БАШЛЫЙ. БИК ИШЛЕ ГАИЛӘ ӘГЪЗАЛАРЫННАН, БӨТЕН КҮРШЕ-КУЛӘННӘН АЕРЫМ-АЕРЫМ ЧУКТИН-ЧУК СӘЛАМНӘР КҮНДЕРГӘННӘН СОҢ, ЙОРТТАГЫ ХӘЛЛӘР, АВЫЛДАГЫ ВАКЫЙГАЛАР ТЕЗЕЛЕП КИТКӘН ИДЕ ХАТТА. СОҢГЫ БИТТӘ САГЫНЫП САРГАЮ, ӨЗЕЛЕП КӨТҮ, ЯРАТУ ТУРЫНДА ҖЫРЛАР ДА БАР ИДЕ.

Җыр чыгару Шәмсенисага әллә ни авыр түгел. Ул үзе җыр чыгарам дип тә уйламый, ничектер шулай, каршысында утырган йөзе сагышлы апаның инде дистә еллар патша хезмәтендә, солдатта йөргән ирен сагынып сулкылдавы була, кызның күңел кыллары нечкәреп китә, бәхетсез хатынның моңнары җыр булып кәгазьгә агыла башлый.

Шәмсениса хатны укып бетергәндә, апа тыела алмый елый иде инде. Бераздан соң ул, кызга карап:

— Гаеп итмә инде, сеңлем, елый дип. Минем эчемдәге бөтен хәсрәтемне җыр итеп язгансың бит. Яшь кенә бит әле син. Барысын да каян бу кадәр беләсең соң? Иргә чыгып, ирдән калып, нужа күрергә өлгермәгәнсең бит.

Шулчагында мич буенда җеп эрләп утырган хуҗа хатын сүзгә кушыла:

— И-и, ахирәт, нужаның аның бүтән төрлесе дә була шул. Хәдичә түти җизнидән дүрт бала белән торып калды бит. Өч кыз, бер малай. Нужаның әчесен нык татыдылар инде алар. Әнә Шәмсениса да, апалары да кече яшьтән кешегә хат язып, хат укып тамак туйдырдылар. Инде бер кыз кияүдә. Хәсән абыйлары өйләнгән. Хәдичә түти янында Акбикә дә төпчек кыз Шәмсениса торып калды. Шәмсениса кызым, безнең авылга утырмага килгән саен, бөтен авыл халкының язу-сызу йомышларын үтәп йөри бит.

— Әйе шул, әйе шул, — ди апа, ашыгып. — Аллаһы Тәгалә сиңа бәхет бирсен, сеңлем. Яраткан кешеңә чыгып, рәхәт гомер итәргә язсын!

— Амин! — ди Шәмсениса, көлеп.

Кызга иртәгә Сыркыдыга кайтып китәргә кирәк. Әнисе хәбәр җибәргән: «Кайтсын, үзен бик сагындым!» — дигән. Нәрсә булды икән? Бүтән елларда Шәмсениса, утырмага килеп, икешәр ай да тора торган иде. Бу юлы әнисе аны бер айдан кире өйгә чакыра.

Иртән иртүк юл чыгасы дип,

иртәрәк ятарга булдылар. Хуҗалар инде күптән йоклый. Ә кыз, күңеленә тынгы таба алмыйча, йоклый алмыйча ята... «Әни нигә чакыртты икән? Өйдә әллә берәр күңелсезлек бар микән?» Аннары кызның уйлары бүгенге вакыйгаларга, Шәмсениса язган хатны бик кадерле нәрсә шикелле күкрәгенә кысып басып торган апага барып тоташты. Хатынның: «Яраткан кешең белән гомер ит!» — дигән сүзләре кабат исенә төшеп, кыз елмаеп куйды. Яратмаган кешегә кияүгә чыгалар диме соң? Бары тик яратканга гына!

Хәдичә түти кызын бик җылы каршылады. Аркасыннан сөйде, әйбәтләп сыйлады. Аннары өйгә чакыртуының сәбәбен сөйләде. Шәмсениса югында ул аны күрше Сәдрү малае Сафага ярәшкән икән. Калым итеп акчасын да алган. Туй көне дә билгеләнгән. Кызның кайтуын дүрт күз белән көтеп торганнар.

Сәдрү күрше эшне бик кызу тоткан. Бу үткен, уңган кыз Сафаны бик өнәп бетерми бугай. Шуңа күрә аны, уйлап торырга вакыт калдырмыйча, тиз генә эләктерергә кирәк. Шул исәптән чыгып, Сәдрү фәкыйрьлек белән тормыш иткән Хәдичә түтигә калымын да тоттырып куйган, туй көнен дә ашыктырган.

Шәмсениса, ышаныргамы-ышанмаскамы дигәндәй, әнисенә карап катып калган иде.

— Йә, кызым, сүзеңне әйт. Ризадыр бит? Сәдрү — бай кеше. Ятимлектә үстең. Хет кияүдә рәхәт яшәрсең, — ди Хәдичә түти, өзеп-өзеп.

— Әни, акчаны Сәдрү абзыйга кире кертеп бир, мин Сафага чыкмыйм!

— И Алла! Кызым, акчаны тотып бетергән идем шул, бурычыбыз бар иде бит, шуны түләдем. Чык Сафага, кызым, карышма, үзеңә дә, безгә дә яхшырак булыр. Үзеңне күптән яратып йөриләр бит...

– Чыкмыйм!

Хәдичә апа, бер карарга килеп:

— Сиңа шуннан да яхшырак кияүне каян табыйм мин? Чыгарсың! Кире уйлау юк! — диде.

Кыз әнисенең холкын белә иде. «Һе, көчләп кияүгә бирмәкче! Үзе мине бәхетле итәм дип уйлый инде... Нишләргә?..»

Бер сәгатьтән бөтен нәрсә хәл ителгән иде инде. Сыркыдыга Урта Азиядән кунакка кайткан бер хатынга ияреп, иртәгә иртүк авылдан чыгып качарга!

...Ат тотып баручы малайга юлчылар үзләрен якындагы Торбеево станциясенә түгел, юлны саташтыру өчен, аннан еррак урнашкан станциягә алып барырга кушалар. Поездга кереп утырулары була, тәрәзәдән атларын станциягә таба җан-фәрманга чаптырып килүче Сәдрү белән Сафаны күреп алалар.

Менә Сәдрү абзый ашыгып вагонга килеп керә, аның артыннан Сафа. Шәмсенисаны ике кулыннан тартып, кычкыртып, вагон ишегенә кадәр алып баралар, урамга өстери башлыйлар. Өзгәләнеп елаган кыз баланы, аны ишектән чыгарырга маташкан ирләрне күреп, кемдер берәү (Шәмсениса аны урядник дип хәтерләп калган):

— Прекратите безобразие! — дип кычкыра.

Сәдрү әлеге кешегә хәлне аңлата башлый:

— Бу кыз улымның кәләше, бүген никах буласы, ә ул өйдән чыгып качкан. Мусульманский бог, так делать — грех, говорит.

— Ә кыз бу егеткә кияүгә чыгарга ризамы? — ди теге кеше.

— Юк, юк, риза түгел, теләмим! — дип кычкыра Шәмсениса.

— Кыз риза түгел икән, сезнең аны көчләргә хакыгыз юк!

Шуның белән кәнитил дә тәмам була. Шәмсениса Урта Азиягә китеп бара.

Ул заманда авыл җирендә кыз баланың мондый тәвәккәллеге һәркемне шаккатыра. Сыркыдыда бу вакыйгага уңае белән кемдер бәет тә чыгара.

Сәдрү агай, талларыңа
Асыл кошлар кунмыйдыр.
Син теләгән Фәхри кызы
Сиңа килен булмыйдыр, —
дип, урамнан җырлап та үткәлиләр.

Һ.Такташның әнисе Шәмсениса, әтисе Хәйрулла

Һ.Такташ туып-үскән йорт. 1964 елгы фоторәсем

Китәрмен илегездән,
Тынармын сүзегездән,
Очып барган аккош төсле
Су эчмәм күлегездән.

Сыркыды халкы, бу җырны авылдан качып китәр алдыннан Шәмсениса чыгарган, дип, озак вакытлар көйгә салып җырлап йөри.

Хәдичә түти кыз өчен дип алган калым акчасын Сәдрүгә түли алмый. Шул хакта озак вакыт ызгышлар бара. Калым акчасын Хәдичәнең Урта Азиядә яши торган кияве, Шәмсенисаның бертуган апасы Зөһрәнең ире Фазлетдин Арсланов түли...

Һади Такташның бертуган сеңелесе Хәнифә апа шушы кыйссаны сөйли иде дә әниләре Шәмсениса апаның үтенечен искә төшерә иде: «Берүк, балалар, минем баштан үткән бу вакыйганы кешегә сөйләмәгез!» Хәнифә апа үзе бу хәлләрне кешеләр белүгә каршы

Һ.Такташ су кереп йөргән Парча елгасы

Сыркыды авылы зираты капкасы

түгел: «Әнине кимсетә торган нәрсә юк бит монда, язарга теләсәң, яз», — дип, миңа боларны матбугатта чыгарырга рөхсәтен әйтеп куя иде…

Шәмсениса апа, Урта Азиядән кайткач, үзенең яраткан кешесенә — Хәйруллага кияүгә чыга. Хәйрулла 25 елга патша хезмәтенә алынган була. Дүрт елдан соң, ашказаны авыруы сәбәпле, өенә кайтарыла. Хәйрулланың беренче хатыны баладан үлә. Егет Шәмсениса белән бертуган Хәсәннең якын дусты була. Ул Хәсән янына еш килеп йөри. Шәмсенисаны ошата. Ләкин бу чая, уңган, җырга-телгә оста кызның үзендә күңеле барлыгын белгәч кенә, башкода җибәрергә батырчылык итә.

Хәлчә туй итәләр. Шәмсениса ике дистәдән артык туган-тумача яшәгән йортка өченче килендәш булып килә.

Такташевлар гаиләсендә 9 бала туа. Шуларның алтысы — Фатыйма, Ха-

физ, Һади, Габидулла, Хәнифә, Мәрзия — исән-сау үсеп җитәләр. Һади гаиләдә өченче бала булып дөньяга килә.

Гомеренең соңгы елларында Шәмсениса апа фаҗигагә тарый — аяклары авыртып, йөри алмас хәлгә килә, җиде ел урын өстендә ята. Һади Такташ аны Казанга алып килеп, «Иске клиника» хастаханәсендәге врачларга да күрсәтеп карый, файда булмый. Сыркыдыда ананы иң кече кызлары Мәрзия тәрбияли.

Бу вакытта өч бала — Һади, Габидулла, Хәнифә — Казанда яшиләр. Ана аларга чиксез мәхәббәт тулы хатлар язып тора. Кулымда Шәмсениса апаның сакланып калган бер хаты: *«...Габидулла җаным, балам! 30 нчы числода буш көн (сишәмбе) дөшемдә күрдем үзеңне. Зинһар, хат яз. Хәлең ярыймы? Юк өчен кайгырынма, зинһар, кайгырма. Үзеңә саулык, тәүфыйк теләп торам. Каршы хат яз, барын да. Мине хәсрәт илә томма. Һади, җанкисәгем, син дөшемә иңмәйсең, тегел көн дә күрергә. Зинһар, бер-береңезне якын итеп, күрешеп торыңыз, ташлашмаңыз. Минем хәсрәтем сез генә. Җаным, Хәнифә, син үгә киләсең, җан-тән илә эшлисең дә, китәсең дә, бер-ике юл хатыңызга да мохтаҗ кыйласың. Җаннарым, минем выт бөтен шатлыгым сездән хәбәр алу. Җанкисәкләрем, балаларым, мин сезне уйлап көн-төн үткәрәм. Ни ашый торганнардыр дип, ничек торалар дип... Һади балам, Рафушны анасы кая алып китте, беленәме? Балам, җаным, кайгырма. Син аңардан файда күрергә булса, дөнья читенә алып китсә дә, күрерсең. Файдасыз булса, кулыңда асрап та, эчеңне пошырыр... Ай булды, Хафиздан хәбәр алганым юк. Сәламәтме икән? Хәсрәт илә торамын... Хәнифә, быел чусинкәләр бастырырга теләгән идегез... Безнең йонны сәвит алды. Үз йоннарыннан кырык сум сорыйлар, анарга хәл алмый, аякларыңыз өшер, нишләрсез. Һади балама 1-2 шигырь язам, Хәнифә яратмаса да.*

Өшим, балам, өшим инде,
адиал ябынсам да,
Дөшләремә дә иңмәйсез никадәр
сагынсам да.
Өстеңдәге күлмәгеңнең
изүләрен кем уйган.
Адәм тегел, коштан да юк
туган иленнән туйган».

Кечкенә буйлы почтальон Кармай Такташевлар өенә җылы җавап хатларын еш китерә.

1931 елның 8 декабрь төнендә Хәйрулла абзый йортына кара хәбәр китерәләр — Һади үлгән. Тормыш мәшәкатьләренә, олыгаюына бирешмәскә тырышып яшәгән Хәйрулла абзый берьюлы бөрешеп, хәлсезләнеп кала. Шәмсениса апаның да хәле начарая, урыныннан бөтенләй тормас була. Ачыргаланып, өзгәләнеп елаган күңеленнән шигырь агыла:

Кай җирләрдә, балам, синең каберең?
Каен бармы каберең янында?
Рәсмең тора менә күз алдымда,
Үзең юк шул, балам, янымда.
Син утырткан ятим каеннарга

Күз яшьләрдән сулар сибәмен,
Таң алдында каен яфракларын
Җылы йөзең итеп үбәмен.
Таң җилләре, каен башын сыйпап,
Әкрен-әкрен итеп исәләр,
Син үлгәчтен никтер шиңмәделәр,
Каеннарың һаман үсәләр.
Каеннарга сөйлим моңнарымны.
Аңлаган күк тып-тын торалар,
Синең кулың итеп ботакларын
Гүя миңа сузган булалар.
Җәйләр җитте инде, ул каеннар
Яшел яфракларга төренде,
Алар кайгы белми, мәңге шатлар,
Тик әниең шашты, сөренде.
Таң җилләре, каен башын сыйпап,
Әкрен генә һаман исәрме?
Син үлгәчтен шаулап үскән каен
Мин үлгәчтен шулай үсәрме?..

Шәмсениса апа өйдәгеләргә дә, хәл белеп керүчеләргә дә Һадиның балачакларын, шаянлыкларын сөйли. Менә Һадиның 5-6 яшьлек чагы. Башка малайлар белән бергә, Хәсәннәр бакчасына кереп, кыярларын тунап чыкканнар. Зуррак балалар йөгереп качалар. Хәсән абзый Һадины эләктереп ала. Бер кулы белән колагыннан тотып, икенчесе белән балага суккалый, кычкырып тирги. Тавышны ишетеп, Шәмсениса апа урамга йөгереп чыга: «Хәсән абзый, ни өчен кыйныйсың?» — ди. «Әнә үзе әйтсен», — дип, Хәсән абзый өенә таба китеп бара. «Улым, ник еламыйсың, ичмасам, еласаң, кыйнаудан туктар иде», — ди әнисе. «Еласам, малайлар ишетерләр дә аннары мине беркайчан да разбуйникка алмаслар», — дип җавап бирә Һади. Әнисе «разбуйникның» корсагына кысып тоткан күлмәк итәген ачып карый. «И балам, бу нәни генә кыярларны ничек җәлләми өздең соң, борыннарыннан чәчәкләре дә төшмәгән бит әле!» Шулчагында Һади, малайлар ишетү ихтималын да онытып, кычкырып елап җибәрә. «Хәзер нәрсәгә елыйсың инде?» — дип сорый әнисе. «Бик нәниләр бит әле-е-е, хәзер үсәлмиләр бит инде-е-е», — дип такмаклый Һади.

Тагын шулай бервакытны Шәмсениса апа Һадины арыш көлтәсе өешергә алып бара. Көн бик эссе. Эш тә җиңел түгел. Менә чүмәлә өстенә менеп баскан Һади: «Әни, безнең өй турысында төтен күренә, пожар түгел микән?» — ди. Әнисе хәйләне сизә, ләкин: «Улым, булмаса, бар, өйгә кайт, пожар булса, килеп әйтерсең, булмаса, килеп тормассың», — ди. Һади, чүмәләдән төшеп, авылга таба йөгерә. Ләкин түзеп күп бара алмый, юлдан борылып, Парча елгасына су керергә чаба. Әнисе улының йомгак шикелле генә гәүдәсенә кызганып карап: «Көнозын су буенда уйнап кына йөрергә иде дә бит, балам», — дип уйлый.



Һ.Такташ әнисе Шәмсенисаның Казанга балаларына язган хаты

Көне-төне колхоз эшендә һәм авыру әнисе янында кайгыртып йөргән Мәрзия һәм авылга кайткан арада башка балалары да Шәмсениса апа чыгарган шигырьләрне язып алгалыйлар. Мәсәлән, ул хәл белергә кергән күршеләренә:

Кыйблалардан килгән кара болыт,
Шул коядыр илләрнең тарысын.
Хәлең ничек, диеп ник сорыйсыз,
Күрмисезме йөземнең сарысын? —

дип җавап бирә. Һадины юксынып, үзенең йөри алмавына әрнеп:

Җир җиләге чыга җир ярып,
Яфраклары кала җир ябып.
Кай җирләрдә, балам,
синең кабереӊ?
Ничек кенә күрием бер барып, — дигән сүзләрне көйгә салып җырлый.

Урында ятканда, Шәмсениса апа бик нәфис бизәкләр белән караватяпмасы бәйләгән. Кызы Хәнифә апа аны гомер буе саклаган. Үләр елында Хәнифә апа аны миңа бирде. Шулай ук әниләре Казанда «Иске клиника»да яткан чакта: «Һадием абажурына ябар», — дип, ике кечкенә япма да бәйләгән. Әнисе алдында Һади аны язу өстәлендәге лампасына каплап торган. «Әни, бу япмалар синең кулларыңны хәтерләтерләр, миңа шигырь язарга илһам бирерләр», — дигән. Ул япмаларны да, кайчан һәм кем бәйләгәне турында язылган язуы белән бергә, Хәнифә апа миңа тапшырды. Бу әйберләр Такташның киләчәктә төзеләчәк музеенда кадерле экспонатлар булачак.

Хәнифә апа Такташева болай сөйли иде: «Әни белән Һади абый төскә дә охшашлар, күңелләре-хисләре белән дә бердәйләр иде. Әти Һади абыйны укытучы итәсе килде, ә әни аның шагыйрьлеген хуп күрде.

Әти дә, әни дә бик зирәк, заманына күрә укымышлы кешеләр иде. Үзара бик яратышып тордылар. Әни үлгәндә, әтине җирдән күтәреп алганнар, шулкадәр хәсрәтләнгән. Әти бик сөйкемле кеше иде. Сакал-мыекны купшы йөртергә, ыспай киенергә ярата иде. Ул беребезгә-бер каты сүз әйтмәде. Ә авыл халкы арасында үткен сүзле, курыкмас туры әйтә торган бер кеше иде». Шәмсениса апа да кирәк урында җавабын әйтә белгән, тел яшермәгән. Илдар Мостафин әнисе Мәрзиянең сөйләгәнен хәтерли: «Шәмсениса юл буенда урак ура икән. Юлдан бик шәп атта кирелеге, тупаслыгы белән танылган барыня үтеп бара. Уракчылар янына җиткәч, бу: «Бог не в помощь!» — дип кычкыра. Шәмсениса да аңа үзе кебек җавап бирә: «Не спасибо!» — ди».

Хәнифә Такташева, техникумнан куылган 1928 ел

Такташевларны дошман күрүчеләр дә булган авылда. Авыл советына кереп оялаган көнчеләр Хәйрулла абзыйларны сайлау хокукыннан мәхрүм итәләр, балалары укыган җирләргә «алар кулак балалары», дип донослар язып, укудан чыгартуга ирешәләр. Бу хәлләрне Һади Такташ газетага язып чыга, төрле оешмаларга мөрәҗәгать итеп, гаеплеләрне фаш иттерә, дөреслекне кайтарта. Шагыйрь үлгәч тә, гаиләне тынычлыкта калдырмыйлар. Төрле уйдырмалар белән нигезләп, Такташевларны колхоздан чыгаралар. Дөреслек инде уллары, югары белемле агроном Хафиз һәм укы-

Һ.Такташның әтисе Хәйрулла Таһир Такташев гаиләсе белән. 1937 ел

Һ.Такташның сеңлесе Хәнифә һәм апасы Фатыйманың улы Әхәт шагыйрьнең кабере янында

тучы Габидулла, Һади Такташның беренче хатыны юрист Гөлчирә Хәмзина ярдәме белән торгызыла.

Хәсрәтле көннәрнең берендә, кичен, авыл советыннан дежурный килеп: «Сезгә анда кәгазь килгән, иртәгә килеп алыгыз», — дип әйтеп китә. Ата белән ана: «Һадиның үлемен дә төнлә хәбәр иткәннәр иде бит», — дип, төнне кара кайгыда үткәрәләр. Хәйрулла абзый иртән авыл советына барса ... зур гына сумма акча тоттырып кайтаралар. Һади Такташның беренче хатыны Гөлчирә Хәмзина, Һади үлгәч, уллары Рафаилга тиешле пенсия акчасын, юллап, картлар исеменә күчергән икән. Кулымда Г.Хәмзинаның шул вакыйгадан алда гына Казанга Габидуллага язган хаты. *«...Абидулла, минем хәзерге экономик хәлем шактый ук әйбәт бит. Мин katerле Һади ярдәме белән университет тәмамлаган кеше буларак, аның улына тиешле тәрбияне бирә алырмын, дип уйлыйм. Мин Һадиның картайган ата-анасын күздә тотам. Рафикка зур расходлар кирәк булганга кадәр, аңа тиешлесен картларга биреп, әз булса да аларга ярдәм итү — минем ихлас теләгем һәм мораль бурычым».*

Хәнифә апаның әйтүенчә, картларга берничә ел дәвамында Гөлчирә Хәмзина күчергән пенсия һәм әдәби гонорар акчалары килеп тора.

Шәмсенисаның бертуган апасы — Зөһрәнең кызы Нәгыймә апа Арсланова Һади әнисенең бик ягымлы кеше булуы, сүзләрне гел бизәкләп әйтүе турында сөйли: «Мәсәлән, мин аларга кунарга килә идем. Зур әни (Шәмсениса апа) алдыма аш кую белән генә чикләнми: «Аша әйбәтләп, Нәгыймә, бездә кояш соңрак чыга, кояш сезнең очтан чыга бит, безгә килеп җиткәнче озак гомер үтә, ачыгырсың», — ди иде».

Такташевларның Мәскәүдә яши торган олы кызлары Фатыйма апа җәен Сыркыдыга балалары белән кайтып яши. Фатыйма апаның улы Әхәт Богатов авылга кайтып йөрүләрен хәтерли: «Әби ятып кына тора, берәмберәм янына киләбез, ул бераз калкынып, безнең башларыбыздан сыйпый, аркадан сөя. Ә бабай безне Торбеево станциясеннән үк ат белән барып ала иде. Юлда карыныгыз ачар, дип, станциядәге чәйханәгә алып кереп, чәй, булка белән сыйлый. Аның гел мәшәкатьле, киеренке хәлдә булуын хәтерлим. Шулай да безнең белән шаярып, уйнап та ала иде. Сеңлем Сәйдәне кулына ала да сарыкларны саната: «Бер ак куй, бер кара куй, бер ак куй, бер кара куй...» Шуннан үзенең бик күңеле булып көлә иде. Безгә йомышмазар кушкан булып, «булдыклылыгыбызны» мактый иде. Кичен йортка малларны кертергә, капкалар ябарга булышканда, бик оста итеп мактый. Шуннан соң тагын берәр йомыш кушсын иде, дип йөрисең.

Тавык оясына менеп, күкәй алам да күрше малайга бирәм, ул миңа алма бирә. Бабай күрмәмешкә салыша иде. Кирәк-яракка дип сораганда, бабайга бик арык, начар ат бирәләр иде, әллә атларның барысы да шундый булдымы инде. Малайлар белән атны конюхка тапшырырга барабыз, ә конюх безне сүгә, атны камыттан суктырткансыз, бабагыз килсен, ди. Бабай аның янына барып, нидер сөйләшеп кайта иде. Бабайның бер яраткан сүзен хәтерлим: «Э, пыста» (пусто, буш нәрсә).

1936 елда, алтмыш өченче яшендә Шәмсениса апа үлгәч, Хәйрулла абзый Мәскәүдәге, Казандагы балаларында бераз торып ала да Ташкент янындагы Кибрай-Олугбәк бистәсенә олы улы Хафиз янына китә. 1943 елның ноябрендә җитмеш тугыз яшендә шунда дөнья куя.

Алдымда Хафизның хатыны Мөршидә апаның кырык өченче елда Мәрзия апага язган хаты. Авыру тарихы, әйткән сүзләре, ничек үлүе турында тәфсилләнгән. Каенатасына карата иң җылы, мәрхәмәтле хисләр белән тулган хат. Хафиз абыйның да, үзенең һәм балаларның да бу югалтуга күнегә алмаулары турында әрнеп язган. Кы-

рыгынчы елларда Һади Такташның һәм Гөлчирә Хәмзинаның улы Рафаил Такташев (рәссам, сәнгать фәннәре докторы) әнисе белән бергә Фирганәгә барышлый Кибрай-Олугбәктә тукталалар, Рафаил абый карандаш белән бабасының рәсемен ясый. Ул бабасын шат күңелле кыяфәттә күргүен хәтерли.

Шулардан чыгып, Хәйрулла абзый картлык елларын яхшы тәрбиядә уздырган, дигән нәтиҗә ясарга мөмкин.

Такташ әсәрләрен (өч томлыкны) матбугатка әзерләгәндә, язучының шәхси тормышына караган һәм туган-тумачалары турында материалларның аз булуы күзгә ташлана иде. Шагыйрьнең туганнарын, якыннарын эзләүне максат итеп куйган идем.

Менә шул максаттан чыгып, Такташның Мәскәүдәге туганнарына бардым. Мәрзия апаның улы, Илдар Мостафин фатирында фоторәсемнәр карап утырабыз. Бер рәсемне кулына алып, Илдар: «Бу минем әбием», — диде. «Кайсы әбиегез?» «Минем әни Мәрзия белән Һади абыйның әниләре», — ди Илдар. Булмас! Шәмсениса апа беркайчан да рәсемгә төшмәгән дип санала иде. Хәнифә апа да шулай ди иде. Элекке Татарстан берләштерелгән дәүләт музеенда (хәзер Милли музей) Такташ әнисенең телдән әйтеп ясалган зур рәсеме бар иде. Дөрес, музейдагы бу портрет Хәнифә апаның портреты сыман. «Ул бит сезнең портрет», — дип, мин Хәнифә апага әйткәнем дә бар иде. Ә бу минем кулымдагы рәсемдә бөтенләй башка кеше. Дөрес, Такташ чалымнары бусында күбрәк. Ләкин ничек ышанырга? Илдарның бу әбисен күргәне юк бит. Кемнән раслатырга? Такташның бертуганнары дөньяда юк инде. Бердәнбер өметем — туксан яшен тутырган Таһир абый. Таһир абый белән Һади Такташның әтиләре бертуган.

Телефонны Таһир абыйның хатыны Нәгыймә апа алды. Килергә рөхсәт сорыйм. «Бүген соң бит инде, юлда куркырсың, иртәгә килерсең», — ди. Иртәгә? Юк, юк, бүген! Таһир абый олыгайган кеше, бер төн эчендә ни булмас!

Метро поездының озак, өстерәлеп кенә баруына шаккаттым. Элек мин метрода йөрүнең тизлеген ничек мактаганмын икән?

Ишек ачылуга ук, какча гәүдәле, пөхтә картны күреп алдым. Исәнләшү әдәбен ашык-пошык үтәп, бабай алдына Илдардан алган рәсемне куйдым. «Таһир абый, таныйсызмы бу кешене?» Җавапны ишетми калырмын дип, тын алудан туктадым. «Шәмсениса тәтәй, син бит бу! Йа Алла!» — картларча өзек-өзек тавыш белән Таһир абый шулай диде. Киеренкелектән кинәт бушанып, хәл бетеп, урындыкка утырдым. Көтелмәгән табыш иде бу!

Илдарның әйтүе буенча, бу рәсем аларда соңгы ун ел эчендә генә күренгән. «Һәрхәлдә, мин мәктәптә укыганда, бездә ул рәсем юк иде», — ди ул. Кемдә булган бу рәсем, мине тагын нинди ачышлар көтә?

Мәскәүгә икенче баруымда мәсьәлә ачыкланды. Рәсем башта Шәмсенисаның олы кызы Фатыймада булган. Фатыйма апаның улы Әхәт абый әйтүенчә, әнисе һаман саен рәсемне кулына алып: «Әнием, бәгърем», — дип үбә торган булган. Соңыннан рәсем Фатыймаападан Мәрзия апага күчкән.

1937 елда Мәскәүгә килгәч, Хәйрулла абзый бертуган Хөсәен абыйсының улы Таһирның гаиләсе белән бергә рәсемгә төшкән. Бик моңлы, хәсрәтле чагы булган Хәйрулла абзыйның, рәсемендә дә шул чагыла.

1910 елда Татарстан китап нәшрияты Һади Такташның моннан утыз ел элек дөнья күргән өч томлыгын кабат бастырып чыгарды. Ике басманы да бер үк төзүчеләр әзерләде. Соңгысына без «Төзәтелгән, тулыландырылган икенче басма» дип куйдык: байтак өстәмәләр керттек, фоторәсемнәр белән бизәдек. Китап сөючеләрнең интернет сөючеләргә әйләнә баруын да, талантлы язучыларыбызның Татар-

Казанда 1925-1931 елларда Һ.Такташ яшәгән йорт

стан китап нәшрияты зур зәвык белән әзерләп чыгарган күптомлыклары кибет киштәләрендә үз укучысын көтеп ятуын да белгәнгә, күңелне, хәзерге көндә Такташны сагынучылар бармы икән, дигән борчулы кызыксыну биләде. Һәм ни хикмәт?! 2500 данә тираж белән чыккан өчтомлык милләттәшләребезнең кече теленә дә йокмый калды — бер ел эчендә сатылып та бетте. Менә бу, чыннан да, халык мәхәббәте! Бәс, шулай булгач, ник соң татар халкының сөйкемле сөяге, горурлыгы булган Такташка һаман музей ачмыйбыз? Хәзерге Кремль урамында «Уникс» бинасы урынында иде бит аның яшәгән йорты. Бик тә төзек, матур йорт иде ул. 1980 елда «1925-1931 елларда Такташ яшәгән йорт» дип истәлек тактасы да эленгән иде. Йортны сүткәндә яңа бинаның ике бүлмәсе Такташ музее өчен булыр дип вәгъдә дә иткәннәр иде. Әмма дөньяның асты-өскә килеп, биргән вәгъдәләр онытылган, язган кәгазьләр, документлар да юкка чыккан...

Музей ачылуын көтә-көтә көтек булгач, шагыйрьнең йөзьеллыгы көннәрендә Хәнифә апа биргән әманәтләрне — әниләре бәйләгән карават япмасын һәм абажур япмаларын — мин Татарстан Милли музеена тапшырдым. Исән чагымда урнаштырып калыйм, дидем. Такташның архивы да шунда бит. Укучылар ул архивта нәрсәләр ятканын да белми, әлбәттә. Хәтта музей хезмәткәрләре дә һәрвакыт карап, барлап утыра алмый инде.

Шундый бер гаҗәп хәл истә калган. 2001 елда Ш.Камал музеенда шагыйрьнең йөзьеллыгына багышланган күргәзмә ачылган иде. Шунда Милли музейның бер хезмәткәре тамашачыларга «менә Такташның әнисе» дип, әлеге дә баягы рәссам Хәнифә апага охша-

тып ясаган портретның кечерәйтелгән фотосурәтен күрсәтте. Югыйсә, 1986 елда мин Такташ әнисенең фотосурәтен «Азат хатын» журналында бастырып чыгаргач, Милли музейда әдәбият фондының ул вакыттагы җитәкчесе Дания апа Баһаветдинова әлеге зур портретны музейдагы дивардан алдырган иде. Ә әдипнең музее булса соң — һәрнәрсә дә үз урынында булыр иде бит!

Милли музейга мин Такташ әнисе рәсеменең оригиналын да тапшырдым. Рәсем шактый таушалган, урыны-урыны белән тоныкланган иде. Аны яңартуда, бастырып чыгарырлык дәрәҗәгә җиткерүдә фотограф-художник Зөфәр Бәшировның зур ярдәме тиде. Ул фотога төшерде, ретушердан эшләтте, кабат төшерде. Һәм рәсем хәзер басылып килгән рәвешенә керде. Зөфәр останың әйтүенчә, фото, борынгыча, пыялага төшерелгән булган, ул сынган, рәсем шул сынганнан соң алынган икән.

Милли музейга Такташның әтисе сурәтен дә, Сыркыдыда туып-үскән йорты рәсемен дә, башка әйберләр белән бергә тапшырдым. Үз музее булмагач, ятар инде алар шунда. Шунысын да әйтим: Такташның әтисе, әнисе рәсемнәрен күбәйтеп, мин әдипнең балаларына гына түгел, Ташкентта, Мәскәүдә, Петербургта, Уфада үзем йөреп эзләп тапкан туганнарына да тараттым. (Аларның һәркайсына да Такташ мәсьәләсендә мин беренче булып «аяк баскан» булып чыктым, әдипнең шәҗәрәсен дә туганнары ярдәменнән башка гына төзеп булмый бит.) Музеена куярлык, әти-әниләре белән бәйле әйберләр шагыйрьнең сеңлесе Хәнифә апа квартирасында да бар иде. Шулай ук шагыйрьнең Мәскәүдә яшәгән бертуган апасы Фатыйманың улы Әхәт абый квартирасында метр ярымлы өч бүрәнә ята иде. Әхәт абый, Сыркыдыда бабалары өе тәмам җимерелеп беткәч, тазаракларын җыеп алып кайткан икән. Музее ачылса, кадерле экспонат булыр дип саклый иде. Хәзер инде Хәнифә апа да юк, Әхәт абый да вафат. Кызганыч, без шагыйрьнең туганнары саклап торган кадерле ядкярләрне югалттык инде. Ә бит вакытында мин Милли музей җитәкчелегенә дә, Татарстан Республикасы Министрлар советында культура бүлеген җитәкләгән Мансур Хәсәновка да, үзем эшләгән Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры Яхья Абдуллинга да болар турында хәбәр иткән идем.

Безгә руслардан үрнәк алырга иде. Алар күпме күренекле милләттәшләренең йортларын (кайберләрен хәрабәдән) торгызып, музейларын ачтылар. Үз йортлары булмаганнарга шәһәр уртасында, Бауман урамында берсенә һәйкәл куярга урын да, икенчесенә музеен ачарга бина да таптылар. Безнекеләрнең йортлары юк шул — Тукайныкы да, Исхакыйныкы да, Такташныкы да юк... Исхакый белән Такташка башкалабызда музейларын ачу турында да, һәйкәлләр кую турында да һаман кайгыртмыйбыз. Моңа нәрсә комачаулый соң? Милли горурлыгыбызның градусы түбән булумы? Әллә без шундый моңсыз милләтме? Милләтнең бөеклеген бөек шәхесләре билгели, диләр. Ләкин бөек шәхесләрне күрсәтә дә белергә кирәк бит!

Еллар бер-бер артлы үткән булыр,
Исмем сезгә җитмәс — онтылыр... — дип язган идең, кадерле Такташ. Юк, исемең дә, иҗатың да онытылмады. Син безнең бөек, сөекле шагыйребез булып каласың. Тик кадереңне генә белә алмадык... Музей да кора алмадык, һәйкәлең дә юк. Яшәп киткән йортыңа куелган истәлек тактасының да хәзер кәгазьдәге сурәтенә генә карап моңаябыз... ■

ЗАРИФ МӨЭМИНОВНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

ӘКИЯТЧЕ БАБАЙ

ФАКИЛ САФИН,
язучы, филология фәннәре кандидаты

СОҢГЫ ИКЕ ЕЛДА МӘГЪРИФӘТЧЕ-ПЕДАГОГ, ФОЛЬКЛОРЧЫ-ӘДИП ЗАРИФ МӨЭМИНОВНЫҢ БИОГРАФИЯСЕН, ИҖАТ МИРАСЫН БАРЛАУ, ҺӘМ АНЫ ӘДӘБИ ЭШКӘРТҮ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНДЕМ. БҮГЕН БУ ЭШНЕҢ БЕРЕНЧЕ ЭТАБЫ ТӘМАМ, КУЛЪЯЗМАНЫ АЕРЫМ КИТАП ИТЕП БАСТЫРЫП ЧЫГАРУ ЭШЕНӘ КЕРЕШЕРГӘ БУЛА. КИТАПНЫ, АВТОР ҮЗЕ ИСКӘРТКӘНЧӘ, «МАҖАРА» ДИП АТАДЫМ ҺӘМ, ЧЫННАН ДА, ӘГӘР КИТАПКА ДӨНЬЯ КҮРҮ НАСЫЙП БУЛСА, ҮЗЕ БЕР МОГҖИЗА, ИСКИТКЕЧ МАҖАРА, ГАҖӘЕП ХӘЛ.

Зариф Мөэминов (1893-1966).
Рәссам Фаил Ислам репродукциясе

Җыентыкка тупланган язмаларның авторы — Мөэминов Әхмәтзариф Әхмәтлатыйф улы. Мөслим районы Октябрь авылында яшәгән фольклорчы-мөгаллим. 1893 елда туган (кайбер чыганакларда — 1855 ел. — Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1988. — Б.400), 1966 елда вафат булган. Исеме «Татар энциклопедиясе сүзлеге»нә кергән. Аның турында: «Әкиятче, 1939-1941 елларда Татарстан Халык Комиссарлары каршындагы Тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институтына 50дән артык әкият туплап җибәргән. Аларның күпчелеге халык авыз иҗаты җыентыкларында

* Гыйнвар аенда хөрмәтле язучыбыз Факил Сафин үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Аңа сәламәтлек, иминлек, иҗади уңышлар телибез.

Зариф Мөэминовның кулъязмалары

басылып чыкты», — диелгән. (Исем-фамилиясе кыскартылып, үзе тарафыннан да, «Татар халык иҗаты» җыентыкларында да Зариф Мөэминов дип күрсәтелә. Без дә шушы әдәби тәхәллүсне калдырырга булдык.) Икенче чыганак — «Без — Мөслим балалары» китабы (автортөзүчесе якташыбыз, язучы Флүр Баһаветдинов. Казан: «Идел-Пресс» нәшрияты, 2006. — Б.416-417). Зариф Мөэминовны моннан ярты гасырлар элек үк ишеткәнем дә, хәтта... күргәнем дә бар иде. Укымышлы зат, мөгаллим, гомере буе татар халык авыз иҗатын өйрәнгән, туплаган, җае чыккан саен, Казанга, Тел, әдәбият һәм тарих институтына җибәргән, анда эшләгән фольклорчы-галимнәрне яхшы белгән. «Татар халык иҗаты» җыентыкларындагы беренче чыганакларга — 1938 ел, соңгыларына 1948 ел дип куйган. Әле аннан соң да тынгысыз мөгаллим бу эшен туктатмагандыр. Зариф Мөэминов бигрәк тә күренекле фольклорчы-галим Хәмит Ярми белән эшлекле мөнәсәбәттә булган. Чыганаклардан күренгәнчә, 1941, 1948 елларда Хәмит Ярми фольклорчы дусты Зариф Мөэминовтан шак-

тый әкият, бәет, җыр, мәкаль-әйтем, табышмаклар язып алган.

Безнең якта аны Зариф абзый яки «Әкиятче бабай» дип йөртәләр иде. Ул яшәгән, озак еллар укыткан, мөгаллимлек иткән авыл — Мөслим районы Октябрь (1940 елга кадәр Теләнче атамасы белән йөргән, төбәктәге борынгы авылларның берсе) мин туып-үскән Әмәкәй авылыннан сигез чакрым чамасы ераклыкта. Теләнчедә туган-тумачаларыбыз бар иде. Әмәкәй, заманында волость үзәге, базарлы, ярминкәле зур авыл булган. Әле мин кечкенә вакытта да һәр атнада базар була иде, базар көннәрендә (якшәмбе булгандыр инде ул) Теләнчедән кем дә булса безгә кермичә китми иде. Ул вакытта аралашу өчен хәзерге мөмкинлекләр юк, очрашкач, һәр ике як бер-берсенә авылдагы барлык яңалыкларны, искә алырлык эш-вакыйгаларны тезеп чыгалар иде. Әлеге сөйләшүләр вакытында, әңгәмәгә ихлас бирелгән өлкәннәр, тирәләренә сырышып, һәр сүзне күңеленә сеңдереп торучы алтыҗиде яшьлек малай — мин барлыгын исләренә алып та карамаганнардыр, билгеле. Мондый әңгәмә вакытында Зариф абзый исеме дә телгә алынгалый, ул йә Казанга, зур кешеләр янына барып кайткан, йә аны кемдер Уфага чакырып хат юллаган, атна буе йөреп, бер капчык китап төяп кайтуы хакында сөйләп, аның зирәклегенә, тапкырлыгына, җорлыгына мөкиббән булып утыралар иде. Аның янына тирә-яктан киңәшкә дип килүчеләрнең өзелмәгәнен дә ишетеп белә идем. Хәзер инде бөтенләй онытылып беткән искиткеч күркәм йола-гадәт бар иде татар халкында — дөнья күргән, белекле кешегә, нindидер катлаулы хәлдән чыгу юлын эзләп, киңәш сорап мөрәҗәгать итү иде ул. Халыкта аны кыскача «киңәшкә килү» дип атаганнар. Бер-бер кешенең чишеп-ерып чыгасы шактый катлаулы эше алга килеп басса, шушы туган мәсьәләләр хакында сөйләшеп, фикерләшү, олпат затның мәсьәләгә карата төпле сүзен ишетү өчен, «киңәш-табыш итүче» янына хәтта ерак-ерак аралардан да килеп чыкканнар. Истәлекләргә караганда, «Әкиятче бабай» шундый абруйлы кеше булган.

Язмалардан күренгәнчә, язмыш Зариф бабайга бик үк миһербанлык күрсәтмәгән. Күп илләр, җирләр гизәргә, күптән-күп җәфалар күрергә, җәбер-золымнар да кичәргә туры килгән. Бу хакта «Без — Мөслим балалары» китабында түбәндәге мәгълүматлар бар: «Австрия-Венгрия территориясендә Зариф Мөэминов әсирлеккә эләгә. Монда ул башка әсир татарлардан ишеткән халык әкиятләрен язып ала башлый. Әсирләрдән җыелган әкиятләр берничә дәфтәр тәшкил итә... Әсирләрне Сараево шәһәренә күчергән вакытта тентеп, әкиятләр тупланган дәфтәрләрне дә табалар һәм Зарифтан алалар. Ләкин әкиятләр югалмый, чөнки аларның күбесе әкиятченең башында була, ул аларны яттан белә. Әкиятләрнең бер өлешен Зариф, күрәсең, авыл картларыннан ишетеп, Бөек Ватан сугышына кадәр язып ала. Дәфтәрләргә шулай итеп Исмәгыйль карт, Латыйп бабай, Габдрахман агай, Габделҗәлил карт, Йосыф карт Хәлилов, Шакир Закировлардан ишетелгән әкиятләр керә». Әкиятләр шактый туплангач, ул аларны Казанга юллый. Әлеге үрнәкләр белән танышкан Гомәр Бәширов әкиятче Зариф Мөэминов эшенә югары бәя бирә.

Зариф ага озак еллар туган авылы Теләнчедә балалар укыта. Октябрь революциясеннән соң авылның беренче укытучыларыннан санала. Ул дәвердә укытучыларны бер авылдан икенчесенә күчерү тәртибе була. Шуңа күрә, истәлекләргә караганда, Зариф Мөэминов Теләнчедә өзеклекләр белән 1919-1927 һәм 1937-

1948 елларда мөгаллимлек итә. 1943-1944 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша. Ул — өч сугышта катнашкан, ил, халык язмышындагы барлык фаҗигаләрнең, сынаулы елларның турыдан-туры шаһиты булган солдат-әдип. Сугыштан кайткач, укытучылык эшен дәвам итә. Туган авылында гына да унҗиде ел балаларга белем бирә. Тагын кайсы авылларда укыткандыр, анысын ачыклау киләчәк эше (Зариф аганың әдәби мирасын өйрәнү чорында, безнең кулда аның тормыш юлын сурәтләгән язма материаллар юк иде. Октябрь авылына кайтып, сораштырып йөрүләремнең дә файдасы аз булды. Әмма 2013 елның гыйнвар ахырында Октябрь авылында яшәүче Фәрит Гыймранов миңа Зариф ага Мөэминовның үз кулы белән язылган «Тәрҗемәи хәл» исемле язмасын китереп тапшырды. Кулдан эшләнгән калын гына дәфтәрдә ике автобиографик материал бар иде. Берсе — тәрҗемәи хәленең шактый тулы варианты, икенчесе кыскачарак язылган. Болар Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор секторы белгече, галим Хәмит Ярми үтенече белән язылган булырга тиешләр. Шушы ук дәфтәрдә Зариф Мөэминовның хәлфәлек иткән чорында кайсы авылдан кайсы шәкертләргә белем биргәне дә җентекләп теркәлгән. Бу кулъязмалар озак еллар дәвамында З.Мөэминовның авылдашы, әлеге авылда озак еллар муллалык вазифасын башкарган Сәрвәретдин бабай Баһауов архивында, чормада сакланган. Фәрит Гыймрановка язмаларны Сәрвәретдин бабайның оныгы Мөнир тапшырган. Соңыннан Зариф бабайның улы Нәкый абыйның улы Илфак миңа бабасының үзләрендә саклатган архивын тапшырды. Алар югалмаган, үз сәгатьләре сугуын тыныч кына көтеп ятканнар икән).

«Тәрҗемәи хәл»нең тулы вариантын сезнең игътибарга тәкъдим итәбез.

МӨСЛИМ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬ АВЫЛЫ ҖИДЕЕЛЛЫК МӘКТӘБЕНЕҢ БАШЛАНГЫЧ КЛАССЛАРЫНДА (ГОМУМИ БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘБЕ УКЫТУЧЫСЫ) МӨЭМИНОВ ЗАРИФ ЛАТЫЙПОВИЧНЫҢ КЫСКАЧА ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕ

Мин 1893 елның 15 июлендә Уфа губернасы Минзәлә өязе Әмәкәй волосте Теләнче **(хәзер — Октябрь. — Ф.С.)** *авылында урта хәлле крестьян семьясында тудым. Минем әти һәм әни җәй көне кыр эшләре, кыш көне үзебезнең өйгә балалар җыйнап укыту белән шөгыльләнделәр. Ир балаларны мәдрәсәдә уку өчен әзерлиләр иде. Җиткән кызлар да белемгә омтыла, аларны укыту әни өстенә төшә иде. Әти — Теләнче авылының Нигъмәтулла хәзрәт улы, әни — Күбәк авылының Гариф мөәзин кызы. Мине 11 яшькә кадәр әти укытты. Унбер яшемдә чакта, 1904 елда, әти мине Күбәк авылыннан Низаметдин бине Хисаметдин әл Ахуныйның муллалар әзерләп чыгара торган дини мәдрәсәсенә укырга илтте. Биш елда мин бу мәдрәсә программасын укып тәмамладым. 1909-1910 уку елында мөдәррис Низаметдин хәзрәт миңа хәлфәлек хокукы бирде һәм шушы уку елында 25 шәкертне укытырга тапшырды.*

Беренче кышны укытып, имтихан алып, шәкертләрне авылларына тараткач: «Яхшы укытучы, тырыш һәм белемле хәлфә», — дигән исемем тирә-юньгә таралды. Шул заман кешеләре һәм үзем укыткан шәкертләр, хәзерге көндә дә мәктәптә укыткан укучыларым мине шушы даным белән искә алалар. Бу фактның дөреслеген искәртү өчен, түбәндәгеләрне күрсәтеп үтәргә тиешмен: 1910-1911 һәм 1911-1912 елларда үзләре укып ята торган мәдрәсәдәге хәлфәләрен, мөдәррисләрен ташлап, йөзәр чакрым җирләрдән дистәләрчә шәкертләр миннән укырга

Күбәк мәдрәсәсенә җыйналды. Мәсәлән, Кама буендагы Дәвек, Ык буендагы Калморза, Бикбау **(хәзерге Минзәлә районы авыллары. — Ф.С.)** *дигән авыллардан, Иске Әгъбәс* **(хәзерге Актаныш районы. — Ф.С.)**, *Әлмәт, хәтта Әмәкәй авылы* **(хәзерге Мөслим районы. — Ф.С.)** *мәдрәсәләреннән укырга дип каршыма килеп бастылар. Урәзмәт, Иске Сәет, Исәнсеф, Бүләр* **(Мөслим районы. — Ф.С.)**, *Түбән, Югары Яхшый* **(Актаныш районы. — Ф.С.)** *авылларыннан күпсанлы шәкертләрем килеп укыдылар.*

Иске мәдрәсә тәртипләренә каршы күп көрәшергә туры килде. Мәчеткә йөрүне мәҗбүрилектән ихтыярлыкка калдырдым, шәкертләр өчен җылы кухня, җылы юыну урыннары — госелханәләр булдырдым. Дәресләрне ныклы расписание белән үткәрүне керттем, башлангыч белем алучыларның барысын да укырга һәм язарга өйрәтү, нумерация, арифметикадан дүрт гамәлне махсус расписание нигезендә өйрәнүне башладым. Иҗат эшләренә ныклы игътибар бирдем. Әдәби кичәләр, инкыйлаби җырлар өйрәтү, бергәләп җырлау, махсус җыр һәм рәсем дәресләре кертүне юлга салдым.

Ул заман халыклары мине шушы гамәлләрем өчен бик яраттылар. Билгеле, иске тәртипләргә каршы чыгуым мөдәррис, карт хәлфәләргә һич тә ошамады. Берничә мәртәбә мине полиция кулына тотып тапшырмакчы булдылар. Ләкин халык мине яклап калды. Шул көннәрдән соң көчнең халык ягында икәнлегенә ышандым.

Шәкертләр торган саен миңа тартылалар иде.

1909-1910 уку елында 25 шәкерт укыттым;

1910-1911 елда 35 шәкерт укыттым;

1911-1912 елда 40 шәкерт укыттым;

1912-1913 елда 60 шәкерт укыттым;

1913-1914 елда 80 шәкерт укыттым.

Шушы елда мине мәдрәсә казые итеп сайладылар. Мине яклап 270 шәкерт тавыш бирде. Казый булган елны мәдрәсәдә ысулы җәдид тәртибе тәмам урнашып бетте дияргә була.

1914-1915 елгы уку елына аяк баскач, 15 февраль көнне мине Германия сугышына җибәрделәр. Казыйлыкны Корыч авылыннан **(хәзерге Башкортстанның Бакалы районына керә. — Ф.С.)** *Нуретдин әфәндегә тапшырып киттем.*

1915 елның май аенда безне Австрия фронтына китерделәр. 1915 елның 5 июнендә разведкага җибәрделәр. Төркемдә ике рус солдаты, ике татар егете бар иде. Ике австрия офицерын, бер немец офицерын, блиндажларыннан тотып алып, әсирлеккә алып чыктык. Шул ук көнне штык сугышында ике немецны кадап ташладым, өченчесен пленга алдым. Шушы батырлыгым өчен һәм хәрби заданиене яхшы итеп үтәгәнгә, 191 нче Ларгокагульский **(Ларго-Кагульский полк. — Ф.С.)** *полкның командиры мине беренче дәрәҗә Георгий хачы медале белән бүләкләде. 1915 елның 8 июнендә, сул кул һәм сул аягым яралану сәбәпле, австриялеләр пленга алдылар. Ел ярым дәвалангач, эшкә ярарлык хәлгә килдем. 1916 елның октябрендә хәзерге Югославиядәге Бүснә-Һәрсәк һәм Хорватия җирләренә китерделәр. Сараево, Торавник, Загрев шәһәрләрендә такта яру заводларында эшләдем.*

Әсирлектә чакта төрле милләт кешеләре белән таныштым һәм алардан күп төрдә хикәяләр ишетеп, дәфтәрләргә теркәп бардым. Шунысы кызганыч: 1917 елда Троуник шәһәреннән Сараево шәһәренә күчергән вакытта, сумкаларыбызга тентү ясап, немец полицияләре минем тарафтан җыйналган 500дән артык төрле халык әкиятләре язылган 50дән артык дәфтәрдән торган

җыентыгымны конфисковать итеп алдылар. Үземне 15 көн аерым камерада арестта утырттылар. Шушы көннәрдә солдатлар хәрәкәтендә актив катнаша башладым.

1919 елның гыйнвар аенда үз илебезгә кайттым. Илдә совет власте урнашкан иде. Кайтуга, мине волость мәгариф шурасына сайлап куйдылар. Мәктәпләре булмаган авылларда мәктәпләр ачтырырга ярдәм иттем, үзебезнең авылда да мәктәп ачып, укыта башладым. Кирилл Назаров дигән бер алпавытның зур йортын, Минзәлә кантоны мәгариф шурасы киңәше белән, үзебезнең авылга мәктәп бинасы итеп күчереп салдырттым. 1919 елның май аенда бу мәктәпнең бинасын аклар, колчакчылар, әлеге алпавыт Назаровның малайлары кире сүтеп алып китте. Алар ак офицерлар иде. Мин бу вакытта аклардан качып йөрдем. 1919-1920 елгы уку елына үзебезнең Теләнче авылына тагын мәктәп ачып укыта башладым. 1920 елның 15 мартында авылга сәнәкчеләр килеп керде, мәктәпне туздырып ташладылар. Мин тагын качып котылдым. 1920 елның май аенда Кызыл Армия сафына киттем. Пермь **(хәзерге Молотов. — Ф.С.)** *шәһәрендәге 48 нче запасной полкка килүгә, мине муссекция, ягъни мөселман секциясенә алып, кызылармеецларны укытырга куштылар. Полк командиры — Зутов, комиссары — Хәмзә Чанышев, политрук — Миннеяров, аның ярдәмчесе мин идем.*

1920 елның октябрендә тиф белән авырып, Усулня, хәзерге Березники больницасында ятып чыктым. Терелгәч, үзебезнең Теләнче авылына кайтып, мәктәп ачып укыта башладым. Әмәкәйдәге волисполком рәисе Зарифуллин, волкомсекретаре Черновлар белән киңәшеп, 1928 елда Әмәкәй авылындагы элекке земство мәктәбе бинасын Теләнче авылына күчереп, мәктәп итеп салдырттым. Шулай итеп Теләнче авылында мәктәп ныклы нигезгә салынды, моңарчы ул төрле өйләрдә урнашкан иде.

Теләнче авылында 1919-1920 еллардан 1921 елның май аена кадәр (ике кыш) Галимов Харрас өендә балалар укытылды.

1921-1922 һәм 1922-1923 уку елларында, ягъни ике ел — Нәфыйков Мусахан өендә; 1923-1924 һәм 1924-1925 уку елларында — ике ел дәвамында Габдуллин Әһлиулла; 1925-1926 һәм 1926-1927 уку елларында, ике ел үземнең өемдә балалар укыттым. Шулай барысы сигез ел үтте. Аннан соң Баекка күчтем.

1927-1928 елгы уку елында КОНО **(Кантон халык мәгарифе бүлеге. — Ф.С.)** *миңа, Баек авылында мәктәп ачып, укытуны башлау бурычын йөкләде. Мәктәп ачып, укытуны юлга салу ул вакытта җиңел түгел иде. КОНО авыл уртасыннанрак ике класс сыйдырышлы йорт табып, йорт хуҗасы белән арзанрак бәягә килешүне таләп итә иде. Өй хуҗалары белән уртак тел табу авыр иде. Алдан ук йортларында спектакль уйнатмау шарты куялар. Алар аны, бозып, «спикатил», диләр иде. Договорга шул шарт язылмаса, укыту өчен йортларын бирмиләр иде. Баек авылында Сәхип дигән кешенең өендә, 80 бала җыеп, ике сменада укыттым. Ләкин КОНО һич тә мине иреккә куймады. Бер ел Баекта мәктәп ачып, эшләр рәтләнгәч, мине Яңа Сәфәр авылына мәктәп ачып, укыту эшен оештырырга җибәрде. Шушы кечкенә авылда 60 бала җыеп, ике сменада укыттым.*

Теләнче авылында 1928 елның җәендә авыл советы рәисе Рәхмәтулла Исмәгыйлев кулаклар тарафыннан үтерелде. 1929 елның көзендә КОНО мине, Яңа Сәфәр авылыннан мәҗбүри рәвештә укыту эшеннән алып, авыл советларына сайлаулар чорында Теләнче авылына кайтарды. Бер шарт куелды: «Син Теләнчегә

Совет төсе, Совет тәртибе керт!» — диделәр. Бер тавыштан авыл советына депутат булып сайландым, авыл советы секретаре булып эшли башладым. Бер үк вакытта яңалиф **(латин алфавиты нигезендә укырга, язарга өйрәтү. — Ф.С.)** *вазифасын да миңа йөкләделәр. Олыларны кичке мәктәптә укыттым. Колхозлашу эшендә ныклап торып катнаштым.*

1932 елның июнендә Мөслимдә укытучылар курсында белем алдым. Курслар тәмам булгач, РОНО **(Район халык мәгарифе бүлеге. — Ф.С.)** *мине Нарат-Асты авылына укыту эшенә җибәрде. Бу авылда ике ел укыттым, мәктәп мөдире дә булдым.*

1934-1935 уку елында РОНО мине тагын Баек авылына мәктәп мөдире итеп билгеләде. Бу юлы Баекта өч уку елы дәвамында эшләдем. 1937 елда Баекта җидееллык мәктәп ачтым. 1937 елның октябрь аенда Теләнчегә «Комсомолларның урта мәктәбе»нә директор итеп билгеләп, туган авылыма кайтардылар. География һәм тарих укыттым. 1939 елда Теләнчедә җидееллык мәктәп ачылды. Мин башлангыч классларда укыта башладым. 1943 елның март башында Бөек Ватан сугышына киттем. Смоленск фронтында булдым, 1943 елның 6 сентябрендә гитлерчыларны Смоленскидан куып чыгаруда актив катнаштым. Авыр яраландым, 1944 елның март башында өйгә кайттым. 1947 елның июненә кадәр укыту эшендә булып, РОНОдан эштән җибәрүләрен сорап гариза яздым. Минем гаризам канәгатьләндерелде. 1942 елдан пенсиядә булып саналам.

1919 елда Теләнче авылыннан урта хәлле крестьян Габдулла кызы Шәмсекамалга өйләндем. Шул карчыгым белән бүгенге көнгә кадәр тормыш итәм. Изге Ватан сугышында өч улым, бер кызым катнашты. Олы улым Һади, унынчы классны тәмамлагач, 1940-1941 уку елында Күбәк урта мәктәбендә укыта башлаган иде. Хәрби хезмәткә китеп, НКВД гаскәрендә, чекист булып фашистларга каршы сугышка керде. 1942 елда батырларча һәлак булды. Сержант иде. Уртанчы улым танк йөртүче булып сугышты. Фронтта берничә мәртәбә яраланды. Өлкән сержант. Кече улым химия частенда булды.

Эш дәверемдә макталдым, һәрчак зурлап килделәр. 1936 елгы укытучылар конференциясендә рух төшенкелегенә бирелгәнем өчен тәнкыйть иттеләр. КОНО тарафыннан макталсам да, районга калгач, минем укыту эшемә бәһа бирүче булмады. Юк-бар сәбәпләр табып, бәйләнүләр булды, тик һәрвакыт минем сүзем дөрескә чыкты. Партияле булмадым, эшемә партия әйбәт бәһа бирде. Бу сүзләрне хәзерге көндә район газетасы редакторы Кадыйров Һади да раслый. Ул — чын коммунист.

Иҗат эшләре буенча 1939 һәм 1940 нчы елларда «Халык иҗаты» исемле җыентыкта минем үзем иҗат иткән «Кызыл партизаннар» бәете ике тапкыр басылып чыкты. Шунда ук мин җыйнап биргән җиде әкият тә басылды. 1942 елда минем тарафтан җыелган 75 әкият «Хуҗа Насретдин әкиятләре» китабында басылды. 1946 елда игълан ителгән конкурска «Авыл картиналары» исемле бер җыентык тәкъдим иттем. Басылырга чиратка куелган булса кирәк.

1948 ел, 20 сентябрь

Күренгәнчә, Зариф ага башыннан кичкәннәрнең шактый өлешен шушы кулъязмага теркәп куйган. Зариф Мөәминов туплаган күп кенә халык иҗаты әсәрләре Октябрь авылындагы янгында юкка чыккан дип уйланыла иде. Тагын шунысын да искәртергә кирәк: чит илдә әсирлеккә эләккән кешеләргә совет хакимияте чорында шикчел, кимсетүле караш яшәгән бит. Мондый

шәхесләрне даими эзәрлекләүләр совет хакимияте урнашуның беренче елларыннан алып (шәхес культы котырынган 1937-1953 елларны аерым күрсәтү кирәк) 1968 нче елларга кадәр дәвам итүен искә алу да җитә. Шуңа күрә Зариф Мөәминовның бик язасы килеп тә, язылмый калган кадәресе ун-егерме мәртәбә артык күләмдә булгандыр дип фаразларга мөмкин. Әлеге фикерем ул туплаган халык авыз иҗаты әсәрләренә дә кагылышлы. Шуңа күрәдерме, язганнарын кат-кат төзәтеп, әдәби кимәлгә китерүне соңгарак, киләчәк буыннарга васыять итеп калдырган. Бу аның җыентыкка язган сүз башында да ачык чагыла. Шулай ук фольклор материалларын җыйнауны кирәкмәгән эш дип күрсәтергә азапланучылар да булгандыр, шунлыктан Казанга, галимнәргә язган хатларында бер үк сорауны юллый — халык иҗаты әсәрләрен җыйнау белән шөгыльләнүе дөрес эшме, кирәклеме ул?..

Зариф Мөәминов — Мөслим төбәгендә әдәби мохитне тернәкләндереп җибәргән, бу эшнең башында торган тәүге карлыгачларның иң күренеклесе, хөрмәткә лаек, ихтирам белән телгә алынырга тиешле әдип, мәгърифәтче. Язмыш аны туктаусыз төрледән-төрле сынау алдына куеп торганлыктан, ул әдәбиятыбыз күгендә якты йолдыз булып кабынып китә алмаган. Соң булса да, уң булсын, берәр бик миһербанлы шәхес, өммәттәшебез, булдыклы, иманлы якташыбыз ярдәме белән, Зариф Мөәминовның язганнары, иншаллаһ, укучылар кулына барып ирешер дигән өметтә калам. Кулъязмалар янмый, диләр. Бу сүзләрне Зариф аганың әлеге җыентыгы тулысынча раслый.

Истә калганы — Зариф бабай аратут йөзле, күбрәк башкалар сөйләгәнгә колак салып утыручы кеше буларак хәтердә калган. Шактый нык бәдәнле, озын гына буйлы, күзләрен нигәдер аскарак төбәп торучы абзый булып күңелдә саклана.

Дөнья кызык бит, ул чыннан да маҗарага тиң. Күпмедер вакыт үткәч, кайчандыр Зариф Мөәминов мөгаллимлек иткән Октябрь мәктәбендә укытырга, хәтта директор булып эшләргә дә насыйп булды. Мәктәптә әле Зариф бабайның шәкертләре укыталар, алар да бу хикмәт иясе мөгаллим хакында еш телгә алалар иде. Зариф Мөәминовның гомере буе язучылык белән шөгыльләнүе, язмаларын Казанга җибәреп тә, бер эш тә чыкмагач, арыш капчыгына салып, Уфага илтеп бирүе хакында искә алучылар бар иде. Мәктәптә төрле вазифалар башкарган Шәрифҗан Шакирҗанов, Рәиф Хисамов абыйлар Зариф бабай турында белеп, яратып, аерым горурлык белән телгә алалар иде. *«Зариф абзыйның дөньяда белмәгәне юк иде, ул беркайчан да ялган язмады. Үзе күргәнне, үзе белгәнне шулкадәр мавыктыргыч итеп сөйли. Ул язганнарны басарга рөхсәт тә итмәгәннәрдер инде. Кайбер язганнары газеталарда басылып чыга иде. Казаннан, Уфадан зур-зур конверт белән хатлар килеп торды. Гаҗәп сабыр кеше иде, әмма кул кушырып та утыручы түгел, яше өлкәнәйгәч тә, Казан, Уфа якларыннан урап кайтты. Ул язган пьесаларны авыл үзешчәннәре белән сәхнәдә уйнап, район смотрларына бара идек. Күп телләр белә иде, бер сүзне әллә ничә телдә әйтеп күрсәтеп, һушларны ала торган иде. Әле укытырлык чуты бар иде, укытудан туктаттылар. Белеме җитми дигән сылтау белән. Өстеннән жалу язучылар булды бугай, имеш: «Муллалыкка укыган башы белән совет балаларының башын бутап ята...»*

Шушы авылда гомер кичергән Әбүзәр Әхмәткәрәм улы Солтанов болай сөйләгән иде: *«Ул җор телле иде. Һәрнәрсәгә фикерен ачык итеп җиткерә, без — укучы балалардан да шуны таләп итә. Төрле фәннәрдән укытты. Ничектер тактага гарәп графикасы белән сүз язып куйды. Кем-*

дер әләкләгән, шуның өчен нык кына эләкте бугай Зариф абыйга. Без аны башка укытучыларга эндәшкән кебек «абый» дип кенә түгел, ничектер, олылап, «Зариф абый» дип йөрттек. Шаяртырга ярата иде, әмма чыгырдан чыксак, колактан шәп кенә тартып та куя иде. Кулын артка куеп, ашыкмый гына Калмыя елгасы аръягындагы болыннан йөргәнен күрештерә идем. Язган чакларында шулай фикер туплавы булгандыр инде. Ашыкмау, сүзен үлчәп сөйләү, зирәклек, сабырлык, шул ук вакытта җитешсезлекләрне тәнкыйть утында тотарга омтылу — Зариф абыйга хас сыйфатлар шушы булды. Ул күп язды, язган әсәрләре кая китеп беткәннәрдер, белгән юк. Үзе юкның — күзе юк. Теләсә кайда таралышып, исраф булганнардыр инде...»

Зариф бабайның улы Сәгыйть Мөэминов озак еллар колхозда бухгалтер-хисапчы хезмәтен башкарды. Гаҗәеп сабыр, тыйнак, олпат зат иде ул. Улы Нәкый абыйның кулыннан килмәгән эше юк иде. Бүген авылда Зариф Мөэминовның оныклары яши. Сораштырып караганым булды, әмма алар да язучы-фольклорчы бабайлары хакында мин башкалардан ишетеп белгәннән артыгын сөйли алмадылар. Күбесенең әти-әниләре, ягъни Зариф бабайның балалары иртәрәк вафат булганнар. Күрәсең, дөнья мәшәкатьләре белән йөреп, бабай хакында ныклап сөйләү, яшь буынның хәтерләренә сеңдерү кичегә килгән... Шулай да хәзер Украинада яшәүче оныгы Халидә Запорожец-Дәүләтгәрәева бабасы хакында кызыклы истәлекләр саклый. Халидәнең әтисе — Дәүләткир Дәүләтгәрәев — Октябрь авылыннан, ул Әхмәтзариф Әхмәтлатыйф улының кызы Әнисәгә өйләнгән. Башта Азнакайда, аннан Таҗикстанда, Дүшәмбе шәһәрендә яшәгәннәр. «Азнакайда чагында Зариф бабам безгә килсә, килеп кергәннән башлап киткәнчегә кадәр без — оныкларына әкият сөйли торган иде», — дип хатирәләре белән уртаклашты Халидә ханым.

Зариф бабай хакында, нигәдер, еш искә ала идем. Безнең төбәктә әдәби эшкә хирыс, маһир булып та, сакланып калган әкиятләреннән башка бер генә әсәре дә дөнья күрмәгән, бөтен язганнары, әдәби архивы янып, каядыр таралып, онытылуга дучар булган мөхтәрәм әдип-мөгаллимнең аянычлы иҗат язмышы хакында соңгы елларда бигрәк тә еш уйландым. Бу уй-хисләрнең туына шактый еллар дәвамында Чаллы шәһәре Башкарма комитетының мәгариф һәм яшьләр идарәсе каршында оешкан «Рухи мирасны өйрәнү төбәк фәнни-методик үзәге»н җитәкләвем дә сәбәпче булгандыр. Әдипләребез язмаларының эзсез юкка чыгуына тап булган бар. Бу гыйбрәт тә, сабак та, төбәкнең рухи мирасын туплау, аны дөньяга чыгару, яшь буынга җиткерү эшен һәрдаим игътибар үзәгендә тотарга тиешлегебезне искәртеп тора. Ярый әле киң күңелле фольклорчы галимнәребез бар, алар, Зариф Мөэминовны онытмас өчен, барысын да эшләгәннәр — үзләренә атап җибәргән әкиятләрне әдәби эшкәртеп, бастырып чыгарганнар, исемен «Татар энциклопедиясе сүзлеге»нә кертмәннәр. Әмма күңел чите китек, калган язмаларның язмышы ничек?.. Шушы сорау озак еллар тынгылык бирмәде. Ходай бар бит ул! — моннан бер ел чамасы элек Мөслимдә яшәп иҗат итүче мәгърифәтче-әдип Мөҗәһит Әхмәтҗанов хәбәр салды (үзе дә Мөслим төбәгенең рухи мирасын барлау, өйрәнү, дөньяга чыгаруда биниһая көч куйган шәхес):

— Безнең якта Зариф Мөэминов дигән бабай булган. Аның хакында ишеткәнең бармы? — диде ул.

Башыма шаулап кан йөгерде. Әле бер атна чамасы элек кенә Зариф бабайның кызы, кияве, оныклары белән төшкән фотосы кулга килеп кергән иде. Хатынымның әнисе —

Гөлчирә әбиемнең бертуган абыйсы Дәүләткир шушы Зариф бабайның киявe була инде. Ул заманында фотога төшерү белән мавыккан. Аклы-каралы фотоны аның истәлеге итеп саклаган Гөлчирә әбием. Вафатыннан соң фотолар хатыным Ләйсирә кулына тапшырылганнар. Әкиятче бабай турында бар белгәннәремне Мөҗәһит Зәһид улына тезеп чыктым.

— Беләсең икән әле... Хәзер андый нәрсәләр белән кызыксынучылар юк бит ул. Миңа Мөслимдә яшәүче Әхсән ага Әмир улы Шәрипов күләмле кулъязма бирде. Гарәп графикасында. Шушы Зариф бабайның язмалары икән.

Әхсән ага — гомере буе районда җаваплы вазифалар башкарган олпат шәхес, Мөслимдә хөрмәтле кешеләребезнең берсе. Гаҗәеп төгәл, пөхтә, чиста һәм киң күңелле кеше, кулына язмалар килеп керүгә, санап үткән сыйфатлар ягыннан үзеннән һич калышмаган Мөҗәһит Әхмәтҗановка мөрәҗәгать иткән. Язмалар гарәп графикасында булганлыктан, папкада ни-нәрсә булуын белү өчен, беренче чиратта, аларны бүгенге без белгән графикага күчереп язу кирәк булган. Мөҗәһит Зәһид улы, бәхеткә, гарәп графикасында укый-яза белүче, үзе гарәп язуын өйрәнү буенча методик кулланмалар төзегән мөгаллим, дүрт йөз битле кулъязманы иренмичә кириллицага күчереп чыккан, инде әдәби яктан эшкәртүне миңа тапшыруны хуп күрә. Якташ бит, җитмәсә, икебез дә төбәкнең рухи мирасын барлау белән җитди шөгыльләнәбез. Язмаларны әдәби эшкәртүне аңлап бетермәгән кешеләргә аңлату кыен булыр инде, әмма кабат әйтмичә булдыра алмыйм — шундый да чуар, буталчык итеп язылган иде алар, һәр җөмләне «кеше» рәтенә кертеп, әсәр «тудырганчы», искәрмә-аңлатмалар төзегәнче, ул юллаган әкият, бәетләрне барлаганчы, кампитрда җыйганчы, елдан артык вакыт үтте. Кулъязма белән шактый күп эшләргә кирәк булачагы хакында Зариф бабай язмаларның башында ук ныклап искәрткән, аңлатмалар да биргән бит инде. Мин аны әкиятче бабайның васыяте итеп кабул иттем, алдан күргән Зариф бабай кемнәрдер, кайчандыр язганнарын алып укырлар, кирәгенчә эшкәртеп-төзәтеп, бастырып чыгарылар дип ышанган. Ышану — иман! Ышанусыз, димәк, имансыз яшәүнең мәгънәсе дә юк! Зариф Мөэминов — безгә иманлы гомер — мәгънәле, өметле тормыш үрнәге калдырып киткән әдип. Купаеп та, зарланып та әйтмим: мондый эштә ордым-бәрдем кыланып булмый, иҗат мирасына сак карарга кирәк, ул зур җаваплылык таләп итә, ахыр чиктә, эшләнгән кадәресенең мәгънәле булуы да кирәк бит. Беркайчан да «миннән киткәнче, иясенә җиткәнче», дип эшкә тотынмадым. Четерекле, хикмәтле эшкә капканымны шундук аңладым, билгеле. Әмма чигенергә урын юк иде — моны мин эшләмәсәм, кем башкарып чыгар? Язмаларның кайбер өлешләрен, автор алдан ук кисәткәнчә, төшереп калдырырга туры килде, алар укучы өчен дә, авторның иҗат язмышы өчен дә әһәмиятле түгел дип саныйм (билгеле, алар да архивта саклана- чак). Бүгенге укучыга таныш булмаган сүзләрне әдәби телгә тәрҗемә итеп, шулай ук авторның йөргән-күргәннәрен, белгәннәрен күз алдына ачык китерү ниятеннән, тарихка мөрәҗәгать итеп, күп кенә искәрмәләр, аңлатмалар бирергә кирәк дип тә таптым. Алар текстта квадрат җәяләр эчендә язылган. Барлык искәрмәләр, аңлатмалар кулъязманы әдәби эшкәртүче-мөхәррир тарафыннан бирелүен кабат әйтеп, кызыксынган кешеләргә аларның файдасы булмый калмас дип уйлыйм.

Чыганаклардан карап фикер йөртсәк, Зариф Мөэминов институтка илледән артык әкият, бәет юллаган. «Әхмәтзариф Мөэминов халык

авыз иҗаты әсәрләре белән ни өчен кызыксынган?» — дигән сорау да туарга мөмкин. Монда, уйлавымча, төп өч сәбәп бар. Беренчедән, ул — шактый еллар мәдрәсәдә белем алган, хәлфәлеккә имтихан биреп, шаһадәтнамә, ягъни дипломга ия булган укымышлы, зыялы шәхес. Мәдрәсәдә укыган шәкертләрнең бер кызыклы шөгыле булган — хәзер фәндә «Шәкерт дәфтәре» дип аталган, үзләре өченгә кулъязма тупланмалар төзегәннәр. Бу хакта зур галимнәребез Мөхәммәт Мәһдиев, Миркасыйм Госманов әтрафлы итеп яздылар инде. Миңа да шундый берничә дәфтәр белән танышырга насыйп булды. Анда ни генә юк! Һәр дәфтәрдә халык авыз иҗаты әсәрләре — кыска әкият, хикәят, мәзәк, табышмак, мәкаль-әйтемнәрне очратырга була, шәкертләрнең шуклыклары, тел чарлаулары да җитәрлек. Икенчедән, Зариф Мөэминов 1915 елның җәендә Германия, Австрия-Венгрия империясе белән Русия арасында сугышта әсирлеккә эләгә. Татар, башкорт, чуваш милләтеннән булган тоткыннар янына венгр галимнәре килеп, алардан күп кенә әкиятләр, башка авыз иҗаты әсәрләре җыйган. Венгрлар Идел-Урал буенда яшәгән төрки һәм угыр (һунгар) халыкларын үзләренең нәсел очыннан дип саныйлар, барлык язганнарын, күз дә йоммыйча, һунгар халкының авыз иҗаты әсәрләре итеп күрсәтеп, бастырып чыгаралар. Бу хакта да матбугатта язылды — киң җәелеп тормыйм. Зариф Мөэминов шушы венгр галимнәренә әкиятләр әйтеп яздыргандыр, укымышлы кеше буларак, аларга булышып йөргәндер, дияргә фараз бар. Өченчедән, утызынчы елларда халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю активлаша. Бу эшкә билгеле татар язучылары (Хәмит Ярми, Афзал Шамов, Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәширов, Абдулла Әхмәт, Шәйхи Маннур, Эдуард Касыймов һ.б.) белән беррәттән, кулына каләм тоткан хәлдә, ул да катнашып китә. Күргәнебезчә, әлеге өлкәдә Зариф Мөэминов иң нәтиҗәле эшләүчеләрнең берсе булган. Язмаларның, автор күрсәткәнчә, 1914-1962 еллар дәвамында язылуын әйтү дә урынлы. Тагын шуны искәртәсе килә: Зариф Мөэминов үзенең язмаларында бер үк атаманы төрлечә яза. Әйтик, Русия-Рәсәй, рус-урыс, буснә-бучнә һ.б. Автор язганча калдыруны кирәк дип таптым. Автор, фикерле каләмкяр буларак, тәнкыйди зәвыкка ия булган. Язмаларны укыганда, үз чорындагы гамәлвакыйгаларга нисбәтле, кайчак йомшак, кайчак көчле тәнкыйтькә дә тап булабыз. Мондый фикерләр белән танышу да кызыклы. Мөһиме шул: автор совет, партия органнары җитешсезлекләрен туп-туры бәреп әйтә алырлык кыю зат булган. Ул чор өчен бу гади кыюлык кына да түгел… Шулай ук Зариф Мөэминовның шигырьләр язуы да билгеле. Әмма безнең кулга бары бер шигырь килеп керде… Эзләнүләрне дәвам итәргә кирәк.

Зариф Мөэминов XIX гасыр ахыры — XX йөз башы татар әдәбияты үсеше йогынтысында иҗат итә башлый. Язганнарыннан чыгып фикер йөртсәк, бигрәк тә Фатих Әмирхан, Габдулла Тукай иҗатына гашыйк булуы нык сизелә. Теманы тотып алу осталыгы, тема кысаларында шактый иркен хәрәкәт итүе, характерларны тасвирлау, алардагы сыйфатларны калку итеп сурәтләү маһирлыгы ачык тоемлана. Ул иҗатында геройларны төрле сынауларга куя, маҗаралы хәлләргә юлыктыра, әмма мантыйкка хилафлык китерми (Кайбер арттырып җибәрүләрне дә әдәби алым дип кенә кабул итәсең. Әйтик, әсир төшкәндә, дошман офицеры белән тәкәбберрәк сөйләшү күренеше, Боснийдә чакта ике йөз метрлы чыршыларны кисеп аударуларын бәян итүе), персонажларның эшгамәлләре укучыда теләктәшлек таба, ышандыра. Үз башыннан күп нәрсәләр

кичергән каләм иясе кырыс реалистик буяулар белән эш итә. Шул ук вакытта җәдитчелек идеяләре белән яхшы таныш булуы күренә, татар халкын дөнья бөтенлегенең бер өлеше итеп карый, бу халык вәкилләренең гомер кичергән иле, гореф-гадәтләре, йолалары, бай тарихы, башкалардан калышмаслык үз теле барлыгын истән чыгармый. Зариф Мөэминовның әсәрләре белән танышкач, шундый нәтиҗәгә килдем: аның «Солдат йөрәге», «Язмыш бизмәне», «Мәрьям», «Сәнәкчеләр» кебек әсәрләре рус әдәбиятында булса, сценарийлар язылып, С.Бондарчук, Г.Чухрай кебек атаклы режиссёрлар тарафыннан үз дәверен кичеп чыккан көчле рухлы кеше язмышы турында кино-эпопеялар төшерелер иде; «Кызыл обоз» кебек тирән сатирага корылган әсәрләр авторы М.Зощенко, И.Ильф, И.Петровлар белән беррәттән телгә алыныр иде. Зариф Мөэминов Н.В.Гоголь әсәрләрен яратып укыган. Үзенең иҗатында ул коточкыч кыенлыкларга юлыгып та, кешелеген саклап кала алган, җан-фәрман яшәргә тырышкан «кечкенә кеше» образын тудыруда уңышларга ирешә, бюрократ-түрәләрнең кыланмышларын зәһәр камчылый. Зариф Мөэминов – бер яктан, татар җәдитчелеге, икенче яктан, Н.В.Гоголь, М.Е.Салтыков-Щедриннардан килгән сатира белән сугарылган реализм, натураль чынбарлык мәктәбе тарафдары. З.Мөэминов, социаль-психологик юнәлештә иҗат итеп, шактый кызыклы образлар тудыра алган. Шулай ук XX йөз башы татар әдәбиятында ныклы үсеш алган романтик-лирик сурәтләү алымнарын да яхшы үзләштергән. Аның прозасында Мәхмүт Галәү әсәрләрендә күзәтелгән кырыс тормыш чынбарлыгы, физик барлыгыңны гына түгел, иманыңны да саклап калу юлында күргән газап-кичерешләр, эпиклык; Гали Рәхимдәге рус мохитенә мөрәҗәгать, шартлылык, хиссилек, тәнкыйди рух; Садри Җәләлдәге психологизм, романтик-лиризм да чагылыш тапкан; Шакир Мөхәммәдов иҗатындагы калку күренгән сатирик хикәяләү алымына да еш мөрәҗәгать иткән. Ягъни Зариф Мөэминовның әсәр тудырудагы иҗади арсеналы бай һәм кызыклы булган. Совет хакимияте урнашкач, сатирик сурәтлелектә кабатланмас образлар тудырган Фатих Әмирхан («Шәфигулла агай» хикәясе), Гомәр Толымбай («Фамилия ясаучылар» хикәясе) традицияләрен дәвам итеп, Зариф Мөэминов «Кызыл обоз» хикәясен яза. Андагы үткенлек, реалистик буяулар белән «советча фидакарь хезмәт үрнәге, рәхәт тормыш итү» мифын җимереп ташлый. Әдәби куәсе ягыннан ул замандашлары Мөхәммәт Гали, Халикъ Садри кебек өлкән солдат-әдипләрдән калышмаган.

2013 елның 15 июлендә мәгърифәтче-педагог, фольклорчы-әдип Зариф Мөэминовның тууына 120 ел тулды. Бу дата уңаеннан районыбызда яшәүче язучылар, җитәкчеләр, Октябрь төп мәктәбе коллективы, авыл халкы зиратта Зариф бабай рухына дога кылдылар, истәлекләр белән уртаклаштылар. Оныгы Илфак Мөэминов бабасының каберен тәртипкә китергән, яңа чардуган куйган. Ул көнне аңа да, бабасының истәлеген мәңгеләштерү юлындагы игелекле хезмәте өчен зур рәхмәтләр ирештерделәр. Икенче оныгы Марат Закиров Зариф Мөэминовның шигырен яттан сөйләде. Һәр елның 15 июле истәлекле көнгә әверелсен иде. Ул үзе төзегән, озак еллар мөгаллимлек иткән (бер кульъязмасында ул 35 ел укытучылык итүе хакында әйтә) Октябрь мәктәбенә аның исеме бирелсә, әйбәт булыр иде.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Киләсе саннарда сезнең игътибарга З.Мөэминовның «Мәрьям» повестен тәкъдим итәчәкбез. – Ред. ■

ХӘТЕР ЯРЫННАН ТОРЫП...

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

ТАВЫШЫ ЛА, ТАВЫШЫ...
АНЫ ТЫҢЛАГАНДА, ТАТАР БУЛЫП ТУУЫҢА ШӨКЕРАНА КЫЛАСЫҢ.
БУ ТАВЫШ — ТУГАН ТЕЛЕБЕЗНЕҢ ЯҢГЫРАШЫНА МӘХӘББӘТ УЯТКАН ТАВЫШ!
АНЫҢ ИГЕН-ИПКӘ КИТЕРЕП ӘЙТКӘН ҺӘР СҮЗЕНЕҢ МӨКӘММӘЛ ОЛЫЛЫГЫН ТАНЫП СӨЙЛӘҮ РӘВЕШЕ — ҮЗЕ БЕР СӘНГАТЬ ИДЕ. ТАТАР РАДИОСЫНДА, ДИКТОР БУЛАРАК, ҮЗ ЧОРЫНЫҢ МӘГЪНӘЛЕ СӘХИФӘСЕН ТУДЫРГАН ЭЛЬС ГАДЕЛЕВНЕ ОНЫТМАДЫКМЫ, ЗАМАНА ДИГӘН ХӘТЕР ЕЛГАСЫ ЯРЫНА САГЫНЫП КИЛГӘЛИБЕЗМЕ?

Әйе, бүгенге дикторлар (ир-атлар) күбесе Эльс Гаделев тавышы белән сөйләргә тырыша. Әмма... тавыш матурлыгы гына йокымсыраган эчке аңваемсызлыгын яшерә алмый шул. Эльс Гаделевнең сөйләү рәвеше башка иде... Аның фикер иясе икәнлеге, зыялы рухы, үз милләтенә булган мәхәббәте, саллы иңенә халык тарихын күтәрә алу кодрәте бәгырьдән күтәрелгән тавыш тембрында сизелеп тора иде.

***

Эльс Гыйният улы Гаделев 1936 елның 16 декабрендә Яшел Үзән районы Олы Шырдан авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Ул елларда шундый тәртип була: кайсы төбәк мәктәбенә укытучылар җитми, мәҗбүри рәвештә диярлек, мөгаллимнәрне яшәгән нигезеннән кубарып, шунда җибәрә торалар. Гыйният ага да, җәмәгате Гөлҗиһан белән балаларын ияртеп, Әгерҗе төбәгенә килеп төпләнә.

Шулай итеп бәрәкәтле Салагыш туфрагында үскән Эльс атлы егет, җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Минзәлә педучилищесына укырга керә. 1955 елдан — Казан дәүләт педагогия институты студенты. Югары уку йортын тәмамлаганчы ук, ул Татарстан радиокомитетында диктор булып эшли башлый һәм гаҗәеп тавышы белән Казанны гына түгел, ә бөтен татар галәмен яулап ала. Эльс Гаделевнең бәрхет тавышы, ил киңлекләренә таралып, хәерле иртә теләп уята, көннең имин буласына ышаныч тергезә, кичләрен исә, тормыш-гамәлләребезгә йомгак ясап, көнне түгәрәкли иде. Әнә шулай бай, хикмәтле тавышы белән ул җәмгыять фикерен, дәүләт фикерен, әдәбият, сәнгать яңалыкларын халыкка радио аша җиткерә барып, дикторлыкның нәкъ менә татарга хас кимәлендә, үз мәктәбен булдырды.

СССРның мәшһүр дикторы, бигрәк тә сугыш елларында үзенең гаярь кодрәтле тавышы белән күпме халыкка ихтыяр көче биргән Юрий Левитан да, Казанга килгәч, Эльс Гаделевне тыңлап, аның сөйләм сәләтенә югары бәя биргән.

Нинди илаһи тавыш... Эльс Гаделев кем икән ул, бер күреп, тотып карарга

Яшь диктор Эльс Гаделев. 1959 ел

иде үзен, дип радиокомитетка әллә кай шәһәрләрдән, хәтта ерак Сахалиннан килүчеләр дә була ул елларда.

Хәтерлим әле: үсмер чакта мин радионы йотылып тыңлый һәм ничек шулай матур, ипле итеп сөйләргә мөмкин икән, дип аптырый идем. Авылыбыздагы бер үзешчән артисттан «радио булып сөйләшә», дип көләләр иде. Гадәти кеше, алай затлы итеп сөйләшергә тиеш түгел, янәсе. Шуңа күрә мин, радиотапшырулардан соң, Эльс Гаделев дигән исемне ишетсәм дә, аны гадәти кеше дип түгел, ә радионың үзеннән яралган бер заттыр дип кабул итә идем.

Узган гасырның җитмешенче еллар башында ул Казан телестудиясендә әдәби-музыкаль тапшырулар редакциясе мөхәррире иде. Казан дәүләт университетын тәмамлагач, миңа Эльс Гаделев белән бергә язучылар оешмасының пропаганда бүлегендә эшләргә туры килде (1974). Эльс Гаделев Казанның сәнгать дөньясын, уч төбенә куеп караган кебек, яхшы белә иде. Җидешәр йөз тамашачы сыярлык залларда татар дөньясында моңарчы күрелмәгән, югары кимәлдә кичәләр уздырабыз. Сценарий язу да, оештыру да икебезнең җилкәдә. Мондый әдәби-музыкаль кичәләр бушлай үткәрелә, артистларның күңелен күрерлек кенә сәмәнне төрле юллар белән таба идек. Билгеле бер авторга багышланган — Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нурихан Фәттах, Гариф Ахунов, Әхсән Баяновларның үзләре катнашында узган кичәләр аеруча хәтердә калган. Заллар шыгрым тулы була, хәтта, халык ташкынын сыйдыра алмыйча, тышкы пыяла ишекләрнең шартлап ватылган чаклары да булды. Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова кебек ил күгендә балкыган йолдызларны да чакыра алсак, бу кичәләрнең шавы бөтен Казанны тетрәтә иде. Ә инде Рафаэль Ильясов, Хәнәви Шәйдуллин, Айдар Фәйзрахманов, Рафаэль Сәхәбиев, Вафирә Гыйззәтуллина, Зилә

Студиядә. 1960 еллар

Сөнгатуллиналар үзебезнең «кул астындагы» артистларга әверелеп беткән иде.

Безнең язучылар оешмасындагы кабинетыбыз гөр килеп тора. Фикер көрәше, бәхәс кызып, бер-береңне ишетмәслек хәлгә килгәндә, Эльс Гаделевнең салмак агышлы сабыр тавышы, барыбызны да сагайтып, тын калырга мәҗбүр итә. Ул безне әнә шулай буйсындыра алудан масаюлы ләззәт кичерми, күз карашын бер-беребезгә күчерә-күчерә, ипле генә сөйли, болгавыр әңгәмәне тыныч яр кысаларына кертә иде. Дикторлык хезмәте аны шулкадәр тәртипкә өйрәткән, күрәсең, ул, тәмәке тарта-тарта гәпләшкәндә дә, һәр авазны имгәтмичә, җөмләне камил кыскалыкка ирештереп, үтемле итеп сөйләү куәсенә ия иде.

Егәрле сөйли белү һәм сәнгатьле яза белү... Бу ике сәләт тә Эльс Гаделевкә бердәй югарылыкта бирелгән иде. Төрле редакцияләрдә эшләгәндә, аның газеталарда кызыклы язмалары дөнья күрде. Ул тәрҗемә эше белән дә шөгыльләнде. Русчадан татарчага яисә татарчадан русчага бердәй җиңеллектә тәрҗемә итә, күп вакыт язып та тормыйча, текстка карап, машинисткага әйтеп кенә тора иде.

Эльс Гаделевнең шигърияте — үзе бер ачылмаган дөнья. Үзе өчен генә дип гомере буе шигырь язды ул. Инде бик сорап, аптыраткан чакларда гына азмаз шигырьләрен матбугатка биргәләде. Әмма, тулаем бер җыентык туплап, китап итеп бастырып чыгарырга кулы җитмәде.

Бәлки ул үз иҗатына карата рәхимсез таләпчән булгандыр. Югыйсә бит шигъриятне чиксез яратканлыгы һәрчак сизелә иде. Халыкның милли рухын шигырьдә гаҗәеп тел хасияте аша чагылдыра алган ике шагыйрьне — Мөдәррис Әгъләмов белән Зөлфәтне — поэзиябезнең бәхетле ачышы дип саный иде. Рәшит һәм Роберт Әхмәтҗановларны ул бик хөрмәт итә, дустанә мөнәсәбәттә иде. Шигырьләрен яттан белә, әңгәмә сөрешенә урынын чат китереп, хикмәтле юлларын әйтеп куя, әмма үз шигырьләрен беркайчан

СССРның атаклы дикторы Юрий Левитан белән. 1960 ел

Гомәр Бәширов белән. 1982 ел

да сөйләргә базмады, үтенгән очракта да сүзне икенчегә бора, ә күзләрендә — әчке халәтенең ризасызлыгын сиздерәсе килмәгән нindидер нәүмиз моңсулык оеп кала иде сыман.

Шагыйрь кәгазьгә төшергәнче, күңеленнән сүз белән көрәшә, уйхисләрен чарлый, үз-үзен кисәтә. Менә аның «Сүз — ефәк ул» дигән шигыреннән юллар:

Каючылар, каеп тукыманы,
Курчак ясап куя кешедән.
Мең кат үлчә, шагыйрь, сүзләреңне:
Дөнья карый синең эшеңә.

Бер елны «Ялкын» журналында Разил Вәлиев аның бер туплам шигырьләрен бастырып чыгарды. Бу истәлекле вакыйганы «билгеләргә» дип җыелыштык. Табын — байларча. Тәмәкене дә «хор» белән тартабыз. Журналның куш бите тулып чыккан шигырьләрне укыштырып та алабыз. Эльс шат. Эльс канәгать. Шулчак мин, Илдар Юзеев әйтмешли, «чырайларга иман нуры йөгерткәч», тост әйттем, азагы болайрак иде:

— Ниһаять, Эльс Гаделевнең тегермәне эшли башлады.

Шул мәл Разил Вәлиев:

— Эльс тегермәнен корып бетергәндә, инешнең суы кипкән иде инде, — дип куйды. Мондый үткен кырлы юмордан мин сискәнеп киттем. Эльс Гаделев исә, авызын мул ачып, рәхәтләнеп көлде. Берәү булса үпкәләр иде. Ә ул, киресенчә, Разилнең тапкыр сүзен яратып кабул итте. Димәк, ялгызы гына калган аулак-бәхетле мизгелләрендә ул, Күк катларына төбәлеп, дога урынына шигырь кыла…

Бирешмим әле, иҗатта гомер беркайчан да соңга калмый, дигән үҗәт максаты, аның эчке рухын җылытып, һәрдаим дәртсендереп торгандыр. Әмма… вакыт берәүне дә аямый шул, ком кебек сиздермичә генә ага да ага.

Бервакыт, ул үз-үзен аклагандай итеп:

— Миндә өч Сибгат Хәкимлек шигырь бар! — дип әйтеп салды. Һәм үз сүзеннән үзе үк шаркылдап көлде. Сибгат ага белән мөнәсәбәте бик әйбәт иде аның, өлкән шагыйребез дә аңа нурлы күзләрен кысып, аталарча яратып карый, гәпләшеп утырырга җай таба иде.

— Эльс Гаделевнең аксакалыбызга багышланган шигыре дә булган икән:

Сез Күлле Киме икәнсез,
Мин үзем күлсез көймә.
Тик, зинһар, сусыз ятып бу
Коргаксыгандыр димә.

Җиңәргә дип килгән рәхимсез авыруга дучар булгач, соңгы көннәренә кадәр ул бөтен кулъязмаларын рәткә китерү, туплау белән шөгыльләнгән икән.

Инсанлы шәхес ике гомер яши. Тәүгесе — дөньялыкта, икенче гомере исә хәтергә, күңелләргә күчеп дәвам итә. Нишлисең, үкенеч-әрнүләр аша үлем дигән хәтәр хакыйкать безне бер тетрәндереп ала да, тагын тормышның иске эзенә төшеп, бер-беребезнең кадере хакында онытып гомер сөрә башлыйбыз…

Соңгы тапкыр күрешү… Разил Вәлиев, Ләис Зөлкарнәй һәм мин Эльсның хәлен белергә дип өенә барган идек (2002 ел). Сүз ара сүз чыгып, аның шигырьләрен искә алдык. Китабыңны тәки бастырмадың, дигәч:

— Башта — иртәрәк, дидем, аннары… соңладым, дип йөрдем. Шулай гомер узып китте, — диде ул.

— Синең шигырьләрең беркайчан да искерми бит! — дигәч:

— Анысын дөрес әйтәсез! — диде дә шаркылдап көлеп куйды. Үзен бәйсез тоеп, дөньяны рәхәт сискәндереп, саллы борын астыннан мул иреннәрен җәеп, тирбәлеп, Эльсча көлүнең моңсу кайтавазы иде бу…

Шул мәлдә туган ямансу тынлыкка бирешмәс өчен, мин әллә кай елларда кулъязмасын укыганда ятланып калган бер шигырен сөйли башладым. Эльс Гаделев бер кулы белән дирижёрлык иткәндәй, сүз куәсенә көч биреп, миңа кушылды.

Тегермәнгә барасым килә минем,
Бураларын кагасым килә минем,
Ап-ак онын кабасым килә минем,
Ап-ак булып каласым килә минем.

Бу шигырьдә нииндидер самими омтылыш, ак моңсулык, шагыйрьнең асылы, җан рухияте, җир йөзендәге яшәү мәгънәсе, ихлас күңеленең яктылыгы чагыладыр сыман.

Татарстан китап нәшрияты Эльс Гаделевнең китабын дөньяга чыгарырга җыена. Шагыйрь үзе исән чакта, сайлый-сайлый, бик аз гына күләмле итеп туплаган булган. Без инде аның архивындагы муллыкка чик куймадык. Сүз хикмәтенең кайчан тоныкланып, кайчан тагын җемелдәп кабынасы — Вакыт ихтыярында. Хак бәягә ул гына хөкемдар.

Булачак китапның ачылышында урын алачак сүземне Сибгат ага Хәким язып калдырган юллар белән тәмамлыйсым килә:

«Эльс Гадел шигырьләре… Шулайдыр дип уйлыйдыр идем аны, язадыр, яшереп, качырып язадыр дип. Дөрес икән. Язганы ачык, үз кичерешләре — шагыйрь булыйм дип түгел, шигырь итеп әйтергә теләүдән туган юллар. Дәгъвасыз, гөнаһсыз юллар…»

ӘДИПЛӘРЕБЕЗ МИРАСЫННАН

ЭЛЬС ГАДЕЛЕВ

МИРАС

Юл өстендә өелеп аунап ятмас —
Тирәндәрәк булыр, ул бик аз.
Бик рас килә аңа кафиясе:
Бик аз булганга да ул — Мирас.
Җир йөзендә үзебез дә бик аз —
Тик бер кавем бары дөньяга;
Сүз әйтмәгез безгә, күпсенмәгез,
Без бер бөртек мирас Ходайдан.
Аңласагыз минем телләремне,
Килегез дә үзегез карагыз,
Әнә нинди мирас калдырган бит
Мең ел элек безгә бабабыз.
Тора-тора торып сокланам мин
Искеләрнең зәвыкларына:
Сайлый белгәннәр бит урынын да
Ыстанга дип казык кагарга!
Җире дисәң, жире — түшәкмени,
Суын эчсәң, суы туйганчы!
Күкрәкләрне тутырып сулыйм дисәң,
Һавасын син кара, һавасын!
Җитмәгәнме шулар әллә тагы!
Баштан ашкан — шөкер Аллага!
Алтыны да явып тормас инде,
Алай ук син, туган, алданма.
Иң шәбе бер ныклап киерел дә
Сызган җиңең, татар баласы!
Каерып-каерып ташлар аласы да
Нигезләргә илтеп саласы.
Янсын әле күзе дошманнарның —
Балкып торсын Казан каласы!
Мең ел торган — торсын әле һаман,
Җирдә соңгы татар калганда.
Мин бәямнән төшмим,
Мирас булгач,
Иң зур бәя куям Казанга.
Мирас икәнеңне онытма, син,
Тарихның бер гәүһәр бөртеге!
Чыкырдар бер тиеп кәйлә сиңа —
Чәчрәп чыгар чаткы бөркелеп.
Бормаенча калмас әле Ходай
Нурлы йөзен татар ягына.
Без татар бит. Татар һаман татар —
Дога белән Хода сагында.

2 февраль, 2000 ел

Телестудиядә. Сулдан уңга: Рөстәм Нәбиуллин, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Әхтәм Зарипов, Рәдиф Гаташ, Луара Шакирҗанова, Марсель Галиев, Эльс Гаделев, Эдуард Сираҗетдинов, Рафаэль Сәхабиев. 1982 ел

КАЗАХ БЕЛӘН КАЗАН АРАСЫ

«Казах» белән «Казан» арасында
Аерма аз — бары бер аваз,
«Дала...» — диеп нугай сагынып җырлар,
«Казан», — диеп торыр һәр казах.

Корылдатып, «къ»ны, «Тукай», дибез,
«Кунай», дибез икән, «кунак» бул!
Дала — дәрья,
Идел — шул ук дәрья,
Дөнья атын эчерер улак ул.

Акмулланың, Тукай, Абайларның
Кафиясен, вәзен, мәкамен
Төннәр буе бикли күңеленә
«Дала», «дәрья» дигән адәмең.

Ник ил кадәр ил учына салып,
«Казах», диеп сүзем корыла.
Дала гаҗәпләнмәс, дала иркен,
Дала күңеле күпне сыйдыра.

Биредә дә, димен, бабайларның,
Түре бардыр, бардыр почмагы...
Яшел күзле татар мөгаллимен
Кайсы казах кызы кочмады..

Хәзер инде Казан малайлары
Казах якларыннан аң җыя:
Икмәген дә бирә Чирәм җире
Һәм җырын да бирә Азия.

Тарихи бер язмыш ярасына
Тапкан дуслык уртак бер дәва.
Гаҗәп: «Казах», «Казан» арасында
Аерма — тик бары бер аваз.

3 апрель, 1982 ел

ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВ БЕЛӘН ИНТЕРВЬЮ

Шәмдәлләрдә — Люкс хыялланган
Йөз кояшлар янды.
«Кеше ашаучы» камералар ул кич
Бары безне алды.
Гыйфрит күзе кебек ул объектив
Йотты, йотты мине:
Бардан ничек юк булганны белә
Телевидение.
Мин һаман да тоям кебек әле
Тезем калтырауны.
Өстәл астын күрми тамашачы —
Син сыйпадың кулны.
Киттең сөйләп, иңне иңгә куеп,
Безнең бабаларның,

Җиңә-җиңә тарих бормаларын,
Бергә барганнарын…
Кул аркамда синең уч җылысы
Һаман яна төсле,
Мин гаҗәп бер Бөек Туганлыкны
Тойдым шушы кичне.
Ә экранда — шундый без тынычлар —
Җирнең игезәкләре;
Артта Казан тора, ә бирерәк —
Кыргыз бизәкләре.

ХИКМӘТ АСЫЛТАШЫ

Канатып уй чукларымны
кара төн коесында,
Эзлим Хикмәт Асылташын
күз нурым яктысында.

Кылга элгән кылыч сыман,
баш өстемдә өметем,
Әйтсә, бары шул таш әйтер
ни буласын алгы көн.

Ярты дөнья дүнгән мәрткә,
яртысы күнгән дәрткә,
Бер мин исәр гамьнәр түгәм
парә-парә йөрәктән.

Бер чебенмен ялгыш кунган
берсенең яңагына,
Берсе чалт иттереп куя
селкенгән арт ягына.

Ярый әле эшләре зур:
сыталмыйлар тиз генә,
Яңакта да, арт якта да
кала алсу эз генә.

Язмышың ни, сагышларың…
ни боларга милләтең?!
Их тәрәзә… булсын иде
алырга бер җилләтеп!

— Үгез үлгән, арба ватык,
иртәгә нишләп булыр?
— Ут ягарбыз, ит куярбыз —
көн бигрәк тә шәп булыр!

… Коеладыр, уеладыр
күз нурларым коега,
Юк, табалмыйм Асылташны —
җанга суер коела.

ТУГАН АВЫЛНЫ САГЫНУ

Кеше баласы микән мин,
Бүре баласы микән?
Ник күңелнең иң түрендә
Һаман Салагыш икән?

Җитмәгәнме миңа Казан,
Мәскәве җитмәгәнме,
Бүреккә салмаганнар бит,
Базарга китмәгәнмен.

Урманны сагына күңел —
Хет үтер, хет ела син,
Нигездән аерма икән
Хәтта бүре баласын.

Елат әле, елыйм әле,
Сал җаныма, сал сагыш!
Гел яктырсын күз төбемдә
Күз яшедәй Салагыш.

КЫШКЫ ЭТЮД

Агачларның, бер талпынса, аккошлардай,
Әкрен генә очып китәр кебек чагы,
Ярты айның сакалыдай кыш бабайның,
Чын да кебек, чын түгел дә кебек чагы;

Сихри төннәр Зөһрә туташ кызыгырлык,
Аксыл-зәңгәр ефәкләргә уралган чак;
Салкын ширбәт, ялкын шәраб күк-һаваны
Яшь күкрәкләр илһамланып сулаган чак.

Кайчан рәттән атлап барган гүзәл ярның
Алсу йөзе була алмадан да алсу;
Аяк астындагы карлар җырлар җырлап
Озата бара кайчан, безгә теләп ак юл!

Шундый вакыт! Һәрбер кылың чыңлап торган
Татар кышы! Бармы тиңең бу дөньяда?!
Мин гашыйкмын синең тышкы ямеңә һәм
Эчеңдәге әйтелмәгән сафлыгыңа.

1963 ел ■



Сәнгать

Күңелләргә сыймый дала моңы,
Җырларга ул ничек сыйсын, ди?!

Разил Вәлиев

ГАСЫРЛАРДАН КИЛГӘН МАТУРЛЫК

ГҮЗӘЛ ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА,
сәнгать фәннәре докторы

КУМЫСНИКОВА НАИЛӘ ХАЛИТ КЫЗЫ – ТЕАТР ҺӘМ ДЕКОРАТИВ-ГАМӘЛИ СӘНГАТЬ РӘССАМЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГАН СӘНГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ (2009). РӘССАМ 1958 ЕЛНЫҢ 4 АПРЕЛЕНДӘ КАЗАН КАЛАСЫНДА ТУА. 1977 ЕЛДА КАЗАН СЫНЛЫ СӘНГАТЬ УЧИЛИЩЕСЫН, 1983 ЕЛДА СУРИКОВ ИСЕМЕНДӘГЕ МӘСКӘҮ ДӘҮЛӘТ СЫНЛЫ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНДА РӘСЕМ СӘНГАТЕ ФАКУЛЬТЕТЫНЫҢ ТЕАТРАЛЬ-ДЕКОРАЦИОН БҮЛЕГЕН ТӘМАМЛЫЙ. 1983-1996 ЕЛЛАРДА КАЗАН СЫНЛЫ СӘНГАТЬ УЧИЛИЩЕСЫНДА УКЫТА. Н.КУМЫСНИКОВА – РОССИЯ РӘССАМНАР БЕРЛЕГЕ ӘГЪЗАСЫ (1987), ТР МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ БАКЫЙ УРМАНЧЕ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ БҮЛӘГЕ ЛАУРЕАТЫ.

Наилә Кумысникова

Наилә Кумысникова – гадәти булмаган тормыш юлы үткән рәссам. Ул үзенең сайлаган юлында нык торып, ата-бабаларыбызның сәнгати мирасын яңа югарылыкта яңартырга омтыла, үткән белән бүгенге арасындагы күперне ялгый. Рәссам, үзенең балачак самимилыгын саклап, кешеләрне ихтыяр көче һәм матурлык идеалына омтылуы белән сокландыра. Иҗатының язмышына булган ышаныч Кумысниковларның гаиләсенә барып тоташа. Наиләнең әтисе – Халит Кумысников – танылган театр тәнкыйтьчесе, сәнгать белгече, татар театрын өйрәнгән иң зур галимнәрнең берсе. Әнисе – Асия Хәйруллина – үзенең бар гомерен Камал театры сәхнәсенә багышлаган Татарстанның атказанган артисткасы.

Наиләне актёрлар даирәсендә, театр диварлары кысасында үскән шәхес, дип әйтергә мөмкин. Тормышының беренче айларында ук аны костюмнар саклый торган бүлмәдә мехтан тегелгән бүреккә салып биләүлиләр. Театр хезмәткәрләре аның турында «бүректә үскән», дип шаяртталар. Наилә тәүге адымнарын да театрда ясый, ә аннары театрның иҗат төркеме белән гастрольләргә йөри. Аңа еш кына спектакльләрдә уйнарга, балалар рольләрен башкарырга туры килә.

«Кошлар» панносы. 2009 ел. 84х84. Күн, алтын җеп

«Алмагач» мендәрләр комплекты. 2011 ел.
50х50. Күн, ефәк җеп

Читекләр. 2002 ел.
Күн, көмеш җеп

Гаиләдә булган иҗади мохит аңа һөнәрен сайлаганда зур этәргеч булып тора. Шунысын да әйтергә кирәк: Наиләнең ире — Александр Федотов, мәшһүр һәм үзенчәлекле рәссам. Уллары Җәмил дә гаилә традицияләрен дәвам итә: архитектор һәм дизайнер булып эшли.

Н.Кумысникова еш кына: «Балачактан ук үземнең рәссам булачагымны белдем», — дип искә ала. Аның иң яраткан шөгыле дә бөек рәссамнарның әсәрләре төшерелгән открыткаларны, аеруча Рембранд рәсемнәрен карап хозурлану булган.

Наилә сәнгать мәктәбен тәмамлаганнан соң, укуын Казан сынлы сәнгать училищесында дәвам итә. Ул, һич икеләнмичә, театраль-декоратив бүлекне сайлый. Анда сценография буенча педагог, танылган Казан рәссамы Канәфи Нәфыйков кебек шәхесләрдән белем ала. Училищеда укыганда, әтисе куйган спектакльләрнең сәхнәсен бизәү белән шөгыльләнә. Шундый спектакльләрнең берсе — Г.Лорканың «Бернард Альбаның йорты»н бизәүне Суриков исемендәге Мәскәү сынлы сәнгать институтының театраль-декорацион бүлегенә кергәндә «ирекле» тема итеп сайлый. Эш сценография буенча иң атаклы белгечләрдән булган М.М.Курилко-Рюминга ошый һәм ул Наиләне үзенең остаханәсенә кабул итә. Һичшиксез, бу аның иң зур уңышларыннан берсе була. Институтта мәшһүр педагогларда гыйлем алу еллары Н.Кумысникованың һөнәри һәм шәхси үсешендә зур роль уйный. Студент вакытта ук ул Казанда уздырылган республика күргәзмәләрендә, Мәскәүдә узган «Ил яшьлеге» дип исемләнгән союзкүләм күргәзмәдә катнаша. Яшь сценограф яңа форма, эчтәлек белән кызыксына башлый һәм бу аның диплом эшендә — С.Прокофьевичның «Өч әфлисунга мәхәббәт» исемле спектакле декорация һәм костюмнарында чагылыш таба.

Мәскәү югары уку йортын тәмамлаганнан соң, Казанга үзенең яңа иҗат концепциясе һәм сәхнәгә үзенчәлекле карашы булган талантлы театр рәссамы кайта. Аның декорацияләре театр сәнгатенә яңа сулыш өрә. Н.Кумысникова үзенең остазыннан спектакльләрнең динамик образын оештыру сәнгатен яхшы үзләштергән була һәм һәрвакыт искелектән, декорацияне гадәти антураж дәрәҗәсенә төшерә торган статик бизәлештән качарга омтыла. Аның тарафыннан Г.Камал исемендәге академия театрында Р.Батулланың «Елантау» (1984), Әлмәт татар дәүләт драма театрында К.Тинчуринның «Җилкәнсезләр» (1984), Казанның «Экипаж» эксперименталь театрында А.С.Пушкинның «Кечкенә фаҗигаләр» (1986), Татар яшьләр театрында Д.Вәлиевның «Намус хөкеме» (1991), «Адым» Татар яшьләр театрында К.Тинчуринның «Ил» (1992), Бөгелмә рус драма театрында М.Горькийның «Соңгылар» (2001) h.б. күптөрле спектакльләргә декорацияләр һәм костюмнар эшләнә. Әмма Н.Кумысникованың җирле театрлар сценографиясенә яңалык кертүе яклау тапмый, шунлыктан ул Казан сынлы сәнгать училищесына укытырга китә. Аның укучылары арасында М. һәм О.Покалёвлар, Е.Ермолина, Н.Граханцева, Д. һәм Л.Җәләлетдиновлар, А.Исмәгыйлова, Л. һәм С.Рябининнар, Д.Нәүрүзова кебек театр рәссамнары, тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать рәссамнары, дизайнерлар бар.

Н.Кумысниковага театраль-декорацион сәнгать өчен кирәк булган киң диапазондагы иҗади таланты яңа һөнәр сайлаганда да мөһим роль уйный. Ул татар декоратив-гамәли сәнгате белән, аеруча, аның каюлы күн дип аталган мәшһүр төре белән кызыксына. Бу юл аның өчен җиңел бирелде, дип әйтергә ярамый, ә бәлки киресенчә, сценографиядән аермалы буларак, кыенлыклары бөтенләй башка төрле. Рәссам алдына иҗади мәсьәләләрне чишү бурычы гына түгел, ә ясаган әйберләрнең санын ишәйтү һәм сәнәгатьне җайга салуны оештыру проблемалары да килеп баса.

Н.Кумысникова 1990 еллар башында үзе өчен яңа булган технологияне һәм каюлы күннең орнамент телен үзләштерүнең беренче адымнарын яса-

Х.Л.Кумысников «Хәлвә». Декорация эскизы. 1992 ел.
«Адым» яшьләр театры

Х.Л.Кумысников «Хәлвә». Костюм эскизы. 1992 ел.
«Адым» яшьләр театры

ганда, бу өлкәдә рәссам С.Кузьминых һәм баш рәссам И.Гайнетдинов житәкчелегендә Арча милли аяк киемнәре фабрикасы гына эшли иде. Аларның һәрберсе дә көчләреннән килгән кадәр хәзерге каюлы күн сәнгате үсешенә өлеш кертсәләр дә, Россиядә генә түгел, ә Европа һәм хәтта дөньяның мода базарында югары сыйфатлы күн эшләнмәләренә ихтыяҗ кала бирде. Моның өчен күн эшләнмәләре формасы эстетикасына һәм модельләштерүдә яңа карашлы рәссам — стилист һәм модельер кирәк булды. Педагог Наилә Кумысникованың инновацияләргә хәзерлеге һәм сәнгати тоемлау сәләте Суриков институтындагы М.М.Курилко остаханәсе кебек һөнәри мәктәптә үк үсеш ала. Әмма бу иҗатта яңалык эзләүнең төп сәбәпләрдән берсе генә була.

Каюлы күн сәнгатен өйрәнер өчен халык иҗатының сәнгати теле, символик образлылык дәвамлылыгы кануннарына төшенергә һәм дөньяда тиңе булмаган технологияне — читек җөе серләрен үзләштерергә дә кирәк. Бу татар декоратив сәнгатенең бай мирасын, аның орнаментларын өйрәнмичә генә мөмкин гамәл түгел. Моннан тыш каюлы күннән әйберләр, аеруча милли аяк киемнәрен тегү өчен, аяк киемнәрен эшләү һәм модельләштерү техникасы белгечләре дә кирәк.

Эзләнүләр нәтиҗәсендә, рәссам-дизайнер һәм аяк киеме тегүче-модельер осталарның уртак иҗат җимешләре барлыкка килде. Бергәләп аяк киемнәре конструкциясе һәм «татар» җөе, ягъни «каю эшләре» технологиясе яңартылды. Ефәк җепләрне файдалану һәм җөйләрне зурайту фикерләре туа, шуның белән төп игътибар бизәкнең читенә, аның рәсеменә юнәлтелә. Н.Кумысникованың беренче иҗат җимеше — «Ел фасыллары» дивар панносында сәнгати эффект орнаментның җәелгән композициясе ярдәмендә тудырылуы очраклы гына түгел. Дивар панносына орнаменталь иҗат кануннары буенча стильләшкән сюжетлы сурәтләр кертелә.

Н.Кумысникованың, рәссам-практик буларак, һөнәри уңышлары — яңача фикерләве һәм халык традицияләрен ирекле файдалануы нәтиҗәсе. Иҗади фикерләрен гамәлгә ашырыр өчен, Казан Кремлендә рәссамның «ТР Президентының мәдәниятә ярдәм итү фонды» карамагында «Болгари» исемле иҗат остаханәсен оештыруы һөнәри үсешендә шактый зур сикереш була. Шулай итеп, узган гасырның 90 нчы еллары башында ук туктап калган каюлы күн эшләнмәләре сәнгатенә яңа сулыш өрелә.

Җитештерүне җайга салу юктан башланып китте, дип әйтергә була. Рәссамның үзалдына куйган төп максаты — алга таба санын ишәйтү өчен коллекцияләр төзү. Уникаль һәм серияле эшләнмәләрнең үрнәкләре тудырыла. Алар арасында ир-ат һәм хатын-кыз читекләре, кием төрләре (камзуллар, курткалар, жилетлар), хатын-кыз сумкалары, идән һәм дивар мендәрләре бар. Остаханәдә ясалган әйберләргә зур ихтыяҗ туа, алар билгеле бер стильдә була һәм миллли үзенчәлекне саклый, өс киемнәрендә этник юнәлешнең үсешенә бәйле мода таләпләренә дә җавап бирә. Остаханәнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә, җәмгыятьтә каюлы күннән тегелгән әйберләрне көнкүрештә һәм костюмнар бизәлешендә куллануда кискен үзгәрешләр күзәтелә, рәссамнарның гамәли иҗатында да татар сәнгатенең бу төрен үстерүгә көчле импульс бирелә. Кызганыч ки, Н.Кумысникова остаханәдә аз — нибары өч ел чамасы эшли. Сәбәбе — остаханә эшчәнлегендә хәлиткеч фактор булып коммерция тора. Бу иҗат ителгән үрнәкләрнең сәнгатилек сыйфатын иң алга куйган талантлы шәхеснең омтылышларына каршы килү була. Шулай да остаханәдә эшләү тәҗрибәсе азлап җитештерү идеясенең уңышын күрсәтә, ә барыннан да бигрәк аның нигезенә сүнеп барган халык һөнәрчелегенең яңаруы салына.

Н.Кумысникованың иҗади фикерләренең гамәлгә ашырылуы яңа шартларда дәвам итә. 1997 елдан ул, заказларны башкарырга тегүче-осталарны җәлеп итеп, мөстәкыйль эшли.

Бүген Н.Кумысникова — каюлы күн тармагында иҗат итүче төп рәссамнарның берсе. Әсәрләре белгечләр тарафыннан югары бәяләнә, Россия һәм халыкара күргәзмәләрдә уңыш казана. Алар үзләренең оригинальлеге, нәфислеге, югары дәрәҗәдә башкарылуы белән аерылып тора. Н.Кумысникованың һөнәри горурлыгы — хәзерге вакытта күп кенә рәссамнар уңышлы файдаланган эре җөй формасын тәкъдим итүдә чагыла. Аның тарафыннан җөйсез бизәкле түфлиләрнең, шулай ук «тарттырылган» ир-ат читекләренең борынгы технологияләре торгызыла. Ул күптөсле җөйне — бизәлештә мөстәкыйль элемент ролен уңышлы башкара торган «миләш төнәтмәсен» («рябиновка») еш файдалана.

Н.Кумысникова төсләр композициясендә каюлы күннең яңарыш дәвере — XVIII гасыр азагы — XIX йөз башы традицияләренә мөрәҗәгать итә, монохром төсләр тезмәсеннән файдалана, аларны ата-бабаларыбыз кулланган үсемлек буяулары төсмеренә якынайта. Колориты буенча охшаш яки контраст композицияләр дә аның өчен ят түгел.

Ул, каюлы күн традицияләрен нәфис хатын-кыз түфлиләрендә, еш кына сумкаларда, жилетларда, каешларда һәм башка аксессуарларда файдаланып, хәзерге милли стильдән аерылып торган эшләнмәләр иҗат итә. 2005 елда

Н.Кумысникова тарафыннан саны буенча моңарчы күрелмәгән гамәл кылына: Казанның меңьеллыгына ачылган күн галантерея фабрикасында, киләчәктә күпләп җитештерү өчен, 330 төрле хатын-кыз сумкасының сувенир моделе эшләнә.

Н.Кумысникова һәр иҗат җимешенә еш кына эксперимент ясап яки борынгы алымнарны заманчалаштырып, иҗади идеяләрен кертә. Паннолар сериясе һәм диван мендәрләрендә (2010 ел) ул татарның күпертеп чигү бизәгеннән файдалана, беренче мәртәбә аны мозаика алымнары белән стильләштерә һәм мондый чигүләр өчен хас булган бертөсле фонны куллана. Эшләнмәләрнең күп кенә үрнәкләрендә мозаика янәшәсендә алтын һәм көмеш белән чигелгән бизәк кулланыла яки бизәк «Казан җөе» имитациясендә тегелә. Авангардизм да сирәк түгел — абстракт композицияләрне, контраст төсләрне файдалана.

Н.Кумысникова иҗатында аерым мөстәкыйль юнәлеш булып интерьерлар бизәлешендә файдаланыла торган дивар панноларын тудыру тора. Алар ассоциатив-символик яки сюжетлы-тематик әсәрләр цикллары төркеменә берләшә, тасвири характердагы мотивлар, символлар белән тулылана. Шундый панноларның берникадәр зуррагы ТР Мәдәният министрлыгының вестибюлен бизи. Ул төп керү ишегенә каршы булган түрдәге диварга урнаштырылган, күз карашын үзенең нәфис орнаментлы бизәкләре белән җәлеп итеп тора. Панноның композициясе буенча симметрик мотивлар, аларның традицион символикасы: кояшка каршы барган, ике якка канатларын җәеп җибәргән кош, Тормыш агачы нигезенә урнашкан парлы бәхет кошлары, лалә чәчәге мотивы һ.б. халыкның галәмне аңлау фәлсәфәсен гәүдәләндерә. Башка панноларның композицияләре татар фольклоры сюжетына — мифларга, риваятьләргә нигезләнә. Алар буыннан буынга татар халкының болгар дәвереннән үк килгән орнамент мирасын үстерә. Мәсәлән, «Аккошлар» панносында болгарлардагы бер металл көзгенең композициясе файдаланылган. Символикасы мифологиягә нигезләнгән. Дивари панноларның сайлап алынган формаларына (үлчәмнәре) туры килеп торган каймадан файдалану, саклау шартлары югары булу җәмәгать һәм шәхси интерьерларда күз явын алырлык итә.

Н.Кумысникова әсәрләре күп кенә сәнгать сөючеләрнең горурлыгы булды. Ул оештырган күргәзмәләргә президентлар, күп дәүләтләрнең югары дәрәҗәдәге җитәкчеләре, коллекционерлар, мәшһүр артистлар, сәнгать эшлеклеләре һ.б. килделәр. Аның иҗади таланты ТР Дәүләт Җыр һәм бию ансамбле, «Салават» театр студиясе концерт сәхнәсен һәм артистлар костюмнарын бизәгәндә, XVIII-XIX гасыр татар чигүле аяк киемнәрен, урта гасырлардагы болгар костюмын, татар сугышчысының кирәк-яракларын тарихи җәһәттән фәнни реконструкцияләгәндә һ.б. дәүләт һәм шәхси заказларда чагылыш тапты. Хезмәтләрен ТР Милли музеенда, ТР Сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли-мәдәни үзәгендә, «Казан Кремле» музей-тыюлыгында, Мәскәүдәге «Мәрҗани» фондында һ.б. коллекцияләрдә күрергә мөмкин.

Н.Кумысникованың иҗади куәте үзенең киң масштаблы булуы белән таң калдыра, аның тарафыннан шундый күп әсәрләр иҗат ителде ки, хәтта аларның исәп-хисабы да мәгълүм түгел. Н.Кумысникова каюлы күн сәнгатен яңа югарылыкка күтәрде, формаларын камилләштереп, аңа заманча төсмерләр биреп кенә калмады, ә гасырлардан килгән традицияләрне дәвам итеп һәм үстереп, татар милли стилен тудырды. Боларда аның күпкырлы таланты чагылыш таба, милләте алдында рәссам буларак иң изге бурычы гамәлгә аша.

Русчадан ***Ленар Гобәйдуллин*** *тәрҗемәсе* ■

ФӘРИТ ЯРУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

УЛ – ЯРУЛЛИННАР ЙОЛДЫЗЛЫГЫННАН

РАШАТ НИЗАМИ,
прозаик, шагыйрь, публицист

Туплар сөйләшкәндә, музалар тик тора.
Мәкаль

ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ КҮРЕНЕКЛЕ КОМПОЗИТОРЫ ФӘРИТ ЯРУЛЛИН 27 ЯШЕНДӘ (ТУКАЙ ЯШЕ!) БЕРЕНЧЕ ТАТАР БАЛЕТЫ «ШҮРӘЛЕ»НЕ ЯЗА. ХӘЕР, 27 ЯШЬЛЕК ТУКАЙ ҺӘМ ЛЕРМОНТОВ ТА ШУНДЫЙ КЫСКА ГОМЕР ЭЧЕНДӘ ӘЙТЕР СҮЗЛӘРЕН ӘЙТЕП ӨЛГЕРӘ. МУЗЫКА – ШУЛАЙ УК ӘЙТЕР СҮЗ УЛ.

Беренче татар балеты...

Бу тормышта «беренче» сүзенә ифрат олы мәгънә салынган. Беренче китап. Беренче орден. Беренче мәхәббәт һ.б. Муса Җәлил исемендәге Татар Дәүләт опера һәм балет театры, гадәттә, үзенең сезонын һәр елны диярлек «Шүрәле» балеты белән башлап җибәрә. Юк, мин моны модага иярү, инде «урыслашып» бетә язган театрыбызга милли төсмер бирергә тырышу гына димәс идем. Асылда бу – беренче татар балетын иҗат иткән Фәрит Яруллинның рухына, иҗатына, талантына олуг хөрмәт билгесе дә. Чөнки «Шүрәле» моңнары – милли музыкабызның визит карточкасы да ул.

Фәрит Яруллинның гомере һәм яшәеше бик тә ачы, фаҗигале. Балет партитурасының карасы да кибеп җитмәстән, 1941 елда Ватан сугышы башлану белән, аны сугышка алалар. Композиторның пианино телләре өстендә талпынасы бармаклары автоматка, утка, пычакка таянмаска тиеш иде ләбаса. Ни өчен соң татарның яшь һәм талантлы композиторын саклап кала алмаганнар, күрәләтә сугышка җибәргәннәр? Дөресен әйткәндә, шундый туры һәм үткен сорауга җавап бирү хәзер инде бер дә җиңел түгел. Чөнки күп сулар аккан, байтак заманалар узган. Кемне – кешеләрнеме, әллә системаны, сугышның үзен гаепләргәме?

Фәрит Яруллин үзенең тирән музыкасында дөреслек турында сөйләде, эстетик хакыйкатьләр ачу белән бергә, кара көчләрнең сугыш белән ил өстенә киләсен алдан ук сиздереп-кисәтеп куйды шикелле. Игътибар белән тыңлап карагыз: балеттагы ике көчнең көрәше өлешендә, чыннан да, сугышны сиземләү һәм кисәтү төсмерләре (ноталары) ярылып ята! Кыскасы, бу татар егетенең бөтен барлыгы, барлык

күзәнәкләре моң һәм дөреслек тойгысы белән сугарылган иде. Аның Казанда да, Мәскәүдә дә, аннары инде фронт сызыгының кайнар көннәрендә дә ялгызлыкка омтылуы, һаман иҗатка ашкынуы бик тә табигый нәрсә. Ял һәм привал вакытларында ул блиндаж өчен киселгән агач төпләрендә (анда — җыр пластинкасындагы эзләрне хәтерләткән боҗралар…) бармакларын биетеп, «көй» чыгара… Менә шуларның барысын да күз алдына китергәннән соң, Ф.Яруллин музыкасы безгә тагын да ныграк тәэсир итә, кысып-кысып йөрәкне авырттыра.

Алгарак китеп булса да, шуны әйтик: сугыштан соң «Шүрәле» балеты Европаның барлык илләрен диярлек гизеп чыга, хәтта Канада урманнарын яктырта, музыкага бик сизгер япон утрауларын да сискәндерә.

Болар — бик саран һәм өстән-өстән генә әйтелгән фактлар. Язмышындагы төрле сәхифәләр ошбу язмада алга таба да өстәлә торыр.

Кем соң ул Фәрит Яруллин? Нинди кеше булган? Нинди уйлар, иҗади хисләр белән яшәгән, милли сәнгатебез күгендә нинди эз калдырган? Аның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнгән кеше буларак, мин бу сорауларга җавап бирә алам. Әмма, җөрьәт итеп, шуны әйтәсем килә: милләттәшләребезнең күбесе Ф.Яруллинның биографиясеннән, язмышыннан ныклап хәбәрдар түгел. Композиторның кыска гына гомере, әйткәнебезчә, фаҗига белән уратып алынган. Төптәнрәк уйлап карасак, әлеге фаҗигадә халкыбыз язмышы да шактый ачык ярылып ята. Үткәнгә карап гыйбрәт алырлык нәрсәләр күп.

Фәрит Яруллин кебек яшь талантны, һичшиксез, саклап калырга кирәк булган ул чакта! Сәнгать һәм иҗат әһелләрен саклау буенча обком тарафыннан «Бронь» исемлеге булдырылган лабаса. Хәтта опера һәм балет театры составындагы гап-гади музыкантларны, кордебалеттагы биючеләрне, массовкада катнашучыларның да күбесен бронь белән ышыклаганнар. Ә менә ни өчен соң әлеге исемлеккә газиз халкына беренче татар балетын бүләк иткән Ф.Яруллин гына «кермичә» калган?

Кызганыч, бу хакта бернинди рәсми хатлар, документлар сакланып калмаган. Татарстан обкомының тиешле өстәленә бронь исемлегенең кайсы оешмадан килеп төшкәнлеге сер түгел. Турысын әйтик: телибез-теләмибезме, әлеге мәсьәләдәге җаваплылык Татарстан композиторлар союзы җитәкчелегенә дә төшә. Ул елларда союз җитәкчелегенең иң биек пирамида-



Яңа Тухиня авылы тирәсендә барган сугышның якынча карта-схемасы (полкташы подполковник Михаил Тихненко төзегән)

Ф.Яруллин Ульяновск пехота училищесында
(утырган, уңнан беренче)

сында кайсы түрәләрнең утырганы яхшы мәгълүм. Истәлекчеләр телдән сөйләвенчә, Фәритне яки «онытканнар», яки исемлектән төшереп калдырганнар, яки аңа дигән броньны кулына вакытында биреп өлгермәгәннәр... Ул, янәсе, сугышка үз теләге белән киткән дигән фараз да бар. Соңгысы ышандырмый. Хатыны Галина-Сачек йөрәге астында туачак нарасыен йөрткән вакытта, ярь-яшь гаиләсен, ай-һай, ансат кына ташлап китәр иде микән ул? Бу буталчыклыкта татарны сөймәс рус түрәләренең дә роль уйнавы бик ихтимал. Ләкин факт: хәрби комиссариаттан Ф.Яруллинга чакыру кәгазе (повестка) килеп төшә...

Мәскәү үзенең талантларын саклый белгән әнә. Бөек Ватан сугышының беренче айларында ук Татарстанга — Казан, Чистай, Алабуга, Печищига — Мәскәү, Ленинград һәм Украина якларыннан 200ләп әдәбият һәм сәнгать әһеле эвакуацияләнә. Сөлгебуе исемлектә безгә бик таныш исемнәр дә очрый: П.Антокольский, В.Бонч-Бруевич, А.Фадеев, В.Лебедев-Кумач, Я.Купала, С.Маршак, Л.Ошанин... (Аларның безнең төбәкләрдә яшәгән чоры турында, горурланып, байтак мәкалә һәм китаплар язылды. Моны безнең татар гына шулай эшли ала.) Бу данлы әдипләрнең исеменә күләгә төшерергә теләмим. Әмма... мондый гуманистик «кагыйдә» безнең татар мәдәниятенә кагылмаган. Татарстанның әдәбият-сәнгать әһелләрен поездлар, киресенчә, Көнбатышка, фронтка — сугышның иң кайнар нокталарына ташый. Алар арасында инде зур танылу алып өлгергән Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Сибгат Хәким, Габдрахман Әпсәләмов, Нәби Дәүли, Салих Баттал һәм тагын күп кенә композитор, рәссам, артистлар бар. (Әлеге исемлек ифрат озын, керми калганнарның рухы мине кичерә күрсен!..)

Менә шундый парадокс: берәүләр ут эченә кергән, икенчеләр исә «бронь» дигән билет ярдәмендә ут-ялкыннан ераклашкан.

Хәер, биредә гаҗәпләнер нәрсә юк. Бу — совет чынбарлыгы, империянең шовинистик асылын оста яшерә белгән сәясәт; аны азчылык һәм яулап алынган халыкларга кимсетеп-түбәнсетеп караган большевистик хакимият тудырган иде.

Инде шунысын да искә төшерик: татарлар әлеге дәһшәтле сугышта сынатмады, батырлык үрнәкләре күрсәтте. Сугышта турыдан-туры катнашкан данлы маршал һәм генералларның бәясен искә төшерү дә җитә. Әйе, хакимият һәм

өстәгеләр татарны кирәккәндә сыйлап, мактап, зур-авыр көрәшләргә һәрчак рухландырып торган. Немец амбразурасын беренчеләрдән булып күкрәге белән каплаган Александр Матросов та чын рус түгел (интернат тәрбиясендә үскән бу ятимнең чын исем-фамилиясе — Шакирҗан Мөхәммәтҗанов булып чыкты). Рейхстагка Җиңү байрагын да иң беренче булып татар кешесе — Гази Заһитов кадый! Беренчесенең чынлыкта татар егете икәнлеген, икенчесенең тәүге байракчы булуын дәүләт серенә тиң рәвештә «яшерделәр», татар масаеп-узынып китмәсен, янәсе. Менә сиңа чын мөнәсәбәт, менә сиңа медальнең «икенче ягы!» Мәскәү каланчасыннан бу эшчән-батыр халыкка карата астыртын мөнәсәбәт беркайчан да үзәрмәгән: ирек бирсәң, алар гаҗәп дәрәҗәдә яшәүчән, тамырланучан, менә шуңа күрә алар бетәргә, сытылырга, сан ягыннан кимергә тиешләр. Кырым татарларын Сталин, сыныкка сылтау табып, хәтта туган җирләреннән үк куып чыгарды, токымын корытырга теләде. Янәсе, бу халыкның кайбер вәкилләре немецлар ягына авышкан икән. Йә Хода! Әгәр мондый мантыйк белән барсак, рус халкының да бер өлешен туган җирләреннән сөрергә кирәк булган лабаса... Ни өчен дигәндә, Сталинның бик яраткан генералы Власов (чиста рус) армиясе-ние белән Гитлер ягына күчмәдемени?! Бу — тарихи факт, Ватан сугышындагы иң кара сәхифәләрнең берсе.

***

Ә хәзер, әйдәгез, композиторның биографиясен саран штрихлар белән булса да, күздән кичерик. Фәрит Заһидулла улы Яруллин 1914 елның 1 гыйнварында Казан шәһәрендә туа. Әтисе — халык музыканты, атаклы «Тукай маршы»ның авторы. Икенче улы Мирсәет Яруллин да — композитор, музыка дөньясында танылган шәхес.

Фәрит кечкенәдән диярлек әтисеннән оста итеп пианинода уйнарга өйрәнә! Казан музыка техникумын тәмамлый. 1936 елда ул күп кенә талантлы яшь музыкантлар белән бергә Мәскәүгә җибәрелә. Башкаланың атаклы консерваториясендә укый.

Мәскәүдә укыган елларында Ф.Яруллин төрле жанрларда бик күп әсәрләр — симфония, соната, скрипка өчен пьеса, Пушкин шигырьләренә романслар иҗат итә. Хәтта опера да яза башлый... Кыскасы, күренә ки, ул үзенең «Шүрәле» балетына төпле белем, ныклы профессиональ әзерлек белән килә.

...Муса Җәлил исемендәге Татар Дәүләт опера һәм балет театры, гадәттә, үзенең сезонын «Шүрәле» балеты белән башлап җибәрә, дидек.

Менә күгелҗем-яшькелт декорация. Рампа утлары. Оркестр елый, ярсый, ыңгыраша да төсле. Музыка давылы эчендә әле скрипкалар өстенлек итә, әле кларнетлар һәм барабан авазы кисәтүле оран булып дөньяга чаң кага. Ак һәм кара. Мәхәббәт һәм нәфрәт. Менә шушы ике көчнең тартышы, кискен бәхәс-көрәше тылсымлы музыкага әверелгән дә яхшылыкның дөньяны коткарырга тиешлеген раслап бәргәләнә.

Ф.Яруллин — тарихта күп михнәтләр кичкән татар халкының моңлы бер вәкиле, дәвамчысы, сәнгати оранчысы. Аның иҗади почеркы кабатланмас төстә һәм үзенчәлекле: коеп куйган мелодист, көчле оркестровка һәм төрле ритмнарның фантастик алымнарын таба белгән. Ул татар музыкасында үзенә генә хас өслүпне калыплаштырды. Күтәрелгән темалар масштаблы, халыкчан, һәр тыңлаучыга диярлек аңлаешлы. Балетның төп геройлары — гаделлек сөйгән батыр егет Былтыр; шаян һәм шул ук вакытта мәкерле, шомлы зат Шүрәле; Сөембикә — саф мәхәббәт өчен яратылган гүзәл һәм эчкерсез зат. Бер-берсенә охшамаган бу затларга психологик характеристика

Басканнар (сулдан уңга): Нәҗип Җиһанов, Фәрит Яруллин, балет либреттосы авторы Әхмәт Фәйзи. Утырган – Генрих Литинский

бирү, аларның күңел хәрәкәтен тулырак җанландыру өчен, композитор музыка һәм оркестр чараларының барлык арсеналын уңышлы файдаланган.

...1941 елның август аенда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре үткәреләчәк. Аның репертуарына «Шүрәле» балеты да кертелгән. Әмма... булачак алкышлар урынына — сугыш гөрелтесе!

Көчле, мәкерле, свастикалы кара ташкын декада язмышын гына түгел, СССР дигән океандай зур бер илнең тормышын да йөзтүбән әйләндереп сала. Тарих сәхнәсенә күтәрелгән канлы симфония, туплар, снаряд һәм бомбалар шартлавы Фәритнең иҗади планнарын да челпәрәмә китереп ташлый!

Ульяновск пехота училищесындагы дүрт айлык курслардан соң, хәрби эшелон иптәшләре белән бергә кече лейтенант Фәрит Яруллинны да турыдан-туры фронтка, ут эченә алып китә. Ул беренче сугышларда ук каты яралана һәм Куйбышев шәһәрендәге госпитальгә барып эләгә. Без моны хатыны Галинага язган хатыннан да укып беләбез: «Хәзер инде хәлем әйбәтләнде. Авырганның тәэсире кулымда гына калды. Сул як җилкәм борчый».

Шушы урында тукталып, композитор тормышындагы өч фаҗигане аерым-аерым әйтеп узу сорала шикелле.

Сугышка китеп баруы бер фаҗига (язмыш хатасы) булса, икенчесе — Ф.Яруллинның Мәскәү чорындагы иҗади архивы юкка чыга. Мәскәүдә укып йөргән чагында, ул Нина Ивановна Минкевич дигән марҗа ханым гаиләсендә фатир почмагы алып яши. Сугыштан соң бу хатын, ордер алып, икенче бер йортка күченеп китә. Болар кирәкле китаплардыр дип, Фәрит Яруллинның киштәсеннән аның култамгасы салынган Чайковский, Бородин, Римский-Корсаков басмаларын үзе белән ала. Картайган карчык нәрсә аңласын икән: Яруллинның ноталар белән чуарланган өем-өем кулъязмаларын, чүп-чарга санаптыр инде, шунда калдырып китә...

Ярымподвал хәлендәге әлеге фатирга яңа хуҗалар күченеп килә... Энесе Мирсәет Яруллин, абыйсының эзләреннән барып, Нина Минкевич дигән карчыкны көчкә эзләп таба. Хәл-әхвәл сорашканнан соң, аның фатирына юнәләләр һәм бик тә кызганыч хәлгә юлыгалар: эчүчелек белән дус булган рус гаиләсе, шешенке-мескен йөзләр, өметсезлек дәрьясы... Тегеләр болай дип сөйләп күрсәтә: без бит ул кәгазьләрнең ни икәнен белмәдек — аңламадык, кирәксә — өстәлгә җәйдек, кирәксә — ботинка чистарттык, безгә хәйранга җитте ул... Әйтүләренә караганда, бер өлешен хәтта чүплеккә дә чыгарып ташлаганнар икән!

Менә шундый хәлләр.

Өченче фаҗига. Мәскәү консерваториясе укытучысы Генрих Литинский, 1942 елны Куйбышев шәһәрендә очрашканнан соң (ул — эвакуациядә), Фәрит Яруллинны хәрби дирижёрлык факультетына күчерү хакында югары командованиегә үтенеч хаты яза. Юллар озын, юллар урау. Бюрокра-

тик тукталышлар да булмый калмагандыр. Рөхсәт хаты килеп җиткәндә, Фәритне инде яңадан фронт сызыгы — Курск Дугасына чакыртып алган булалар. Шулай итеп, профессор Литинскийның: «Ничек сине фронтка җибәрмичә алып калмады композиторлар союзы? Син бит музыкаң белән Кызыл Армияне рухландырып, дошманны җиңәргә ярдәм итәрлек көчле композитор!» — дигән сүзләре чынга ашмый кала, җилгә оча.

Боларга аңлатма бирүнең хаҗәте юк хәзер. Улларының ачы язмышыннан чыгып, «Бөек» дип аталган Ватан сугышына яңача караш ташларга да вакыт җитте. Сугышка ревизия ясыйсы килми, әлбәттә, әмма дөреслекнең күзенә карап әйтәсе килә: ике ил арасындагы сугыш — кан кою, вәхшилек бәрелеше генә түгел, халкыбызның талантлы һәм эшчән улларын үтерү мәйданы да булды. Без элегрәк, 200дән артык Геройларыбыз бар, дип мактанырга, горурланырга ярата идек. Әфганстанга бәреп керүдәге кебек, бу очракта да ялган интернационализм барлыгын күрү кыен түгел. Нәрсә, сугыш җәһәннәменә китеп барган татар кавемнәре бу сугышларда татар халкы мәнфәгатьләрен яклап көрәштеме әллә? Юк, заманында үзебезне яулап алган «өлкән туган»ның Камчаткадан алып Брестка кадәр җәелгән империя чикләрен якларга дип ут эченә китеп бардылар. Күпләр, бик күпләр әйләнеп кайтмады, пушка ите буларак, Европа җирләрендә, чит каберләрдә түшкәтүшкә булып түшәлделәр. Боларны исәпкә алучы бармы хәзер?

Кызганыч, Мәскәү сәясәтчеләрендә безне — татарны аңлаучы күренми дә, табылмый да. Киресенчә, суверенитетны (кәгазьдәге диярлек) тумас борын имгәтеп ташладылар, инде хәзер туган телебезне һәм татар мәктәпләрен каты кысрыклау башланды! Бер генә илдә дә мондый шовинизм юк. Өстебезгә рәхмәтләр әйтәсе урында, куркыныч килә. Без әле һаман да солдатлар түгел,

Майя Плисецкая – «Шүрәле» балетында Сөембикә. 1955 ел. Чыңгыз Әхмәрев эше

коллар хәлендәрәк. Онытмыйк, Тукаебыз безне инде XX гасыр башында ук: «Тотса мәскәүләр якаң...» — дип кисәткән иде.

1941 елда минем (булачак) әтине дә сугышка алалар. Ярты Европаны диярлек гизеп, өч елдан соң сыңар кул белән авылына кайтып төшә ул. Кайта-кайта уйлаганым бар: язмыш аны шәҗәрә агачыбызны, үзенең туачак балаларын саклау өчен исән калдырган, ахрысы. Ә менә теге «каракош» безнең нәселне һаман сагалап торган икән — Җәүдәт исемле бертуган абыем хәрби очучы иде, вертолёт сынаганда, Россия күгендә янып үлде. Милләт файдасына булса, мин аны бу кадәр үк кызганмас та идем.

***

Сугыш елларында тылдагыларның гаиләсенә бик тә саран, бик тә хәтәр сүзләр язылган уч төбедәй хатлар килә башлый: «Яраланды», «Һәлак булды», «Билгесез югалды».

Взвод командиры, кече лейтенант Фәрит Яруллиннан да ике елдан соң хат-хәбәрләр бөтенләй өзелә. Ул кайчан, кайда, ничек һәлак булган — бо-

Фәрит Яруллин кабере каршында (сулдан уңга): Мирсәет Яруллин, Рафаэль Билалов, Рашат Низамиев, композиторның кызы Наилә Яруллина, Марат Әхмәтов, сугыш ветераны (?). 1985 ел. Белоруссия

лар хакында бернинди дә мәгълүматлар табылмый. Халык композиторы, әтисе Заһидулла Яруллинга «Хәбәрсез югалды», дигән кара пичәтле хат — шуның белән вәссәлам! 40 елдан соң гына, ниһаять, аның соңгы сугыш юллары ачыкланды һәм кабере табылды! Смоленск һәм Витебск юнәлешендәге канлы бәрелешләрдән соң, Белоруссиянең Яңа Тухиня авылын азат иткәндә, дошман ядрәсе композиторның гомерен өзә*...

Фәрит Яруллин үзенең сугышчылары белән Яңа Тухиня авылы зиратына килеп урнаша. 1943 ел, 17 октябрь көне бу. Алда — Днепр, аның теге ягында дошман блиндажлары шәйләнә. Безнең артиллерия иң элек ярты сәгать буена дошман сафларына ут яудыра. Каракаршы атышлар бер якка да өстенлек бирми. Менә шундый атышларның берсендә татар егете Фәритнең каны Белоруссия туфрагына, күгелҗем яфраклар өстенә тама. Тукта, вакыт! Фашизм көчләп таккан сугыш һәм яшь талантны саклауда битарафлык күрсәтүчеләр татар Моцартын үтерде. Бу урында үзе дә немец фашистларына каршы көрәшкән атаклы хәрби очучы һәм язучы Сент-Экзюпери сүзләре искә төшә: «Мине бернәрсә газаплый, бәлки һәр кешедә Моцарт үтерелгәндер...»

Аның исән калган полкташ дуслары, авыл кешеләренең сүзләренә нигезләнеп, сугышчы-композиторның үлемен якынча күзалларга мөмкин.

...Яңгырлы салкынча көз. Зираттагы карт агачлар шәрәләнеп калган. Алар, сугышчылар киләсен белгәндәй, яфракларын келәм итеп җиргә түшәгән. Зират — үлем белән яшәү мәгънәсе (нокталары) кисешкән, адәмнәр үзләренә мәңгелек йокы сорап килгән изге урын. Ләкин сугыш зәхмәте хәтта үлгәннәргә дә тынычлык бирми, каберләрнең астын-өскә китерердәй кодрәт белән снарядлар шартлата... Выжылдап очкан ядрәләр усак кәүсәләренең яшькелт кайрысын тунап-сыдырып китә... Кинәт күкрәкне утлы күмер көйдереп алгандай итә! Йөрәккә кадәр яндырып-яндырып төшә дә тәнне сәер бер хәлсезлек биләп ала. Дөнья тын, атыш тавышлары каядыр офык аръягына төшеп баткан... Күктән соңгы тапкыр газаплы музыка, билгесез әсәрнең аккордлары салмак кына ишелеп төшә дә, аксыл томанга әверелеп, бар дөньяны каплый...

Нигә икән кабереӊ дә, йөрәгеӊ дә әллә кайда еракларда ятып калды синеӊ, маэстро?!.

*Бу хакта тулырак язучы Рашат Низамиевның «Ут һәм җыр» (Казан: Татар.кит.нәшр., 2000) исемле роман-хроникасыннан укып таныша аласыз. — Ред.



Беренче багана, астан икенче – Ф.Яруллин

***

…1985 ел, 1 июль иртәсе.

Татарстан делегациясе Мәскәү-Минск магистраленең 467 нче чакрымында басып тора. Рыленки дип аталган туганнар каберлеге, мемориаль комплекс. Тирәяк район һәм авылларда калкып торган каберләрне ачу-күчерү нәтиҗәсендә, биредә батырларча сугышкан һәм һәлак булган 10 мең сугышчының җәсәде үзенә төяк тапкан. Шундый мәрмәр плитәләрнең берсенә Фәрит Яруллин исеме дә уеп язылган. Кабере өстенә бер уч Татарстан туфрагы салабыз. Энесе Мирсәет Яруллин, композиторның Кече Сөндәге музеена дип, кабердән шулай ук бер уч туфрак ала.

Рыленкидагы кабер өстендә — скрипка моңнары… Танылган скрипкачыбыз Марат Әхмәтов башкаруында «Шүрәле» балетыннан анданте агыла. Рәт-рәт тезелгән 170 матәм плитәсе — гүя партитура битләре. Шунда уеп язылган хәрефләр, исемнәр нота билгеләре кебек. Скрипка елый, өзгәләнә, исәннәр белән үлгәннәр рухын бергә китереп ялгый…

1992 елның җәе: Фәрит Яруллинның туган ягында — Кече Сон авылында (Мамадыш районы) — аңа багышланган музей ачылган иде. Ут һәм тәкъдир композиторны һаман эзәрлекләп килә. Каравылчының хатасы һәм гамьсезлеге аркасында (бу хакта минем архивымда бер хат саклана, гаеплеләрнең исемен атап тормыйм), кичке якларда янгын чыга! Хикмәти Хода: кашагалар, тәрәзә пәрдәләре, бүрәнә арасындагы мүк кисәкләре идәнгә янып төшкән, ә менә бер почмактагы рамлы киндер рәсем, нота битләре, шамаил һәм Коръән китабы ничектер исән калган! Могҗиза дими, ни дисең моны…

Җыр һәм мылтык янәшә була алмый. Фәрит Яруллин — менә шушы «сандал белән чүкеч» арасына эләккән (килеп кергән) кеше. Аның физик һәм рухи батырлыгын онытырга хакыбыз юк безнең. Туганнан алып һәлакәтенә кадәр ул моң һәм көрәш дөньясында яшәде. Гомере, яшәү рәвеше — үзе бер музыка. Музыка аның өчен газаплы бәхет иде. ■

Татарстан Президентының Казан Кремлендәге резиденциясендә фән һәм техника өлкәсендә ТР Дәүләт бүләкләрен тапшыру тантанасы булып үтте. Филология фәннәре докторы, профессор, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты язма һәм музыкаль мирасны өйрәнү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре Марсель ӘХМӘТҖАНОВ «Татар шәҗәрәләре» дигән фәнни хезмәтләр сериясе өчен әлеге премиягә лаек булды. Авторыбызны зур уңышы белән котлыйбыз!

ЯҢА КИТАПЛАР



ЮНЫС Р.Ю. **ТАТАР ГАМЕ: тәфсилле әңгәмәләр, мәкаләләр, хатирәләр, шигырьләр** / [кереш сүз авт. Р.Вәлиев]. — Казан: Татар.кит. нәшр., 2013. — 495 б. Тиражы — 2000 данә.

1965 елда университетка укырга кергәч, без Рәфикъ Юныс белән тулай торакта бер бүлмәдә яшәдек. Өченчебез — Зөлфәт, аның белән икебез — хыялый затлар: ярыша-ярыша, шигырьләр язабыз, өлкән әдипләрне сүтеп-җыеп, ярсый-ярсый бәхәсләшәбез, көне-төне төрле очрашуларга, әдәби берләшмә утырышларына йөрибез, бүлмәбездә «Фанатик» исемле ирекле дивар гәҗите дә чыгарабыз. Ә Рәфикъ исә, безнең ыгы-зыгыларыбызга артык кушылып китмичә, сабыр гына бер читтән карап-күзәтеп тора. Ләкин аның бу күзәтүләре битараф күзәтү түгел, ә бүлмәдәшләреннән берничә яшькә өлкәнрәк, тәҗрибәлерәк кешенең гаҗәпләнеп тә, сынап та каравы булган икән.

Билгеле, бүлмәдә бәхәс чыккан чакта, ул бөтенләй үк читтә калмый, әңгәмәнең иң кызган вакытында, китабын бер кырыйга куя да ашыкмый гына үз фикерен әйтә. Бу инде бәхәс учагына бензин сипкән сыман була. Без, кинәт кабынып китеп, аны консерваторлыкта гаеплибез, гел-гел дөрес яшәүнең җәмгыятьне йоклатуы, тәрәккыят тәгәрмәченә таяк тыгуы хакындагы фәлсәфәбезне тукый башлыйбыз. Ул, күзләрен челт-челт йома-йома, үҗәтләнеп, үз сүзен дәвам итә, фикерен дәлилләү өчен, моңа кадәр без укымаган китаплардан, без исемнәрен дә ишетмәгән гыйлем ияләреннән мисаллар китерә. Рәфикъның бу «киребеткәнлеге» тәмам җелегебезгә үткәч, аның белән килешмәсәк тә, бәхәскә нокта куярга мәҗбүр булабыз. Берничә көннән ул, әлеге өзелгән бәхәсне дәвам итеп, һич көтмәгәндә, яңадан сүз башлый. Бүлмәдәшебез атна буена шул хакта уйланып йөргән, безне ышандыру өчен, китаплардан саллы дәлилләр эзләгән икән. Ә без инде, бу бәхәс турында күптән онытып, башка дулкында йөзәбез, башка дөньяда яшибез...

Ул чакларда шәриктәшебезнең ачуны чыгарган сыйфатлары киләчәктә иҗат кешесе өчен иң асыл сыйфатка әвереләсен беребез дә белмәгәндер, шәт. Дөрес, ул чорда һәммәбез дә үзебезчә сәер, үзебезчә үҗәт идек. Ләкин без, яшь шагыйрьләр, үҗәтләнеп, хыял канатында җиде кат күккә күтәрелергә омтылсак, журналист һөнәрен сайлаган Рәфикъ чын мәгънәсендә җир кешесе, җирнең үз баласы иде. Мулла гаиләсендә дөньяга килеп, ятимлек һәм фәкыйрьлек ачысын татыган, армия һәм тормыш тәҗрибәсе тупларга өлгергән егетнең тоткан юлы да безнекеннән аныграк, уйлары да җитдирәк булгандыр шул.

Еллар узгач, аек акыл һәм милли аң кушылган үҗәтлекнең ничек итеп яшәү максатына, иҗат кыйбласына әверелүен шагыйрь һәм публицист Рәфикъ Юныс мисалында без үз күзләребез белән күрдек. Шагыйрьлек оеткысының җанына Илаһи зат тарафыннан тумыштан ук иңдерелгән булуын, киләчәктә аның шигърияттән аерыла алмаячагын без инде студент елларында ук сиземләгән, аңлаган идек. Ә татар халкының соңгы утыз еллык рухи халәтенә төгәл диагноз куярлык фикер иясе — публицист булып җитешү өчен күпме акыл хезмәте куйганын исә ул бары үзе генә беләә торгандыр.

XX гасыр дәвамында татар халкы ике мәртәбә күтәрелеш чоры кичергән. Аның беренчесе, гасыр башындагысы, Тукайлар заманына туры килсә, 80-90 нчы еллардагысына безнең буын да шаһит булды. Бер милләт тә гел күтәрелештә, гел шатлык-куанычта гына яши алмыйдыр, милләт язмышы диңгез дулкыны сыман әле күтәрелә, әле түбән төшеп тынычлана, уйга таладыр. Шуңа күрә әлеге дулкын кодрәтен өйрәнеп һәм аңлап, аны халык күңеленә иңдерү, кешеләрне киләсе

дулкыннарга әзерләү милләтнең зыялы-затлы, туры кыйблалы шәхесләренә йөкләнә. Заманында бөек француз язучысы һәм галиме Шарль Луи Монтескье үзенең «Фарсы хатлары» әсәрендә татар халкының бөек дәүләтләр, империяләр корып, ярты дөньяны кул астына алып та шушы җиңүләрен, казанышларын тарихка теркәп барырлык елъязмачылары булмавы хакында әйтеп калдырган. Безнең җиңүләрдән һәм җиңелүләрдән торган көрәш тарихыбыз хәзер дә дәвам итә. Киләчәк буыннарыбыз белсен, өйрәнсен һәм гыйбрәт алсын өчен, аларны соңламыйча, бүген үк тәфсилләп язып баручыларыбыз, һәр вакыйганы, акыл һәм йөрәк аша кат-кат үткәреп, кәгазьгә төшерүчеләребез бармы соң? Бу урында мин, горурланып: «Бар безнең андый милли елъязмачыларыбыз, талантлы акыл ияләребез, һәм аларның иң булдыклысы, иң өлгере, — һичшиксез, Рәфикъ Юныс», — дияр идем.

Студент елларында Рәфикъ тулай торак белән университет арасындагы биш чакрым араны көн саен, трамвай, троллейбуска утырмыйча, җәяүләп теркелди торган иде. Башта моны чираттагы сәерлеге дип санап йөрсәк тә, торабара аңа да күнектек. Ләкин ул болар белән генә канәгатьләнмәде, озакламый марафон йөгерешләрендә катнаша башлады. Бераздан, бөтенебезне шаккатырып, Идел башланган урыннан Казанга кадәр мең биш йөз чакрымны җәяүләп узды, шул хакта гаҗәеп мавыктыргыч һәм гыйбрәтле язмалар да бастырды. Тора-бара Рәфикъ Юнысның бу җәяүле сәяхәтләре милли көрәш мәйданындагы иҗади марафонга әверелеп китте…

Рәфикъны мин иң әлек үзем өчен шагыйрь буларак ачкан идем. Аның шигырьләренә табигыйлек, ихласлык хас, ул, өстән торып, философларча акыл сатмый, яшәргә өйрәтми, ә, киресенчә, беренче чиратта үзен, үз күңелен, яшәү мәгънәсен аңларга омтыла. Рәфикъның шагыйранә иҗатында кеше күңеленең чиксезлеге галәми чиксезлек белән тоташа, кешеләр һәм чорлар белән ул «вакытлар алмашып» сөйләшә белә.

Ә бу китаптагы публицистик язмалар, әңгәмәләр белән шигъри әсәрләрнең аралашып баруы авторның фикерләү рәвешен тагын да ачыграк күзалларга ярдәм итә. Китапны тулысынча укып чыккач, ул аерым-аерым әсәрләрдән торган мәҗмуга түгел, ә бербөтен зур әсәр, заманыбызның шагыйрь йөрәге аша үткән елъязма-хроникасы булып күз алдына килә.

Рәфикъ Юныста тагын берничә бик затлы сыйфат — үзе күренмичә генә, кеше күрерлек олы эшләр эшләү, шапырынмыйча, йодрык төйнәп, сәяси мөнбәрләрдә шигырьләр яңгыратмыйча гына көрәшә белү, максатка ирешә алу сыйфатлары бар. Кайсы гына газетада яисә журналда кем генә булып эшләсә дә, ул тора-бара аларның күзгә күренми торган төп хезмәткәренә — умыртка сөягенә әверелә.

Бу кульъязманы укыганда, мин татар халкының милли күтәрелеш елларына әйләнеп кайткандай булдым, онытыла башлаган хатирәләрне күңелемдә яңарттым, референдум алдыннан, кулга алуларын көтеп, Югары Совет бинасында йокысыз үткәргән төннәрне, Ирек мәйданында бәйсезлек даулап, диңгездәй шаулаган көннәрне искә төшердем, һәм йөрәгем урынынннан кубып, яңа көрәшләргә ашкынгандай, ярсый-ярсый тибә башлады.

Рәфикъ Юнысның милләт язмышы белән бергә кушылган иҗади язмышы, «Татар гаме» белән сугарылган әсәрләре бер минем генә түгел, һәр чын татар кешесенең күңеленә барып җитәр, аларның йөрәген дә ешрак тибәргә мәҗбүр итәр дип уйлыйм.

Үзенең бер шигырендә Рәфикъ болай дип яза:

«Халык бит юк», — дисең. Әйе, аны
Берәмтекләп әле җыясы.
Мәңге туңнан, казып сөңге белән,
Чыгарасы татар кояшын.

Татарның көрәш тарихы, һичшиксез, кояш чыкканчы дәвам итәр, һәм Рәфикъ Юныс киләчәктә дә аның фидакяр елъязмачысы булыр дип ышанам.

Разил Вәлиев,
Татарстанның халык шагыйре ■

*Халкыбыз тарихы,
әдәби, мәдәни мирасыбыз,
тәнкыйди фикер һәм
заманча караш – барысы да*
«ЧЫН МИРАС»
журналында

ИНДЕКС

ТАТАРСТАНДА – 54132

ЧИТ ТӨБӘКЛӘРДӘ – 70275

БЕЗ МИРАСЛЫ ХАЛЫК. «ЧЫН МИРАС» БЕЛӘН БЕРГӘ БУЛЫГЫЗ!

ЧЫН МИРАС №1 / 2014